Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

02
февраль 2018
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

СЕРГЕЙ ШИРОКОВ. «КӘРВАН»

КҮЗ УҢЫНДА – ТАРИХИ ҮЗӘК

15 гыйнварда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казанның тарихи үзәген карап йөргәндә, Каюм Насыйри урамы үсеше эскизын тәкъдим иттеләр. Моннан тыш, Президент һәм аны озатып йөрүче рәсми затлар күптән түгел Иске Татар бистәсендә ачылган «Татар бистәсе» музеен (Каюм Насыйри урамы, 38) да карады.

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

02 (290)

февраль 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

42

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Кадыйр Сибгатуллин

ТАРИХИ МИРАС

4 Татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе
9 Мәрҗани хакында җавапларым. *Б.Шәрәф*
13 Нурсолтан. *О.Иванова*
19 «Мәрхәмәтсез кыз балалар пәрдә тартып тилмертә...» *М.Фәйзи*
25 «Әлислах» газетасы
29 Сафакүл
34 Ядәч һәм ядәчиләр. *Р.Фәхретдинов*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

36 Тәңре, Дингир вә Умай... *А.Галимҗанов*
40 Балкар халкының сөекле шагыйре

ТАТАР ГАМЕ

42 Мирасыбыз сагында

ДИНИ МИРАС

50 Ислам дөньясы. *Г.Ибраһимов*
55 Ризаэддин Фәхреддиннең Гыймадеддин Җәмаледдин улына язган хаты

ӘДӘБИ МИРАС

56 Аяз Гыйләҗев хатлары
64 Туган телнең хәстәрчесе. *Р.Әхмәтҗанов*
67 Татар теле. *Ф.Яруллин*
68 Үткәннән үтенеч
70 «Күңел дәфтәре»ндә ниләр бар? *Л.Хәмидуллин*
74 Үзем һәм юбилеем турында. *Г.Бәширов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

76 Йәгез, бер дога!

50 **ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ.**
Габдерәшит Ибраһимов



94 **КИҢ ТАРМАКЛЫ МИЛЛИ ИҖАТ.**
Розалина Шаһиева

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Ленар Гобәйдуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закиров
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 **Тимерче Фатих.** *Л.Закир*
83 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

86 **Сабакташым, иҗатташым...** *Ә.Зарипов*
94 **Киң тармаклы милли иҗат.** *Р.Шаһиева*

МУЗЫКАЛЬ МИРАСНЫ БАРЛАГАНДА

98 **Җырлар артыннан илләр гизеп.** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
108 **Милли музейда Шиһабетдин Мәрҗани мирасы**
110 **Татарның асыл улы.** *Л.Лерон*

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*

Заказ №Е-156. Тираж – 1900 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.01.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Кәрван» ***С.Широков.***
Рауль Мир-Хәйдәров тупланмасыннан.

Безнең мирас №2 февраль 2018



КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН

(15.02.1942 – 04.06.1994)

ЯШИК...

Меңәр еллык тарих та бар,
Исем дә бар, ат та бар.
Милләт тә бар, халык та бар,
Хокук та бар, хак та бар.

Инде без ярлы да түгел,
Үтте бездән фәкыйрьлек.
Инде без мескен дә түгел,
Горур, диеп әйтерлек.

Барысы да үзебездә,
Бөтенесе бирелгән.
Әллә нәрсә эзләгән күк
Башлар гына иелгән.

Түбән карап эзлибезме? –
Яшик лә ансыз гына...
Милләт бөек, халык бөек –
Бары тик сансыз гына. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

ТАТАР АВЫЛЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

Узган елның ноябрь аенда ТР Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институтында «Урта Идел буеның татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» булып узды. Шул чарада яңгыраган кайбер фикерләрне сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ: «Татар авылы – телнең бишеге»

Казан ханлыгы бетерелгәннән соң, татар тормышы авылда гына сакланып кала. Татар үзенең шәһәр структурасын югалта һәм гасырлар дәвамында татар авылы телне, мәдәниятне, безнең гореф-гадәтләрне саклап килә. Бүген без, глобальләшү шартларында, шәһәрдә яшибез. Халкыбыз алдында гаять зур һәм катлаулы мәсьәлә – шушы ике структураны бергә янәшә ничек яшәтергә? Шәһәрдә ничек татар мохитен саклап калырга, үстерергә? Монысы – мәсьәләнең бер ягы. Ләкин глобальләшү чорында авыл да бик зур үзгәрешләр кичерә. Бөтен нәрсә соңгы 30-40 ел эчендә үзгәреп бетте. Без, татар авылы – телнең бишеге, татар авылы телебезне саклый, дип әйтәбез һәм шуңа ышанабыз.

Рафаил ШӘЙДУЛЛИН: «Татар авылларының тулы исемлеге юк»

Узган XX гасырның 90 нчы елларына кадәр авылларны өйрәнүгә зур игътибар бирелмәде. Мәсьәлә белән совет чорында күбесенчә пенсия яшендәге укымышлы авыл кешеләре, сирәк кенә, авылдан күчеп киткән шәһәр зыялылары шөгыльләнде. Кызганыч ки, аларның авыллар турында язган махсус хезмәтләре һәм хатирәләренең күпчелеге дөнья күрмәде, югалды. Бәлки кайбер өлеше һаман сандык төбендә, өйләрдәге киштәләрдә ятадыр. Моңа, әлбәттә, бүгенге көндә җитди игътибар бирергә кирәктер.

Авыл зыялылары язган кульязмаларның шундый хәлдә булуының сәбәбе берничә. Беренчедән, авыллар турында мәгълүмат булмау сәбәпле, күбесе ярым эшләнгән хәлдә була һәм матбугатка чыкмый кала; икенчедән, полиграфия оешмалары дәүләт карамагында булганга, төрле формаль берлекләргә теркәлмәгән аерым зыялылар үз хезмәтләрен бастыра алмыйлар; өченчедән, совет чорында хөкүмәт, галимнәр, зыялылар тарафыннан да авыллар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә зур ихтыяҗ булмый.

Бу мәсьәлә алар, аеруча галимнәр һәм хөкүмәт эшлекләләре өчен вак тема булып тоела, чөнки күбесе авылның киләчәген булачак «бөек социалистик казанышлар», шул исәптән авыл тормышының шәһәрләшүе белән бәйли һәм шуңа чын күңелдән ышана. Шунлыктан, авыллар турында күп кенә саллы хезмәтләр дөнья күрми кала, аларның тарихы гореф-гадәтләрдә, хатирәләрдә генә яшәвен дәвам итә. Менә шундый кульязма минем авылым турында да була. Аны 1960 нчы елларда кемдер Куйбышев шәһәренә (хәзерге Самара) бастырам дип алып китә дә, югалта.

Татарстанда 70-80 ел эчендә юкка чыккан 1200 авылның 230ы гына татар авылы, 700дән артыгы – руснныкы. Димәк, татар авылларының яшәеш потенциалы русларныкына караганда югарырак булган. Хәзер инде, аяныч ки, татар авылларының да яшәү көче елдан-ел кими бара, чөнки авылда халык өчен эш юк, яшьләр өчен киң социаль-мәдәни чаралар каралмаган.

Шунысы кызганыч, татар авылларының тулы исемлеге юк. Кайбер исәпләүләр буенча, 2017 елда Россия Федерациясендә якынча 4300 татар һәм башка милләтләр белән катнаш татар авыллары теркәлгән. Татарстандагы татар авыллары буенча да мондый исемлек юк. Әлбәттә, татар авылларын өйрәнү эшен аларның исемлеген барлаудан башлап җибәрергә кирәк.

Дамир ИСХАКОВ: «Җиргә тарихи хокукны күрсәтү кирәк булачак»

Үз гомеремдә төрле якларда 550 татар авылында булдым. Мәсьәләне төбәк тарихын өйрәнү, тарихи аңны үстерү белән генә бәйләргә кирәк түгел, аның сәяси яклары да бар. Якын арада Украинада җирне хосусыйлаштыру булачак, моны Европа илләре үткәрергә уйлый. Димәк, җир сәүдә әйләнешенә керәчәк. Җир мәсьәләсе аркылы анда бик күп кенә үзгәрешләр булачак. Ул вакытта, уйлавымча, аның буенча зур конфликтлар килеп чыгачак. Россия эчендә дә андый процесс бара. Көньякта, Краснодар тирәсендә фермерлар белән эре җирбиләүчеләр арасында низаглар туды. Татарстанны алсагыз да, бездә бик зур олигархлар бар, игенчеләр аларның 200-300 мең гектар җирен эшкәртә. Ләкин чынлыкта алар хуҗа түгел, ә арендаторлар гына. Җирне бүлә башлагач, хуҗа булырга теләүчеләр Татарстаннан гына түгел, читтән дә киләчәк һәм бу бик зур проблема китереп чыгарачак. Шул вакытта җиргә тарихи хокукны күрсәтү кирәк булачак.

Татарларның 95 проценты XIX гасыр ахырына кадәр авылда яшәгән. Безнең тегe яки бу дәрәҗәдә җиргә хокукыбыз бар, әмма ул беркетелмәгән. Авыллар тарихын өйрәнү алга таба шушы мәсьәлә тирәсендә дә безгә бераз ярдәм итәргә мөмкин. Анда кемнәр, кайсы чорда яшәгәнен беркетеп куйсак, җир өчен көрәш булганда, дәлил дә китерә алабыз. Бу – мәсьәләнең сәяси ягы. Әле бу турыда уйлаучылар аз, ләкин проблема күтәрелә башлады инде.

Беләсездер, Ш.Мәрҗани татар тарихын язганда, без күбрәк рус чыганакларына таянабыз, дип кисәткән һәм бу эшнең дөрес түгеллеге турында әйтеп калдырган. Әлеге ситуация бүген дә шул килеш саклана. Үзебезнең милләт өчен әһәмиятле бик күп мәгълүматлар рәсми тарихтан читтә калып килә һәм моның сәбәпләре төрле. Методик яктан да эшләнмәгән бик күп проблемалар бар. Мәсәлән, дустым һәм автордашым Искәндәр Измайлов миңа гел тәнкыйть итә: «Син төрле легенда һәм риваятьләргә таянасың, алар барысы да «выдумка» һәм аларны куллану кирәк түгел», – ди. Ләкин бит шушы дастаннардан, риваятьләрдән без бик күп яңа мәгълүмат таба алабыз, әмма аның өчен методика булырга тиеш, югыйсә, татар авыллары тарихы XVI йөздән түбән төшмәячәк.

Татар авылларының археологиясе юк диярлек. Тарих институтында, татар авыллары

XVI гасырда булмаган да, ахрысы, бу гасырга хәтле татарлар күчеп йөргәндер бәлки, дигән сыман фикерләрне дә ишетәм. Чөнки материал казылмаган, авылның датасын белеп булмый.

Минем аспирантым Иделнең уң ягындагы мишәрләр тарихы белән шөгыльләнде. Шул нәрсә күренә: без – татарлар, дигән мишәр төркемнәре XV-XVI гасырларга хәтле, гомумән, авылда яшәмәгән, крепость һәм шәһәрләрдә көн күргән. Алар элита булган һәм шушындагы халыктан ясак җыйган, соңрак кына авылга күчә башлаган. Бу нәрсә дигән сүз? Татар авылы тарихын язган вакытта безгә шәһәрләр тарихын да өйрәнергә туры киләчәк. Казан ханлыгында да шәһәрләр күп булган. Алат, Җөри кебек татарлар яшәгән урыннар – авыллар түгел, ә феодаль үзәкләр.

Гомәр САБИРҖАНОВ: «Хәзерге чорда колхозлар тарихына караш үтә тискәре»

Хәзер авыл тарихын язганда, русча әйткәндә, «осуждение прошлой большевистической истории» кысаларына сылтап, колхозлар, совхозлар, авыл советлары тарихына игътибар итмиләр, аларның тарихы онытыла, югала бара. Җитәкчеләр, колхозларны оештыручылар, андагы эшне җигелеп тартучылар – алар тарихны сөреп барган кешеләр ләбаса. Ул кешеләр илгә икмәк биргән, терлек үстергән, сөт һәм ит белән тәэмин иткән. Заманында үз халкы, районнар җитәкчелеге өчен алар алтын бөртек кебек булган – «золотой фонд кадров», дияләр иде. Бу шәхесләрне тарих читендә калдыру – зур гөнаһ. Мәсәлән, әтием сугыш башланган елда авыл советы рәисе иде (Куйбышев өлкәсенең Кутузов районындагы Яңа Җүрәй – Новое Фейзуллово авылы). Урак эшләрен төгәлләмичә, игеннәрне җыеп бетермичә, аны партия райкомы фронтка да җибәрмәде. Ә сугышның беренче атналарында ук яшь тракторчыларны, комбайнчыларны, хәтта иң таза атларны, колхозга бик кирәк фуражны да фронтка алдылар. Шулай итеп, әтием ашлыкны җыеп, дәүләтнекен элеваторга озатып, трудоденьнәргә һәм орлыкка дигәннәрен келәтләргә салдыргач кына аның «бронен» алдылар һәм ул фронтка китте. Андый кешеләрне онытырга ярамый.

Хәзерге чорда аерым даирәләрдә колхозлар, совхозлар тарихына караш үтә тискәре. «Ленин – җинаятьче, Германия белән килешү төзеп, Россиягә хыянәт итте», – дип кычкыручылар бар. Революция белән бәйләнгән һәрнәрсәгә кара ягыла. Шундый фикер ияләре асылда халыкның битенә төкерә, аның тарихын аяк астына салып таптарга тырыша. Ә шул ук тарихның сәхифәләре, мәсәлән, әтиемнең, хәтта авылда беренче коммунист булган әбиемнең дә, абыйларым һәм апаларымның да узган гомер юллары ич! Авыл кешеләренең биографиясен өйрәнү – ватан тарихын яклауның бер зур чарасы.

Альберт БОРҺАНОВ: «Авылларны сакларга тиешбез!»

Бу эш өч юнәлештә барырга тиеш: өйрәнү, һәйкәлләрне саклау һәм файдалану. Авыл тарихын өйрәнгәндә табигый мираска да игътибар итәргә кирәк (мәсәлән, чишмәләр, елгалар, калкулыклар һ.б.).

Күп кенә төбәк тарихы китапларында археология материаллары әлегә күренми. Күбесе XVIII гасырдан башлана. Кайбер иптәшләр: «Арча районында археология материаллары юк», – дип әйтәләр. Бар алар, ләкин бу турыда күпләр белми! Археология буенча чыккан элекке китаплар искерде. Күп һәйкәлләр җимерелде, аларны су басты, шактые төзелеш вакытында югалды. Археология һәйкәлләренең яңаларын

табарга кирәк, ә моның өчен казу эшләре алып бару зарур. Эзләсәң, һәр авылда археологик материал табыла. Әле күптән түгел генә Лашман авылында (Чирмешән районы) булдым. Бер иске сарай җимерелгән, җирне казыганда ук очлары, сөңгеләр килеп чыкты. Алар VII-XIV гасырларга карый.

Икенче юнәлеш – эпиграфик истәлекләрне, кабер ташларын өйрәнү. Төзелеш вакытында күп ядкәрләр җимерелгән, ул ташларны чиркәүләр, сыер фермалары төзегәндә файдаланганнар. Сакланган ташларны тәртипкә китерергә кирәк. Аларны өйрәнгәндә ике төрле материал үзәккә алына: язмалар һәм тамгалар.

1994 елдан бирле 32 районны өйрәнеп чыктым, күп авылларда булдым. Кыр экспедицияләрен тәмамлагач, безгә, җыелып, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрергә кирәк. Әле генә Чирмешәндә конференция үткәрдек, анда йөзгә якын укытучы килде. Зур җыелышны Азнакайда да уздырдык. Мактанып әйтүем түгел, Татарстанда гына да 62 конференция үткәрдем!

Соңгы елларда без Татарстанда бик күп юбилейлар уздырырга ашыктык. Авыл темасы онытылды. Татар халкының тарихы (1552 елдан башлап) авылда, шуның өчен без авылларны сакларга тиешбез.

Альта МӘХМҮТОВА: «Әбиләр сөйләгән риваятьләр дә кирәк»

Үземнең туган авылым – Менделеевск районының Бәзәкә тарихы турында ике китап яздым. Берсе аның татар телендә, «Бәзәкәм – туган бишегем» дип атала, икенчесе исә рус телендә – «Колыбель моя – Бизяки». Мин, үз тәҗрибәмнән чыгып, авыл тарихын язучыларга нинди авырлыкларга очравым хакында бераз сөйләп китмәкче булам.

Авыл тарихына бәйле материалларны кайдан табып була? Җавабы да бар һәм ул җиңел дә кебек: архив һәм китапханәләрдән. Беренчесе, әлбәттә, Казандагы Милли архив. Мин анда бик күп эшләдем. Русча әйтсәк, «вдоль и поперёк» эзләндем һәм күп нәрсә таптым. Әлбәттә, ул материал нигез итеп алынса да, аның фрагментар булуы, китап язу өчен башка архивларда да эшләү кирәклеге ачыкланды. Билгеле, күп материал РГАДА (Мәскәү), Уфа, Киров һәм башка дәүләт архивларында саклана. Бу шәһәрләргә барып, архивларда эшләмичә, тиешле нәтиҗәгә ирешеп булмый.

Нәрсәдән һәм ничек яза башларга? Материал җыелгач, китап язу – авыр булса да, бик мавыктыргыч эш. Шул материал нигезендә авылың тарихын йөрәгең аша уздырасың, үткәненә кайтып киләсең, эти-әниләрең чорына да игътибар итәсең. Үзең яшәгән чорны да күрәсең. Китап язганда иң мөһиме – тарихи дәвамчылыкны булдыру, тарихның дәвам итүен күрсәтә белү. Һәм мин нигез итеп хронологик принципны алдым.

Бездә авылларның борынгы чорын яктыртырлык документлар юк дәрәҗәсендә, архивлардагылары XVI гасырдан башлана. Гасырлар узган саен, документлар күбәя. Һәм үз авылымның тарихына багышланган материалларны туплаганнан соң, минем фикерем мондый: һәрбер авылның тарихы архивларда нинди дә булса чагылыш тапкан, аны эзләп таба белергә генә кирәк. Бу нәтиҗәне мин ни өчен әйтәм? Авыл тарихын язарга тотынганчы, мин шактый вакыт ризалашмадым. Ризалашмадым, дим, чөнки 90 нчы еллардан башлап, авылдашлар миңе: «Авыл тарихын яз», – дип кыса башлады. Бигрәк тә Иж Бубый тарихын язганнан соң: «Хәзер үзебезнең авылга да чират җитте», – дип кабатладылар. Ләкин мин 2010 елга кадәр ул темадан кача килдем. Бердән, куркыныч һәм бик җаваплы эш. Икенчедән, материаллар җитмәс, дип уйлый идем, бигрәк тә борынгы чор материаллары. Әлбәттә, риваятьләр, легендалар, мин кечкенәдән ишетеп үскән материал бар, ләкин бу гына җитми, документлар кирәк. Мәсәлән, Та-

тар энциклопедиясен булдырганда, төзүчеләр Бәзәкә авылы тарихын XVIII гасырдан башлаган иде. Айдар Ногманов белән без бу хакта күп сүз көрәштердек. Мин: «Безнең авыл шәҗәрәсенең бер читендә, «Таһир баба 1545 елда вафат», дип язылган. Димәк, авыл инде XVI гасырда ук булган», – дим. Айдар исә үз сүзендә нык тора: «Шәҗәрә генә җитми, документ кирәк», – ди.

Авыл тарихына бәйле документларны туплый башлагач, алар арасында борынгыдан авылда сакланып килгән риваять-шәҗәрәләрне раслаучылары булуын да күрдем. Мәсәлән, безнең бабаларыбыз 1697 елда Петр Iдән вотчина хокукына багышланган «Жалованная грамота» алган. Димәк, авылдашлар җирләрен нығыткан, аларның үз җирләре, вотчина җирләре булган һәм ул биләмәләр 1917 елга кадәр сакланган. 1697 елгы документ нәрсәгә нигезләнгән? Бәзәкәлеләрнең Павел Iгә мөрәҗәгатеннән: безнең бабаларыбыздан булган «Тогайко Беляков имел «Старинную крепость», но она сгорела в 1750 году». Алар 1750 нче елларда кулларында булган ике документны атый. Берсе – елы күрсәтелмичә генә бирелгән «Старинная крепость», Тогай Беляковның өстенлекләргә һәм ташламаларга хокукын раслаган грамота. Икенчесе – шулай ук янган, авыл тирәсендәге күлләрдә һәм Кама елгасында балык тотар өчен 1752 елда рөхсәт алынган шундый ук грамота.

Шушы документлар турында уйлый торгач, бәлки «Старинная крепость» Таһир баба исеменә бирелгән документтыр, дигән фикергә килдем, чөнки берничә гасыр эчендә кешенең ничәнче елда вафат булуын истә тоту (кабер ташы да, шәҗәрәсе дә сакланмаган) өчен ниндидер зур эш эшләргә тиеш бу баба. Ә җирне алудан да зуррак эш булырга мөмкин түгел. Шулай итеп, 1545 елны вафат булган Таһир баба әлеге җирләрне биләү хокукы алучы кеше булырга мөмкин, дип фаразладым. Эш вакытында бу документның ничәнче елда алынганлыгына тап булдым. Алабуга өязеннән Мәскәүгә җибәрелгән документлар реестрында язылган: 1517 елда алынган грамота Уфа «Приказная изба»сында теркәлгән булган. Шулай итеп, Таһир бабаның исемен 1517 елда алынган грамота белән бәйләргә була. Менә шундый чишелеше авыр булган мәсьәләләргә еш очрарга туры килә. Моның өчен, әлбәттә, казынырга, тарихны өйрәнергә һәм бик күп уйланырга да кирәк, чөнки фактларны, исемнәрне бер-берсенә тоташтыру өчен документлар җитми. Шуңа күрә дә шәҗәрәләргә һәм төрле легендаларга игътибар бирелергә тиеш һәм фараз рәвешендә булса да алар исәпкә алынсын иде. Әбиләр сөйләгән риваятьләр дә, тарихи хикәятләр дә – бөтенесе дә кирәк, чөнки аларда ниндидер таяныч табарга була.

Тагын бер мәсьәлә: минем өчен иң авыры – китапны бастыру өчен акча эзләү булды. «Башта китапның татарчасын үз акчама авылдашларым өчен чыгарам. Ә инде сезнең шәһәрләргә киткән балаларыгыз һәм аларның татарча укый белмәгән балалары – оныкларыгыз өчен русча китап кирәк. Анысына ярдәм итә алган кадәр итәрсез», – дидем.

Шулай итеп, Бәзәкә авылы тарихы турындагы китапны чыгардым, аны тәкъдим итү дә булды. Чыннан да бу вакыйга авылны уятты. Һәм шул тәкъдим итү вакытында мин авылның 500 еллыгын үткәрергә кирәк, дигән фикер әйттем. Августның 19ында авылның 500 еллыгын да зурлап уздырдылар. Бик күп кеше кайткан иде. Һәм менә хәзер дә шундый уяну бара авылда. Бу эшкә Чаллы, Алабуга, Менделеевск һәм Түбән Камада яшәүче зыялыларыбыз – бәзәкәлеләр зур өлеш кертте. Чөнки алар менә шушы бәйрәмнәрне үткәрүдә башлап йөрде: акчасын да тапты, эшен дә эшләде. Авылны уяту өчен мондый китаплар кирәктер, дип уйлыйм.

«Түгәрәк өстәл» басмага ТР Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре ярдәме белән әзерләнде. ■

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА – 200 ЕЛ
«ШУРА» ЖУРНАЛЫНЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫНА – 110 ЕЛ
БОРҺАН ШӘРӘФНЕҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

МӘРҖАНИ ХАКЫНДА ҖАВАПЛАРЫМ

Борһан Шәрәф

Ошбу елның гыйнвар ае татар, төрки һәм ислам дөнясында мөһим дата – Шиһабетдин Мәрҗанинең туууына – 200 ел һәм «Шура» журналының беренче саны басылып чыгуга 110 ел тулу белән әһәмиятле. Әлеге вакыйгаларның беренчесе – XIX гасыр, ә икенчесе XX йөз башы белән тоташтырса да, алар арасында тарихи бәйләнеш булуы бәхәссез.

Беренчедән, «Шура» журналының баш мөхәррире Ризаэддин Фәхреддин Шиһабетдин Мәрҗанине үзенең рухи остазы дип санаган, аның иҗаты белән шәкертлек, хәлфәлек вакытында ук танышкан. Булачак галим Түбән Шәлчәле авылында китап сәүдәгәреннән «Нәзурәтел-хак...»ны сатып ала һәм укып чыга: «Мәрҗанигә булган дошманлыкларым урынына – мәхәббәтем, нәфрәтем урынына ихлас һәм гүзәл гакыйдә урнашты. Шул көннән башлап аның һәр басылган әсәрен тикшереп бардым һәм бик күп файда алдым. Бүген дә Мәрҗанинең әсәрләреннән туйганым юк, бик күп гыйльми мәсьәләләр хакында мөрәҗәгать итәм, кабул итсәм-итмәсәм, аның фикере белән танышып үтәм», – дип, аңа чиксез ихтирамын белдерә. 1886 елда шәкерт Казанга сәяхәт итеп, заманының олуг тарихчысы, дин галиме Шиһабетдин Мәрҗани белән күрешә, әмма аның белән иркенләп аралаша алмый. Шиһабетдин Мәрҗани дә, Ризаэддин әфәнденең «Игътибар»ын укыгач, өмидле егет, мәсләгендә нык торса, эш эшләр, дигән.

Икенчедән, Р.Фәхреддин үзенең мәшһүр «Асар» исемле биобиблиографик хезмәтен һәм «Шура» журналында атаклы шәхесләр турында ун ел дәвамында басылып килгән «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хадисәләр» (вакыйгалар) сәхифәсен Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...», «Вафийәтел-әсляф...» китаплары рухында язган, биографияләрне өйрәнгәндә әлеге хезмәтләрне чыганак буларак та файдаланган. XX йөз башы татар зыялыларының киңәш мәйданы булган «Шура»да Муса Бигиевнең: «Мәрҗани хәзрәтләренең милләтебезгә күрсәткән хезмәтләре ни нәрсәдә? Тараткан фикерләренең тәэсирен үзе дөньяда чакта күргәнме?» – дигән сорауларына берничә авторның җавабы да басыла. Шуларның берсен – атаклы педагог, әдип, нашир һәм журналист Борһан Шәрәф (1883-1942, аның тууына да быел 135 ел) язганын сезнең хозурга да тәкъдим итәбез. Җаваплар «Шура» журналының 1911 елгы 24 нче санында дөнья күргән (757-759 битләр).

Шуны да искәртик: Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләре заманында күп кенә ислам мәмләкәтләрендә танылган кебек, «Шура» журналы да бөтен төрки дөньяга таралган, аның сәхифәләрендә Көнчыгыш һәм Аурупа әдипләренең, фикер ияләренең иҗатына зур урын бирелгән.

Редакция

Кай эше ул фазылның таң калмастай,
Кай сүзе ул камилнең күз салмастай?
Дәрдենә дәрдмәндләр шифа тапты,
Сукырлар күзен ачты кар манмастай.
Акмулла. «Мәрҗани» мәрсиясе.

Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре Бохарада укып та, аннан канәгатьләнмәгән вә шуны бөтен дөньяга игълан иткән кешеләрнең беренчесе булды. «Бохара күргән» кешеләр һәммәсе үзләренең камиллекләренә, мәдрәсә вә остазларының олуглыгына мәгърур булып йөргән һәм халык та шуларны хаклап вә яклап торган бер заманда Шиһаб хәзрәтнең бу каһарманлыгы бик олуг бер хидмәт иде. Соңра татарларның Бохарага карашлары бөтенләй алмашынуга сәбәп булды.

Шиһаб хәзрәтнең гыйлем вә камиллеккә ихтирамы, аңа юнәлүе вә аның алдында тез чүгүе мәрхүмнең үзен дә ирексез иткән, үз шәхси мәнфәгатьләреннән, вак дөнья мәшәкатьләреннән өстен иткән. Шул сәбәпле, гыйлем вә хакыйкать аннан, ягъни гыйлем хадименнән бер шәй таләп итсә, ул шуңа: «Ләббәйкә!» – дип, шартсыз, ык-мыксыз җавап биргән. Бу хакта гавамның яратмавы, голәмәнең вә меллаларның каршы килүләре аңа чүп булып кына күренгән.

Шиһаб хәзрәт белгән нәрсәләрне ул заманда белүче булмаган, димибез. Ул аңлаган мәсьәләләрне аңлаучы үзе генә булган, дип әйтсәк, хата булыр. Әмма ул әйткән сүзләрне башкалар әйтә алмаган, ул ачкан хакыйкатьләрне башкалар ябып тотканнар, бәлки хәзергәчә дә караңгы калган булырлар иде, дип әйтә алабыз. Башка белгечләрнең игътикадлары[1] анықы дәрәҗәсендә катгый була алмагандыр, дип уйларга нигез бар.

Сыйфат важиб[2] мәсьәләсендәге дәгъвалары, ястү намазы мәсьәләсендәге «Нәзурә»се, тәүге дүрт хәлифәне өстен күрү мәсьәләсендәге бәхәсләре, хөтбә, җомга намазыннан соң өйлә уку мәсьәләсендәге катгый бәяннәре, Бохараның мәгълүм укыту ысулларын тәнкыйтьләве, шәрех вә хашия[3] исемендәге чүп-чарларны игътибардан себерептүгеп, Коръән, хәдис вә чын голәмә әсәрләрен күтәрергә иҗтиһады, һәрбер мәсьәләдә хөкем вә тикшерүне алга чыгарып, тәкълид[4] вә гадәтнең хакимлегенә һөҗүм ясавы, Тәфтазаниларның фикерләрен танытуы – олы галимнең никадәр җөрьәтле һәм хак өчен никадәр гайрәтле вә фидакяр икәнлегенә ачык дәлилләрдер. Бу мәсьәләләр халыкның тәрәккыйсенә вә дин эшенең алга китүенә күп тәэсир күрсәтмәсә дә, галимебезнең хәзинәсендәге нәрсәләргә яңадан бәһа куеп чыгу булганлыктан, бездә фикер тууга

[1]Игътикад – ышану, инану.
[2]Сыйфат важиб –Аллаһның сыйфатлары.
[3]Шәрех вә хашия – текст читендә яки башка китапка коментарий һәм өстәмәләр.
[4] Тәкълид – ияру.

вә безнең милли вә иҗтимагый хәятебездәге алмашынуларга башлап зур сәбәпче булды.

Иҗтиһад гасырының төгәлләнмәве мәсьәләсен киң сурәттә мәйданга куюы үзе генә дә ни тора! Төркия, бик күп ислам мәмләкәтләре бу хакта Русиядән көнләшергә тиешләр. Бу хакта Курсави хәзрәтләренең дә хезмәтен онытмыйбыз, ләкин халыкка тәэсиребез Мәрҗанидән булды. Курсавиның «әл-Иршад» вә «Шәрхе гакаид»лары басылып мәйданга куелганда инде базарның кызуы үткән иде[5]. Шуңа күрә ул әсәрләрнең чыгуы аз гына да имеш-мимешкә сәбәп булмады. Шушының барысы Ташкичү каһарманы колагына яңгырап беткән иде.


شورا
١٩٠٨ = نومير ١٢
اورنبورغدا اونبيش كونده بر چققان
ادبى فنى و سياسى مجموعه‌در
محررى رضاء الدين بن فخرالدين =
ناشرلرى م. شاكر م. ذاكر راميفلر

«Шура» журналы, 1908 ел

Кечкенә генә ике эш: Шиһаб хәзрәт хисабы илә Казанда ике мәсҗеднең михраб урыны алмаштырылган. Чөнки бу мәсҗедләр кыйблага кыек салынган булган. Хәзерге вә элекке замандагы меллалар, гавамның «кыйбланы үзгәртте» дигән сүзен ишетмәс өчен, бу хәрәкәттән сакланырлар иде, дип уйлыйм. Риваять итүләренә күрә, Шиһаб хәзрәт урамда, мәсәлән, өеннән чыгып мәсҗедкә барганда авыз эченнән берәр дәрес тәкърарлап барып, кешеләрнең сәламен дә алмый торган булган, мәсҗедтә намаз көткәндә Коръән йә башка китапны уку илә мәшгуль булган. Бу эшләр зур камиллек түгел, әмма моның өчен гавамнан өстен тору кирәклегендә шөбһә юк. Хәзерге вә элекке заманда «сәясәтле» голәмәләр мәсҗедтән кергәндә вә чыкканда, берничә кешеләр илә исәнләшеп-сөйләшеп аларның хәтерләрен табуны камиллектән саныйлар түгелме?

Татарлардан галим сыйфаты илә чит мәмләкәтләрдә танылган кешеләрнең беренчесе Шиһабетдин әл-Мәрҗани булды. Мәдрәсәдә һинд басма китабының һамиштәге[6] кыек язуларын ихлас илә укыганым заманда, шул китапта бер мәсьәләгә дәлил өчен «әл-фәзыйлү Шиһабетдин әл-Мәрҗани»нең фикере аерым язылганын күрү миңа шулчаклы шатлык булды, татарлык өчен шулкадәр горурландым ки, тизрәк кычкырып, иптәшләремне җыеп, китапның шул урынын күрсәтмичә чыдый алмадым. Ул китапта татар галимен искә төшерүченең кем идеген белергә телисезме? Рәхим итегез: Мәрҗанинең сүзе илә дәлил итүче кеше Һиндның иң зур вә иң мәшһүр галимнәреннән имам Габделхәй әл-Лүкнәви иде.

[5] Габденнасыйр Курсавиның китаплары үзе исән вакытта кульъязма хәлдә тарала, Ш.Мәрҗани китапларыннан соң гына басылып чыга.
[6] Һамиш – китапка өстәмә текст, аңлатма.

Мәрҗанинең Истанбулда бастырылган «Мелла Җәлал хашия»сен актарганда, мәшһүр тарихчы Нәҗип Гасыймның «Төрек тарихы» әсәрендә Мәрҗанидән күчерелгән сәхифәләрне укыганда шулай ук милли горур хис иteләдер. 1874 нче елларда Лондонда бер китап фирмасы «Камусе гомуми»дә (энциклопедиядә) бастырылган мәшһүр кешеләр арасына Шиһаб хәзрәтнең тәрҗемәи хәлен тәкъдим итәр өчен хат илә аның үзенә мөрәҗәгать иткән, үзе хакында материал сораган. Бу хат хәзергәчә мәрхүмнең варислары кулында сакланадыр.

Шиһаб хәзрәт заманында бик таралган бер фикер – әһлеисламның Русиядә тәрәккый итүенннән өмид өзеп, Төркиягә һиҗрәт кылу кирәклеге булган. Казанның иң мәшһүр мөдәррисләреннән Кәрим хәзрәт вә гайре күп кешеләр шул фикер нигезендә һиҗрәт иткәннәр. Ләкин Шиһаб хәзрәт Русиядә татарларның тәрәккый итүләре мөмкин икәнлеге фикерендә булып, шуның юлларын күрсәткән. Бу мәсьәләдә хаклык кай тарафта булганы ул заманда караңгы булса да, дөреслек аның тарафында булдыгы хәзердә көн кеби ачыктыр.

Шиһаб хәзрәттән элек гыйлем эше мелла вә мәдрәсәләргә генә хас кеби булган. Элек заманда христиан гыйлемен монастырьга япкан кеби. Ул исә гыйлемне мәдрәсә почмагыннан чыгарган. Казанда сәүдәгәр, мирза вә гавам сыйныфы арасыннан Мәрҗани хозурында укыган кешеләр күп булган. Гыйлемнең мәдрәсә хөҗрәләреннән[7] вә чаршауларыннан читкә чыгуы, ягъни гыйлемнең гавамлашуы берничә ун еллар элек мәйданга куелу сәбәпле, хәзерге заманда указсыз вә вазыйфасыз кешеләр арасында да шундаен галимнәр табыла ки, бу хәл илә милләтебез өчен горурланмаска мөмкин түгелдер.

Аның милләтебез эчендә тарихка хезмәте беренче булганлыгы никадәр әйтелсә дә урынындадыр, ләкин мәрхүмнең бу юлдагы хезмәтләренең бер өлеше генә мәйданга чыгып, бик күп хезмәт вә мәшәкатьләреннән һаман да файдаланылмаган көе торыла. Әһле варислары, сәләтсез халыклар, эшкә килгәндә суына торган китап төзүчеләр дә аның әсәрләрен мәйданга чыгаруны булдыра алмый торалар .

Сүз чыкканда шуны искә төшерик әле: «Шиһаб ахун»ның кабер ташы берничә заманнар Казан зиратында иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган. Бер бәдәлченең каберенә чардуган ясаган Казан халкы Шиһаб ахун каберенә тиешенчә хатирә ясый алмый. Аның ташын да төзәттермиләр. Мәрхүм үзе кабер ташларының кадерен бик белүче, аларны эзләп сәфәр чыгучы, һәммәсен дикъкатьләп өйрәнүче булган.

Шиһаб хәзрәт галим, гыйлемне гавам фикереннән югары тота ала һәм шулай тота торган, гыйлемгә иҗтиһадлы вә аның өчен гайрәтле кеше булган. Үзеннән соңгыларның күз алдында гыйлемнең дәрәҗәсен күтәргән. Чит мәмләкәттә татар исемен гыйлем белән бәйләп телгә алуларына сәбәпче булган. Бик күп гыйльми мәсьәләләрне мәйданга куеп, кадере беленә башлауга иске хәзинәбездәге нәрсәләрне актарып, бәһаләрен тикшерүгә сәбәпче вә кузгатучы булган. Болар аз хезмәт түгел. Боларның әсәрләре дә күз алдында.

Без – Мәрҗани хәзрәтләрен күрмәгән, аның янында булучылардан гына әсәрләнгән кешеләр «олуг абыз»ны шулай таныйбыз.

PS*. Мөгаен, Шиһабетдин Мәрҗанинең кабер ташына XX йөз башында һәм совет дәверендә игътибар булгандыр, әмма аны соңгы елларда яңарту-төзекләндерү эшен* ***Лотфулла Нурислам*** *улы* ***Шәфигуллин*** *җитәкчелегендәге «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ егетләре башкарды.* ■

[7] Хөҗрә – мәдрәсәдә яшәп укый торган бүлмә.

НУРСОЛТАН

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Бу әсәрне тәрҗемә итәргә алынгач, тарихи әсәрләрдә Нурсолтан ханбикә исеменнән әйтелгән илаһи җыруга тап булдым. Ханәкә-Солтан дигәндә, нәкъ менә Нурсолтан һәм аның язмышы күздә тотылганы аңлашылыр дип уйлыйм:

Госман бер хафиз кызы идем,
Ханәкә-Солтан атлы идем.
Җефәк тә тотмас наз идем,
Тезген тотып барамын...

Чөнки үзенә Ходай озын гомер бирсә дә, Хәлил хан белән аларның бәхетле тормышы, ни аяныч, – алга таба укыгач, белерсез, – кыска, бик кыска булып чыга шул...

Мөдәррис Вәлиев

Хан бакчасының иң аргы башындагы ипле түгәрәк чатырда үзенә бер җайлы урын тапты Нурсолтан. Табигатьнең бөтен дөньядан аерып куелган бу почмагында җәй ахырының җылы көне аны купшы чәчәкләре белән кочаклап алды. Ятагыннан әле генә торган яшь кызга шул гына кирәк иде. Ул, сарай ыгы-зыгысыннан котылып, булачак ире – Хәлил солтан белән икәүдән-икәү очрашуны зарыгып көтә. Бу очрашуны карт ханның да озак һәм сабыр гына көткәнен белә һәм сүнеп баручы хакимнең өметләрен алдыйсы килми иде кызның.

Яшь солтан, озак көттермичә, тиздән бакча сукмагында пәйда булды. Якынлашып килүче ир-егеткә Нурсолтан әчке бер киеренкелек белән төбәлде. Казан ханының варисы шактый ябык һәм буйга да әлләкем түгел икән, шунлыктан, ул үз булмышыннан күпкә яшьрәк күренә, егерме биш яшәр ир-егеттән бигрәк, Хәлил әле килеш-килбәте

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2018) санында.

һаман да өлгереп җитмәгән үсмерне хәтерләтә. Яшь солтанның күзләре моңсу һәм арыган төсле, әйтерсең лә, бу күзләр – аныкы түгел, ә бары тик каш астына хан-атасыннан күчереп утыртылган иде. Солтан бу мизгелдә үзен шулкадәр оялчан-кыюсыз тота иде ки, Нурсолтанның йөрәге ирексездән калтыранып-тетрәнеп куйды, ул инде аңа таба яклауга, кемгәдер сыенуга һәм ана мәхәббәтенә мохтаҗ бер бала гына килеп барганын аңлады.

Хәлил, адымын акрынайтты да, эскәмиягә якынлашып җитәр-җитмәс, кыймыйча туктап калды. Нурсолтан да, шулвакыт аңына килеп, аңа туп-туры каравына, бар гореф-гадәтләрне читкә этәреп дигәндәй, булачак киявен баштанаяк күздән кичерүенә уңайсызланып куйды.

Шулай да кызның, эскәмиядән торып, булачак хуҗасына нәзакәтле генә буй сынып:

– Сезгә ихтирамым, хакимем, – дип әйтергә теле әйләнде.

– Кирәкми! – Ул ашыгып аңа каршы атлады, иңнәреннән кочып алды, кырыс гадәт кушканынча тагын да ныграк иелергә ирек бирмәде. – Сез әле бик хәлсез, башыгыз әйләнеп китүе дә ихтимал. Күп көннәр буе урын өстендә ятуы никадәр авыр булганын мин белмимме соң инде!

Нурсолтанның чынлап та колаклары тонды һәм башы шаулады. Ул солтанга үзен эскәмиягә утыртырга һәм яшел ефәк шәле белән урап алырга ризалык бирде. Йөзенең яртысын каплаган үтә күренмәле япма кызның сулышына капчык киндере кидергән сыман тоелды, шуңа аны, үзе дә сизмәстән, түземсезләнеп читкәрәк этәреп куйды. Чәчәк атучы розаларның искиткеч хуш исе белән йөзенә аңкылган саф җил аны башын эскәмиянең биек аркасына терәп, рәхәтләнеп күзләрен йомып, яшәү көче биргән һаваны суларга мәҗбүр итте.

Нурсолтан әле тиз генә аңына килә алмады, күпмедер шул хәлдә утырганнан соң гына, ниһаять, каршында катып-каушап торган солтаннан куркып калган кыяфәттә күзләрен ачты. Ниләр уйлады икән бу чакта аның булачак кияве? Шулкадәр саксызипсез булырга кирәк бит, әй! Сырхаулаган чагында аны караган Мәхмүд ханның хәләл җефетләре, армый-талмый, яхшы гадәтләргә өйрәттеләр ләбаса: «Ир-ат алдында, хәтта ул аның иртәгә үк ире икәнлеге билгеле булса да, кыз бала йөзен ачмаска тиеш!». Даланың кырыс тормышы һәртөрле шартларга елмаебрак карарга мөмкинлек биргән иркенлек-хөрлекне мәңгегә онытырга тиеш иде ул. Нурсолтан, кабаланып, япмасының читенә ябышты:

– Кичерегез...

Шул мәлдә үк кулында аның бармакларының кайнарлыгын тойды.

– Нурсолтан.

Нурсолтан, гаҗизләнеп, күзләрен ачты: «Йа Аллаһ, һәрвакыт барысы да шулай! Хәзер инде ул аның никадәр гүзәл булуы турында татлы сүзләрен кызганмас, шул гүзәллектән башка яши алмасын әйтер, кызның бер генә карашыннан да, имештер, ул мең кәррә «аһ» итә... Тик нигә шулай?! Тышкы кыяфәте нигә һәммә ир-ат затында чиксез дәрт-шәһвәт уята да аны ничек кенә булса да үзенеке итәргә ымсындыра соң?!»

– Нурсолтан, әгәр Сезгә сулыш алуы кыен булса, йөзегезне капламагыз. Монда миннән кала кеше юк, йоланы бозганыгызны беркем дә күрмәячәк.

Хәлил аннан кулын алды һәм кыз ирексездән шул сүзгә күнеп, йөзен ачты. Солтан аның каршындагы эскәмиягә утырды, әмма кәләшенең битенә туры карамас өчен, карашын чәчәк атып утыручы розаларга күчерде.

– Бу чатырның бөтен сарай биләмәсендә минем иң яраткан урыным икәнлеген кайдан белдегез? – Һәм, җавабын көтеп тормастан, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, сүзен акрын гына дәвам итте: – Без монда гүр иясе булган хатыным белән еш була идек. Соңгы

айларында ул тәмам хәлсезләнде, ә бит җәй җиткәнче яшисе, яраткан гөлчәчкәбезнең чәчәк атуын бик тә күрәсе килә иде. Розалар чәчәк атты, ләкин без менә аңардан башка гына алар белән хозурланып утырабыз. Йөрәгемдәге сагышым шулкадәр көчле...

Нурсолтан ишетелер-ишетелмәс кенә авыр сулыш алды, әмма бу тавыш солтанның сизгер колагына барып иреште, ул кинәт уңайсызланып куйды:

– Кичерә күрегез, Нурсолтан, мин үземне ахмакларча тотам. Сезнең янәшәгездә утырып, башка хатын-кыз турында сөйлим. Никадәр ахмаклык!

Ник килгәненә үкенә башлаган солтан, шунда ук китәргә ниятләп, кискен генә урыныннан торды. Нурсолтан аны китмәскә көч-хәл белән үгетли алды. Алар, вакыт узганын да сизмичә, төшкә кадәр сөйләшеп утырдылар.

Солтанның хатынына, әтисенә, яраткан шәһәренә багышлап үзе язган шигъри парчаларны елмаеп тыңлады Нурсолтан. Ул игътибарлы карашы астында ирнең ничек терелеп, кайнарланып китүен, кызның һәр сүзен шатланып тыңлавын күрде. Солтан зур, әмма саф, сизгер күңелле бала кебек иде. Өйлә намазы вакыты җиткәч, булачак кияү белән кәләшкә аерылышырга туры килде, Нурсолтан җиңелчә генә сагыш эчендә калды.

– Мин үз гомеремдә моннан да мәрхәмәтлерәк көн күрмәгән идем, – дип пышылдады ул. – Аллаһның зирәк карарларына каршы килгәндә, аның тарафыннан ләүхелмәгъфүздә ниләр язып куелганын белмибез шул.

Төн чыгарга үз бүлмәсенә кайтып яткач, Нурсолтан үзалдына гаҗәпләнеп уйлады: «Бүген инде «үләргә» дигән тыелгысыз теләгем юк. Яратмаган кеше кочагына ташлаган, дип, язмышымны да каһәрләмим. Авыруым басылып килә, бу көннәрдә Ходай Тәгаләдән Миңлегәрәйгә кире кайтаруын да ялвармыйм, ул үткәндә, томан эчендә калып бара».

Хан табибәләре иртән Нурсолтанны карагач, ул тәмам сау-сәламәт дип таптылар һәм Мәхмүд хан шунда ук никах көнен дә билгеләп куйды. Бер ай элек Ибраһим солтан белән никахлашкан Шаһназга шулай ук тәхет варисының кәләше белән күрешергә рөхсәт ителде. Нурсолтан туганы белән очрашуга сөенде, ә Шаһназ бусагадан ук үзендә җыелып килгән яңалыкларны такылдарга тотынды. Ибраһим солтанның икенче хатыны үз тормышыннан бик канәгать күренде. Аның сүзләренчә, ире илтифатлы һәм ягымлы икән. Моңарчы Ибраһимның бердәнбер җефете булган көндәше Фатыймасолтанга Шаһназ беренче көннәрдән үк якты чырай күрсәтмәгән, имеш.

Солтанның өлкән хатынын ничек җиңүен тасвирлаганын тыңлаганда, Нурсолтан әледән-әле елмаеп куя иде. Аның Шаһназын җен алыштырган диярсең, бу Ходай яраткан сылуның кара күзләрендәге сугышчан ялкынны бернинди үзгәрешләр дә басасүндерә алмас кебек.

– Ул бит, беренче улын тудыргач, инде икенче баласын көтеп йөргәнлектән, Ибраһимны үзенеке генә дип уйлый. Миңа ун бала табып бирү дә берни тормый, мин – бик нык хатын һәм беркайчан да авырганым булмады! Кендек әбисе, туасы балага зыяны тиюе бар, дип, Фатыймага төнге сәгатьләрдә солтан янына керүне тыйган, ә Ибраһим бөтен төннәрне минем белән үткәрә! – Шаһназ бик канәгать кенә кеткелдәп алды. – И Нурсолтан, Хөсәеннеке кебек күзләре зәңгәр, ә үзе шундый ук чибәр булса, мин үземне аның белән бик бәхетле тояр идем.

Балачак мәхәббәтен искә төшерү шул мәлдә үк Шаһназның дәртле кәефен кырды. Авыр көрсенеп эскәмиягә утырды да, Нурсолтан белән бергә йөргән бакчага күз салды.

– Ә син Миңлегәрәйне сагынасыңмы?

– Шаһназ! – Нурсолтан, куркып, тирә-ягына карады. – Син үзеңне шулкадәр ваемсыз тотасың. Аның турында сөйләшкәнебезне хан үзе дә ишетте бит. Мин аңа,

варисыңның кәләше ят ирләр хакында аһ ора икән, дип җиткерүләрен теләмәс идем.

– Әйе, син, әлбәттә, аны уйлап сагышланмыйсың, – диде Шаһназ, үчекләп. – Син, имештер, булачак иреңә тугрылыклы! Варис Хәлилгә ничек гашыйк икәнлегеңне күз алдыма китерәм! Минем ирем әйтә: Хәлилгә кыз булып туасы калган да аңа озын күлмәк кидереп, алтын-көмеш тагасы иде, ди...

– Тукта, Шаһназ! – Нурсолтанның болай гәп сатуга ачуы чыкты. – Берәүнең ахмаклыгын миңа сөйлисең. Күрәсең, ирең Хәлил солтаннан көнләшәдер, хан бит варислыкка Ибраһимны сайламаган!

– У-у!!! Шуны гына ишетәсем калган икән! – Шаһназ эскәмиядә сикереп үк куйды. – Әйе, күрәсең, син чынлап та Хәлилеңә гашыйк булгансың! Аны ничек кайнарланып яклыйсың, хәтта битемне тырнарга ябышыр идең бугай.

– Шаяруларыңны читкә куй әле, – Нурсолтан эскәмия артына аркасы белән сөялде. – Хәлил солтан – лаеклы кеше. Ул миңа ошый, тик мин куркам. – Инде күп көннәр үз-үзенә тыю салган исемне әйтер алдыннан ул бераз тынып торды. – Миңлегәрәйне беркайчан да оныта алмам, дип куркам.

Һәрвакыттагыча җиңел генә икенче сүзгә күчә торган Шаһназ Ибраһим солтанның үзенә бүләк иткән кыйммәтле зиннәтләре турында тәмләп сөйләргә кереште. Нурсолтан, аңа игътибар итмичә, уйга чумды. «Әйе, карт хан хаклы булган, – дип уйлады ул, – сагыну чире узып бара кебек. Мин аның авырттырып чәнчүләрен сизмим инде. Әмма синең йөзең күз алдыма килгәндә, Миңлегәрәй, ничек боекканымны, күңелемне нинди авыр сагыш басканын белсәң иде. Ә син мине онытмадың микән, Җаек буендагы теге кояшлы көнне хәтерлисеңме?» Нурсолтан, күз алдына китерергә дә курыккан, башны шаулата башлаган манзара-күренешләрне юып алырга теләгәндәй, битен сыпырып куйды, күзләрен томан басты. «Мин үземә синең турыда уйлауны тыям, Миңлегәрәй! Тынычлыкта калдыр мине, зинһар, төшләремә дә кермә! Тагын ике көннән мин Хәлил хатыны булам. Мин аңа бөтен барлыгымны тапшырам, тик ул аның яртысын гына кабул итәчәк, чөнки солтан теләсә нинди хәрәмләшүне бик тиз сизә һәм шул чакта, ялгыз дәрвиш кебек, хөҗрәсенә кереп йомыла. Ә мин моңа юл куярга тиеш түгел. Минем Мәхмүд ханны алдыйсым, миннән тугрылыклы адым көткән Казан Иленә хыянәт итәсем юк. Барысын да күреп-белеп торган Аллаһ каршысында ант итәм: Хәлил солтанга әйбәт хатын булырмын һәм бу антымны бозмам, Миңлегәрәй! Кит, үтенәм, хәтеремнән җуел!» Ул саркылып чыккан күз яшьләренең яңагы буйлап берәм-берәм тәгәрәгәнен дә тоймады. Шаһназның гамьсез сайравын еraктан гына ишеткән кебек, шулай дәшми-тынмый утыруында булды Нурсолтан.

***

– Ай, рәхимле Аллаһым, нинди гөнаһ шомлыгы булды инде бу?!

Нурсолтан әле генә төшеп ватылган нәфис фарфор касә кыйпылчыкларына аптырап карап торды. Башы чуалып, тәбәнәк чәй өстәле кырына куйган икән. Затлы касә ватыкларының аяк астында кызганыч тавыш белән чылтырап-зеңләп алуын аңышмый да калды. Нурсолтан, йөрәгенең дөп-дөп тибүен басарга теләп, кулларын күкрәгенә кушырды. Бүген иртәдән үк аны нindидер котылгысыз куркыныч каза килү ихтималын хәвефләнеп тоемлау биләде. Ул гадәти эшләр белән шөгыльләнергә теләде, әмма кулы бернигә дә бармады. Курку өянәкләре тәмам биләп алгач, ул кол хатыннарны Хәлил солтанның һәм ханның саулыгын белешеп кайтырга җибәрде. Коллар тынычландыра торган хәбәр белән кайтты: хан да, аның варисы да исән-сау, алар көне буе хан янында дәүләт эшләре белән шөгыльләнгәннәр.

Хәзер инде Нурсолтан кинәт кенә ачык итеп аңлап алды: Шаһназ белән нидер булган, ул туганының ярдәменә мохтаҗ һәм иртәдән бирле аны үз янына чакырган. Икесе бер үк Казан Кирмәне эчендә яшәсәләр дә, сирәк күрешәләр иде шул. Сарайның кырыс кануннары буенча, Ибраһим солтанның өендә яшәгән хатыны, хан сараена, варис хатынына әверелгән Нурсолтан янына бару өчен, әллә никадәр йола киртәләрен үтеп чыгарга тиеш булды. Нурсолтан, никах вакыйгалары вакытында Хәлил солтан аны энесенә күрсәтергә алып барган чакта гына, Шаһназда нибары бер мәртәбә кунак булды. Ә хәзер инде, иренең рөхсәтеннән башка, берьялгызы анда бару турында сүз дә юк иде.

Нурсолтан кәнәфигә утырды да Шаһназ өенә ничек барырга дип ашыгып уйлый башлады. Хезмәтче белән хат җибәрер идең, Шаһназ җавап язарга яратмый, чит кеше аша үз борчылуларыңны җиткерү мөмкин дә түгелдер. Шаһназга бәла-каза килгәненә Нурсолтанның инде шиге юк, хәтта үзендә нindидер чарасын күрергә өндәүче бер көч ташкынының көчәюен тойды. Куркыныч киләсен сизенгәндә, аның белән һәрвакыт шулай була иде.

Әле күптән түгел, ире Хәлил солтанга инде күптән онытылган чир өянәге әйләнеп кайткач та шул хәл кабатланды бит. Ул төнне бик нык эче пошып, Нурсолтан бик озак йокыга китә алмады, шуңа күрә иренең авырудан бәргәләнеп ятуын күргәч тә, һич каушап калмады. Аллаһ аңа җибәргән сынау сәгатендә ул, сарай буйлап, яланаяк көе карт табибка йөгерде. Ә инде дәвалаучы бабай авыру янында кайнашкан арада, Нурсолтан төнге салкын сарай буйлап хан хозурына чапты. Йөрәгенең шашынып тибүен, башыннан аягына чаклы биләп алган калтырануын хәзергә хәтле оныта алмый әле ул. Нурсолтан, өянәк узып, солтан инде куркуга салмаслык тирән йокыга талгач кына, үзен көчсез хатын итеп тоя алды. Мәхмүд хан ул чакта яшь хатынның күшеккән иңнәреннән нык учлары белән кысып, күңелен күтәрерлек сүзләр тапкан иде:

– Мин синдә ялгышмаганымны беләдер идем, кызым, шуның өчен дә рәхмәтлемен, – диде.

Карт ханга, Хәлилнең гомере икебез өчен дә кадерле, шуңа күрә миңа рәхмәт укырга кирәк түгел, дип әйтәсе килде Нурсолтанның. Тик салкыннан иреннәре калтырап, ул бер сүз дә оештыра алмады. Аннары хан кайнар үлән чәе китерергә кушты һәм, аталарча кайгырту белән, Нурсолтанны җылы сырган юрган астына кереп ятарга мәҗбүр итте.

Күптән түгел генә баштан узган бу хәлләр Нурсолтанның Шаһназга бару фикерен тагын да көчәйтте. Тик моны ничек эшләп була?.. Шул чакта сырлап эшләнгән ишек капкачлары ике якка ачылып китте, аннан Хәлил килеп керде, яшь солтанның йөзе балкый иде:

– Нурсолтан, күр әле! Бүген без әти белән яңа мәдрәсәнең планын сыздык. Әти, төзелеш белән син идарә итәрсең, дип вәгъдә бирде.

Солтан кечкенә өстәлгә сызымнар һәм рәсемнәр белән тулы кәгазь битләрен җәеп салды.

– Әйе, бу бик кызыклы, – дип, зиһене чуалган хәлдә генә җавап кайтарды Нурсолтан.

Бүтән теләсә кайсы вакытта ул яңа мәдрәсәнең өлгесе турында мавыгып фикер алышырга тотыныр иде, әмма хәзер түгел. Хәзер, аның йөрәген сыкраткан хәвеф-хәтәрне сиземләү вакытында түгел!

– Сиңа ни булды, җаным?

Ул тирән итеп сулыш алды. Хәлилнең сизгер күңеле һәрвакыттагыча аның хәлен шунда ук сизде. Хатын үзенең курку-борчылуын сөйләп бирде.

– Алай да син нишләп, Шаһназ белән нәрсәдер булган, дип, чын-чынлап ышанасың

әле? Бәла-каза булса, беренче итеп сиңа хәбәр салырлар иде, – аның, дулкынланып, бутала-бутала сөйләгәнен тыңлап бетергәч, Хәлил хатынын шулай дип тынычландырырга тырышты.

– Аңлагыз, хуҗам, бәлки, бернинди хәвеф-хәтәр булмагандыр, бу – гадәти хатын-кыз борчылуы гынадыр! Бер куркыныч хәл дә булмаганын минем Шаһназның үзеннән ишетәсем килә, яисә мине бүген бөтенләй йокы алмаячак.

– Ярар, яхшы, Нурсолтан! Йөрәгеңне борчылу-газаплардан азат итәр өчен, мин синең белән үземнең сакчымны һәм энекәшемә синең килүең турында хат язып җибәрермен.

– И Хәлил, рәхмәтләр яусын Сезгә!

Ул, аңышып та җитмәгән хәлдә иелде дә, көтелмәгән иркә-наз күрсәтеп, солтанны аптырашка калдырып, кулларын үпте. Шул ук мизгелдә ишеккә ташланып, хезмәтчеләргә кием китерергә кушты.

Башкала урамында кырлач салкыннары хакимлек итә иде. Зәмһәрир суыктан атларның танавыннан, кешеләрнең авыз-борыныннан пар бөркелә. Ханның баш ат караучысы кашау тирәсенә җыелышып, яшь хатынга урын-җир әзерләргә маташучы колларның озак мыштырдавына әкрен генә сукранып алды. Ниһаять, иренең сакчысы һәм хезмәтчеләр белән уратып алынган Нурсолтан да капкада күренде. Кашауның ярымкараңгы эчлегенә чумып, кеш тиреләреннән тегелгән туны белән ябынды һәм, кайчан юлга чыгабыз инде, дип, түземсезләнеп сорады. Әмма бөтенесе, сүз куешкан кебек, бүген гел каршы килеп торды: инде кузгалабыз дигәндә генә, дилбегә, камыт бавы белән нидер килеп чыкты. Шулай итеп, Нурсолтан туганы язмышында хәлиткеч булуы ихтимал тагын берничә мизгелне югалтты.

Шаһназ ярты ел буена, Казан ханлыгының пайтәхетендә пәйда булган көннән башлап, үзен олылау, куштанлану һәм рәхәт тормыш катламнарыннан ясалган татлы хәлвә шикелле биек тау түбәсе дип санады. Бай, хәлле тормыш саркып чыккан йортлары, киң бистәләре, гаҗәеп базарлары белән халык мыжлап торган Казан аның күпне күрергә ашыккан күзләрен, эшлекле табигатен шунда ук җәлеп итте. Ире Ибраһим солтанның зур йорты да төзелеше белән аңа хан сараен хәтерләтте. Өй артыннан җәелеп киткән бакча хан бакчасына шулкадәр охшаган, тик кечерәк кенә иде. Бу йортның исеме дә – Кече Сарай һәм анда Шаһназ үзен бик тиз хуҗабикә итеп тоя башлады. Ибраһимның өлкән хатыны – хакимият сөюче, кырыс-кырку холыклы Фатыймасолтан белән әләгешеп алулар аның көндәлек тормышына бик хаҗәт булган төрлелек һәм тоз-борыч тәмнәре кертеп җибәрде. Өйдәге хезмәтчеләр яшь бикәне карусыз тыңлыйлар, аннан куркалар иде. Ә кулга ияләштерелгән, аяк астында мырлап ятучы арыслан кебек ире ягымлы һәм юаш булды. Ибраһим солтаннан кыйммәтле һәдияләр алып, Шаһназ шунда ук иренең көчле һәм кайнар мәхәббәтенә ышанды. Аннары иренә карата үзенең сөю хисләре ничек тиз кабынган булса, шундый ук тизлек белән суынды да. Аны һәрвакыт кызыксындырган бүләк – ерак Нугай даласында, Нурсолтанның зәңгәр күзле туганы – Хөсәен морзага гыйшыгы төшүдән газапланган чакларында алып булмаган нәрсәләр генә иде. Аяк астында яткан ир затын һаман да күралмаганлыктан, ул әйтерсең лә әлегәчә тоймаган зур хисне – күңелен алгысыткан, гадәти булмаган зарыгу белән, йөрәге сизгән хәлне көтте. Һәм ул көн килде. ■

«МӘРХӘМӘТСЕЗ КЫЗ БАЛАЛАР ПӘРДӘ ТАРТЫП ТИЛМЕРТӘ...»

Мирхәйдәр Фәйзи

Драматургның көндәлекләре белән танышуны дәвам итәбез. 1919 елда М.Фәйзи хәзерге Башкортстан Республикасының Баймак районындагы Юлык авылында бертуган Рәмиевләр тарафыннан ачылган китапханәнең мөдире вазыйфасын башкара. Бер үк вакытта авылда яшьләр түгәрәге дә оештырып җибәрә, спектакльләр куя, әдәбият кичәләре уздыра. Әлеге кичә-спектакльләр ничек узган? Юлык яшьләре аулак өйләрдә ничек бәйрәм иткән? 1919 елда авыл халкының яшәү рәвеше, мәдәни тормышы ни хәлдә булган? Бу сорауларга җавапны М.Фәйзи язып калдырган көндәлектән эзлик.


1919
№20

20 нче номер белән теркәлгән көндәлекнең беренче бите. 1919 ел

1919 ЕЛ. ЮЛЫК – ОРСК – ЮЛЫК

Июль 7 сендә иртүк Вафаларга бардым. Яңа пешкән эремчек пәрәмәче белән чәй эчтем. Вафа, Садыйк, Бари – дүртебез Вафаларның аты белән балыкка киттек. Авылдан 7-8 чакрымдагы Куса елгасы буена барып төштек. Бари – ат караучы, без өчәү кармаклар алып киттек. Тар гына, сай гына бәләкәй елга. Мин андый җирдә тотып өйрәнмәгәнгә, тота белмим. Бер бәрдине эләктерә алмый җәдәп беттем. Ни качмый, ни эләкми. Ахры кармакны ташладым да, җиләккә киттем. Чәй эчәргә кайтканда Вафалар зур-зур тугызар бәрди алып кайттылар. Аңа бер дә күренергә ярамавын һәм башка шартларын өйрәттеләр. Каен күләгәсендә изүләрне чишеп, җиләкләп, чиксез тәмле итеп чәй эчтек. Чәйдән соң тагы бер тырышып карасам да, оста булып булмый ләбаса. Тагы җиләккә, тагы чәчәккә. Һай, һәйбәт урыннар, валлаһи. Бу якта каеннар тагы матуррак, үлән шәп. Гаҗәеп ямьле манзара...

Кичкә таба кичке салкын белән урман эченнән матур юллардан кайту, җаннарны дәүләткә чумдыра. «Үгез үлгән» елгасына туктап, салкын, тәмле суын эчеп йөрәкне ял иттердек. Печән чабып алып, өстенә утырып кайттык.

Кусакаем, синең буйларыңда үсә каен, үсә усаклар;
Ядкәреңне күңелем гел иркәләр, гел кадерләр, сөяр, гел саклар.
Кечкенә генә Куса, бик тар, бик сай, тирәләре аның ямьгә бай.
Кармагыма бер дә каптыра алмыйм, бәрдиләре шаян, ай-яй!

11ендә иртә чәйне эчкәч тә тырыс алып, Карасаз башына җиләккә киттем. Ике чакрымдай китеп бер җирдә генә тырысымны тутырып алдым. Бөрлегәннәр дә пешеп бетеп килә. Ул хатын-кыз, бала-чаганың җабырылып йөргән көне, миннән дә җырак китеп, чиләкләп, тырыслап алып кайталар. Мин, тырысымны тутырып, каен күләгәсендә хәл җыеп ятканда, бер арбага төялеп җиләктән кайтучы хатыннар, кызлар миңа атап бер җыр җырлап үттеләр:

Кара казаки кигәнсең, башың түбән игәнсең,
Башың түбән, күңелең сүрән, ...не[1] сөямсең?

Авыруым тиф – корсак тифы булып чыгып, Юлыкта, тәрбиясез, ялгыз 19 көн авырып яттым. Яныма Вәкил, Мөхәммәтгали, Хәсән, Гобәйдулла, Вафа, Маһруйлар килеп йөрделәр. Төннәрне ялгыз уздырдым. Кыенлык ниһаясенә җитеп барганда, Шакирҗан хәзрәтләр үзләренең күршеләрендәге бер буш өйгә алып куеп тәрбияли башладылар. Алар тәрбиясендә үткәргән биш көнемдә алардан күп ярдәмнәр күрдем. Ходаның рәхмәте булсын аларга! Сәгыйть җизни белән апай мине һәм Маһруйны алырга дип килеп, ике [төн] кундылар. Июль 31еннән Юлыктан чыгып китеп, Аюлы Тамагында бер, Акъярда бер, Күкшелдә ике кунып, **август** 4ендә Җүнәйгә кайтып җиттек. Юлда артык ватылмый, яхшы гына кайттым. Бик куандым.

Кызыллар якынлаганлыктан, безнекеләр кире Орскига күчә башлап, 13ендә мин, апай, Мортаза абый, Кәримә, Дилбәр, туп тавышлары ишетелә башлаганлыктан, ашыгыч сурәттә Орскига кайтып киттек. Әниләрне иртәгесен килеп алмакчы булсалар да, фронт бик якынлап, алар Җүнәйдә бүленеп калдылар.

Шәһәрдә гаскәр күп. Кызыл яшьләр дә кайтты. Эшли башладылар. Себердә качып йөргән артист Габдулла Кариев Орскида калган иде. Аны мобилизовать итеп, труппа төзеп, театрлар бик еш куела башлады. Артисткаларны мобилизация формасында гына җыеп алдылар. Минем «Галиябану», «Авыл бәйрәме»м дә куелды. Бик шәп чыкты. Үземне сәхнәгә чакырып алкышладылар. Пьесаларымны Кариев аркылы Казанга бастырырга дип җибәрдем, ягъни Кариев киткәндә алып китәчәк булды.

[1] Текстта шулай бирелгән.

Савыгып бетүемә дә карамастан, мөселман секциясе «Борьба красного Урала» исемле русча пьесаны перевод итәргә бирде. Ирексездән тәрҗемә итеп биреп, 500 сум хезмәт хакы бирделәр. Артист булып кал, переводчик булып кал, дип, күп жалунияләр күрсәттеләр. Нык бәйләнделәр. Риза булмадым. Көчләп алырлар иде инде, мин Башкортстан кешесе. Ул арада безгә мобилизация хәбәре дә килде. Ниһаять, тәмам савыгып бетеп, октябрь 8ендә Зыя җизнигә утырып Орскидан чыгып киттем. И Аллам, инде авырулардан сакла, исәнлектә кайтып күрешим, барыбыз да сау булыйк, дип теләп, туганнардан аерылдым.

Китапханәне барып карадым. Ишек йозагын, шкаф биген бозып, аклар байтак зыян ясаганнар. Каталог, инвентарь, айлык хисаплар – бөтенесе унлап кенәгә, әллә никадәр кәгазьләрне алып киткәннәр. Үткәндәге бөтен хезмәт югалган. Бик үкендем. Китапханәне өр-яңадан юлга куярга туры килә.

Авылда яшьләр гаскәрлектән котылу өчен читтә төрле урыннарга кереп беткәннәр. Кыш күңелсезрәк булыр микән, дигән уйлар туып, Темәстә каласымы әллә, дигән уйлар да туып китә. Ләкин Юлыкка күңел тарта да тора.

24ендә кич Сәлам белән Әпипә җиңгиләрнең өмәсен карарга бардык. Тәрәзәләрнең пәрдәләре күтәрелгән, өй эче тулы кыз. Гармон уйнап, җырлап, биеп дөньяны тетрәттеләр. Тыштан тәрәзәгә егетләр тулган. Карап тору гаять зәвыклы. Кызлар егетләргә төбәп төрле җырлар җырлыйлар. Егетләр капак[2] сүзләр ычкындыралар. Тәрәзә аша сөйләшү, уйнашу.


Г. Орск. 1918 год.

ПРОГРАММА.

В СРЕДУ (25) 8 МАЯ.

В помещении общественнаго собрания

Драматической секцией Союза Тюрко-Татарской молодежи.

ДАН БУДЕТ

СПЕКТАКЛЬ

I

ЯРТЫ АЛМА

Пьеса в 2 действ и 3 картины местнаго автора Мирхайдара Фейза.

ДЕЙСТВУЮЩИЯ ЛИЦА:

Гайнетдин . . . Х. Губайдуллин.
Марфуга (его жена) . . . Р. Галеева.
Маргуба (их дочь) . . . М. Люси.
Фойза (сноха) . . . Ш. Кися.
Сабит (интел. молод. чел.) . . . М. Ахметов.
Хайрулла, Усман, Хаким, Гимад, Хамидзян, Ханафи и другие — Друзья сабита. — Р. Мухамедияр, А. Габдинов, Г. Юсуф, А. Улум-бей, А. Бикбулат, Х. Мангут.

II

Кызлар шулай кзык итяляръ.

Кемедия в 1 действ. Г. Атауи.

Джамиля (дер. барышня) . . . М. Люси.
Латыфа . . . З. Музаферова.
Шакир-Хальфа (учитель) . . . Х. Губайдуллин.
Садык, Гильмзян, Ахмет-Гали, Бик-Тимир, Галимзян и другие — Ученики. — А. Эдя, А. Габдинов, Р. Мухамедияр, Г. Юсуф.

Начало в 8 час вечера.

Режиссер М. Ахметов. Распор. Г. Юсупов.
Тов. М. Файзуллин.

Тип. И. А. Лютикова, в Орске.

Орск шәһәрендә төрки-татар яшьләре тарафыннан уйналган спектакльләрнең программасы. 1918 ел

Ноябрь 1ендә китапханәне юлга куеп, ачып җибәрдем.

Кич Сәлам белән Әсма туташларның өмәсенә бардык. Кызлар да, егетләр дә күп. Тәрәзәләр уңайлы. Капак әйттеләр. Пәрдә төшереп тилмертәләр, күтәреп тилертәләр. Камилә, Гөләрәм туташлар белән тәрәзә аша ишарәләр белән сөйләштек. Гөләрәм туташ, тәрәзә янына гына утырганда пәрдәне төшерсәләр, шундук тартып куя. Мулла кызы мин дип куркып тормый. Бию, җырлау... Сәхнәдән карап торган кебек карап тик торабыз. Һәммәсе дә диярлек җиткән һәм капак кызлар, выставкага куйган мал кебек күз алдында тезелеп тора. Егетләр карап тора дип тартыну, качу юк. Хәтта егетләр карап торганда утыру, дәрт белән уйнауларын үзләре икърар итәләр. Шулай булуы

[2] Капак – шәп, мактап әйтү.

табигый да. Кайвакыт басып тәрәзәгә өелеп егетләрне карыйлар. Кайчак: «Курыккач, монда ник килгән?» – дип гаеплиләр. Күзгә-күз карашып торырга тиешле! Кайтканда Сәлам, Мөхәммәтҗан – өчебез бик күп кызларны озатып ташладык.

2сендә Хәсән белән Низамиләр өмәсенә бардык. Пәрдәләрне күтәреп, тәрәзәләрне гел сөртеп кенә торалар. Күңелле дә инде, валлаһи. Җанга әллә нинди ямьләр иңә. Бүген бер дә яшеренмәстән карадым. Килеп-килеп текәлеп карап торалар. Сүз кушсаң бер дә җавапсыз калдырмыйлар. Кызлар эчтә, егетләр тышта гармун белән капак сиптерәләр. «Мине кыстырмагыз!» – дим.

Зендә «Яшьләр түгәрәге» төзү чарасына вакыт җиткәнлекне аңлаттым. Һәм бер-ике көннән яшьләрне җыярга карар бирдек.

Кич Хәсән белән Рәхмәтулла абзыйлар өмәсенә бардык. Камилә туташлар белән яулык селкеп аңлаштык. Пәрдә төшерсәләр, тәрәзәне рәхимсез чиртәбез, пәрдә төшерүчеләргә төбәп җырлар чыгардык:

Өй түрендә киң киртә, киртә буйлап кил иртә;
Мәрхәмәтсез кыз балалар пәрдә тартып тилмертә.

Ачсалар:

Тәрәзәсе, тәрәзәсе, күтәрелде пәрдәсе;
Пәрдәләрне ачып куйды бер рәхимле бәндәсе.

Тагы төшерсәләр:

Тәрәзәңнең пәрдәсен кичке җилләр бәрмәсен;
Пәрдә төшергән кызларны Аллаһ үзе әрләсен.

Тагы күтәргәч:

Сузылып яттым, үрдәк аттым, алдыралмадым, алдаттым;
Пәрдәне күтәргән өчен рәхмәт яусын, ардаклым[3]!

Кызык булып бетте. Бер малайның тәрәзә капкачын нык дөбердәтүе сәбәпле, өй хуҗасы хатын табагач тотып чыгып һәммәбезне тызылдатып куды. Тыпыр-тыпыр коймадан сикереп төшеп качтык. И мәрәкә булды да инде. Ул кереп киткәч, тагы бардык. Кызларны тәмам озатып бетеп кайттык.

6сында кич яшьләр җыелды. 16 белән 30 арасындагылардан 45 егет килде. Мәҗлеснең рәислеген үз өстемә алып, язучылыкка Әдһәм Чанышевны күрсәттем. Мәҗлесне ачып, максудны яхшы ук әтрафлы һәм озын гына итеп сөйләп аңлаттым. Башка яклап сөйләүчеләр дә булды. Бары 5 каршы тавыш белән «Яшьләр түгәрәге» төзергә карар бирелде. Шундук 30 кеше әгъза язылып, 1600 сум әгъзалык акчасы җыелды. Идарә әгъзалары сайланды. Рәис – Габдулла Әдһәмов, секретарь – Әдһәм Чанышев, казначей – Хәсән Хәлилуллин; мин, Габделәхәт Әдһәмов, Нәби Тимербулатов, Миңлегали Хәлилуллин идарә әгъзалары булып сайландык. Мин режиссёр да булдым. Соңынтын, түгәрәкне котлап, мәҗлесне яптым. Гаять күңелле, тәртипле, рухлы үтте. Иптәшләрнең бу кадәр үзләрен матур тотулары зур өметләр бирде. Ләкин мәҗлес азагында ике кешенең котыртуы белән, теге биш кара тавыш та аларга кушылып, зур тавыш, кабахәт сүзләр белән мәйданга чыктылар. «Театр уйнаттырмыйбыз», «сөякләрегезне көл итәбез», «бардак ачарга йөрисез», «до последней капли крови», «дин дошманнары», «барыгызны да кырып бетерәбез», кебек кабахәт һәм зур сүзләр белән өстебезгә атылып, йодрыклары баш түбәләребездә уйнап йөрде. Әгъзаларны куып чыгарып бетерделәр. Кайсы өстәлгә, кайсы урындыкка басып, кулларын болгап: «Чөеп ташлагыз!» – кебек сүзләр белән әгъзаларның котларын алдылар. Кызып, вәхшиләнеп киткән кешеләрнең йодрыгыннан чак кыйналмый, кайсыбыз аннан, кай-

[3] Ардаклым – кадерлем.

сыбыз моннан качып, өйләребезгә кайттык. Яшьрәк әгъзалардан байтагы куркудан: «Безне җуегыз», – дип төн буе секретарь, казначей һәм минем өйләр арасында сәяхәт итеп йөрделәр. Юатып җибәреп тордым.

14ендә кич Газиз Надировлар өмәсенә бардым. Миннән соң Хәсән белән Мөхәммәтгали дә килде. Тәрәзә уңайлы, зур, бозсыз, пәрдәләр күтәрүле. Шым кызлар тулган. Баргач та, тәрәзә чиртеп, үземне белдердем. Тәрәзә янында утырган кызга: «Тәрәзәне сөрт әле, акыллым!» – дигән идем, ул Гөләрәм туташ икән. Яулыгын корбан итеп булса да тәрәзәне сөртте. Егетләр килеп карый башлады исә, уеннары бердән кызып китә. Кызлар йөрәге белән егетләр йөрәге арасындагы чыбыксыз телефонның тәэсире инде бу, әлбәттә. Пәрдәне кору, ачу, бу хакта кызларның икегә бүленеп тартышулары... Бер хатын: «Пәрдәне тартыгыз, китап шулай утырырга кушамыни», – дигән иде, бер кыз: «Китапта, егетләр килсә, пәрдә төшерегез, дигән сүз юк», – дип, капак ычкындырды. Берсе артыннан берсе төшеп, рәттән унлап кыз бии. Мин тәрәзә аша такмак әйтәм. Йә малайларга өйрәтеп әйттерәм. Бер хатын: «Җыр тыңлаган егетләрнең ялтырап тора маңкасы», – дип җырлаган иде, мин: «Үз маңкаң да агып китәр, бик күтәрмә борыныңны», – дип ачу катыш тавыш белән бәреп җыктым. Бик ачу килгәнгә, бер малайга өйрәтеп: «Безне хурлаган хатыннар җәһәннәмгә мөкиббән[4]» – дип кызларның киберен[5] чәлпәрәмә китердем. Һәрхәлдә, кызык булып бетте. Кайтканда Камилә, Гөләрәм туташлар белән бергә кайтып, аларны озатып куйдык.

17сендә кич түгәрәкнең гомуми җыелышы чакырылды. Вакыт җиткәч, кыйраәтханәне ачыйм гына дигән идем, бер бала килеп: «Мөәзин өендә сине ике солдат чакыра», – дип алып китте. Бардым. Пайтәхеттә чыккан Хәмидуллин һәм Мансур Зиннәтуллин исемнәрендә ике агитатор-организатор икән. Волостьлардагы хезмәтләрен бетереп, кайтырга йөргәндә, Юлыктагы безнең вакыйгалар сәбәпле, бу волостька да җибәрәсе иткәннәр. Күп авылларда яшьләр оешмасы төзегәннәр. Миннән вакыйганың тәфсилен сөйләттеләр. Безнең җыелышка да килделәр. Ләкин җитәрлек әгъзалар җыелмау сәбәпле, мәҗлес иртәгә кичектерелде. Берсе байтак кына сөйләде.

18ендә организаторлар иртүк кыйраәтханәгә сход җыйдылар. Кеше бик күп килде. Иң элек Хәмидуллин бик озак һәм шәп итеп төрле хакта сөйләде. Безнең эшләр турысында да байтак кына тукыды. Каршы килүчеләрне рәхимсез тотып бирергә кушты. Аннан Зиннәтуллин тагы шул хакта сөйләде. Аннан мин сүз алып, үзебезнең эшләр хакында халыкка доклад бирдем. Шул мөнәсәбәт белән күп нәрсәләргә кагылып, байтак мисаллар китереп, театр-әдәбият кичәләре хакында байтак сөйләдем. Шактый озынга киткән сүзләрем муаффәкыятьле, кызыл җеп кебек сузылып барып очланды. Картларның характерларын Хуҗа Насретдинның үзе утырган ботакка балта чабуына охшатып, яхшы ук кына каты бәрелдем. Сүземне: «Яшәсен яшьләре белән картларның аңлашып эш итүе!» – дип бетердем. Кул чаптылар. Аннан Әхәт, аннан Гомәр, аннан Хәмидуллин, аннан Гомәр, аннан Габдерәшидев, аннан мин, аннан Әхәт, аннан Хәмидуллин, аннан Гомәр, аннан Хәбиб хәлфә, аннан Хәмидуллин сөйләде. Бик шәп бер гыйльми мәҗлес булды. Халык тәмам бөгелде. Һичбер каршы нәрсә әйтә алмадылар.

21ендә кич кызлар мәктәбендә «Яшьләр түгәрәге»нең беренче әдәби кичәсе булды. Залны төрле пыялалы фонарьлар, кәгазь фонарьлар, кәгазьләр белән бизәп, карагайлар белән бик матур сәхнә ясадык. Мөгаллимнәр күп килмәде. Ләкин бик күңелле, рухлы, муаффәкыятьле булып чыкты. Элек мин үземне һәм әгъзаларны, Габделәхәт укыту-

---

[4] Мөкиббән – артык.
[5] Кибер – тәкәбберләнү.

чыларны тәкъдим иттек. Мөгаллимнәр үзләрен тәкъдим иттеләр. Танышу мәрасиме узгач, уен башланды.

Программасы: «Галиябану», «Нарасый бала» – хор; «Бәрәңге вә гыйлем» – декламация, Габделәхәт Әдһәмов; «Миндә көч» – декламация, Хөсәен Хәлилуллин; парлап бию – Борһан, Мөхәммәтҗан; «Зиләйлүк» – ялгыз җыр, Мостафа Зәйнелгабетдинев; «Ысулы кадимче» – декламация, Мирхәйдәр Фәйзи; «Өйләнү, түгел сөйләнү» – декламация, Фәйзи, Әдһәм; «Бардым базарга» – декламация, Борһан Әдһәмов; «Гыйшык уты» – декламация, Хәсән Хәлил; бию – Габидулла Габделкәримев; «Кайгырмагыз» – декламация, Гомәр Габидев; «Гаскәр хаты» – декламация, Мирхәйдәр Фәйзи; «Зөбәрҗәт», «Ай, былбылым» – хор. Уеннан соң, үзләре теләп сәхнәгә чыгучылар белән кичә байтакка сузылды. Бари мулла белән Заһири мөәзин дә килде. Мин режиссёр булдым.

Декабрь 5есендә үрге ирләр мәктәбе залында театр уйнадык. Бер стенаны кисү аркасында бик матур сәхнә, зал, буфетлар мәйданга килде. Буфетны карагай, төрле пыяла фонарь һәм кәгазь фонарь, кәгазь чылбырлар белән бик матурлап бизәдек. Төрле урыннардан, төрле тәмле ашлар – бәлеш, пәрәмәч, ләвеш, сумса, пирожный, печеньелар килде. Билетлар җитми калды. Сәхнә һәм бик муаффәкыятьле чыгып, җиһазлар да җитеш булу аркасында ямь тәҗәссем итеп торды. Читтән курайчы, җырчы, биючеләр дә китерттек. Уеннар яхшук муаффәкыятьле чыкты. Халык бик ягратканлыгын белдереп таралды.

Халык таралгач, участвовать итүчеләргә хас күңелле, мәмиләргә бай мәҗлес булды. Зәһидулла Туганов, Муса Таһировларның курайда парлап уйнаулары, Габдерәхим Ишгузинның җырлавы, биюе күңелемдә бетмәслек эз калдырдылар. Вәлит ыспай гына җиңел итек кигән, аяклары белән шулкадәр күп фигуралар ясап, күбәләк кебек очкалап йөргәндә, кызларның йөрәгенә кул куеп карыйсым килә. Заһид та хәйран матур бии. Болар каршында: «Мин бәхетсез, мин бәхетсез дөньяда ...»

Кичәнең программасы: «Имчеләр корбаны»; «Бүләк өчен»; Әдәбият бүлеме: «Кичке җилләр», «Миләүшә» – күмәк җыр; «Нәсыйхәт» – (декламация) Габделәхәт Әдһәмов; Бер картлыкта, бер яшьлектә – (кечкенә сәхнә) Борһан, Әхмәт; «Тәфтиләү», «Буранай» – (ялгыз җыр) Гадерәхим Ишгуҗин; «Шикмәрне сагынып» – (декламация) Габделхәй Әдһәмов; Милли моңнар – (курайда) Муса Таһиров, Заһидулла Тойгынов; «Тәравих чәе» – (декламация) Мирхәйдәр Фәйзи; «Сикереп бас!» – (бию) Ибраһим Мортазин; «Нарасый бала», «Зөбәрҗәт» – (күмәк җыр).

6сында кич шулук програм хатын-кызлар өчен куелды. Билетлар сатылып бетте. Буфетны туташлар идарә итте. Мулла, мөәзин хатыннары – бар да килде. Бик тәртипле, матур, күңелле үтте кичәләр.

Халыкка зур бер бәйрәм ясадык. Оешма төзегән вакытта йодрыклары баш түбәләребездә уйнап йөргән ике кеше дә килеп: «Эчмәм дигән коеңнан, өч әйләнеп эчәрсең», – дигән мәкальне тәсдыйк иттеләр. Заһири мөәзин суфлёр булды.

27сендә – хатыннар кичәсе дә бик матур үтте. Уеннар шәп чыкты. Тырышу аркасында уйнаучылар да табылып, ниндәй һәйбәт кичәләр төзелә башлады. Матур-матур гына уйнаучылар пәйда булды. Авыл балалары сәнаигы нәфисә мәйданында матур гына эшләр, ләүхәләр[6] күрсәтә башладылар. Хода хәерле дәвам бирсен. Сау булыйк!

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

[6] Ләүхә – күренеш, картина.

Безнең мирас №2 февраль 2018

ТАТАР МАТБУГАТЫ

«ӘЛИСЛАХ» ГАЗЕТАСЫ

Татар әдәбияты һәм тарихында Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан исемнәре белән бәйләп еш телгә алына торган «гыйльми, әдәби һәфтәлек (атналык) гәзитә» «Әлислах» турында матбугат белгече Исмәгыйль Рәмиев менә нiләр яза: «Легальный булып, 1907 нче ел 13 нче октябрьдә Казанда чыга башлый. Башта бу гәзит шәкертләрнең яшерен төзелгән «Ислях» комитеты тарафыннан яшерен, рөхсәтсез, җилем матбагада гына басылып килә. Беренче яшерен номеры 1905 нче ел 29 нче нобярьдә чыгарыла. Лозунгы: «Уйганыгыз, бөтен татар шәкертләре!» – була. Бу гәзит – милли буржаузный агымының сул канатыннан барган гәзит. Иске кадими мәдрәсәләрне, ислях, мантыйк белән баш ватуны ташлап, фән дә укуга күчү; шуның белән бергә иске фикерле хәлфәләргә, мулла-мөдәррисләргә каршы көрәш ачты. Шәкертлек дөньясының милли кыйсемен нык аякка бастырды. «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Галия», «Госмания», «Касыймия»ләрдә, хәтта Кышкар, Түнтәр, Мәчкәрә кебек искелек бик нык көчле булган, артта калган мәдрәсләрдә дә чуалышлар, фикери үзгәрешләр ясатуда нык тәэсире булды»[1].

«Әлислах»ның эчтәлеге, рубрикалары реклама буларак газетаның үзендә үк берничә мәртәбә басылган текстта ачык чагыла: *«Гәзитәдә мәгариф интишарына гаид (җәелдерүгә караган) баш мәкаләләр, татар мәгыйшәтеннән: сәяси, икътисади, гыйльми, дини җәһәтеннән тәнкыйть иткән мәкаләләр, гомумән, әдәбиятка вә хосусый сурәттә татар әдәбиятына даир (караган) тәнкыйть вә мөхакәмәләр (тикшерүләр), мәдрәсәләргә даир меляхәзәләр (фикерләр), бөтенрусия мәдрәсәләре мәгыйшәтеннән мөфассаль (җентекле) хәбәрләр, шагыйрь Габдулла Тукайның иң яңа шигырьләре, татар руханилары мәгыйшәтеннән иң тәфсыйлле хәбәрләр, «Хатын-кыз галәме», Истанбул хәбәрләре (махсус мөхбиребез булачак), татар гәзитә вә журналларына даир тәнкыйтьләр, шәрык, гареб галәме, дахили (эчке) хәбәрләр, Казан хәбәрләре, сәясәткә даир мәкаләләр, татар мәгыйшәтенең төрле тарафларыннан килгән кечкенә фельетоннар, фәнни вә мәгаши (яшәү өчен кирәкле) мөтәфәррикалар (бүлекләр) булачактыр».*

Фатих Әмирхан инициативасы белән дөньяга таралган «Әлислах»ның баш

[1] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты: альбом (1905–1925). – Казан: Гажур, 1926. – Б.25-26.

мөхәррире һәм нашире – Вафа Бәхтияров (1881-1960). Газетаны чыгарырга рөхсәт алгач, мөхәррир 1907 елның апрелендә Габдулла Тукайга хезмәттәшлек итүне сорап хат юллый. Шагыйрь Җаектан кайткач та, аны «Сарай» номерларының Кабан күленә карый торган ягына, үзе белән күрше бүлмәгә урнаштыра[2]. Вафа Бәхтияров Тукай турындагы истәлекләрендә: *«Тукай, мин, хәзер дә исән-сау, Казанда мех фабрикасында бухгалтер булып хезмәт итүче Лотфулла Вахидов – өчәүләп Фатих Әмирханга бардык. 1907 елның декабрендә шул утырышта Тукай Казанда калырга һәм «Әлислах»та эшләшергә сүз бирде. Шулай итеп, Тукай «ислахчы»лар арасына кереп китте»*, – дип яза. Шагыйрь үз исеме һәм «Гъ.Т», «Шүрәле», «Феакут» имзалары белән илледән артык шигырен, берничә мәкаләсен, шулар арасыннан барыбызга да мәгълүм «Тәнкыйть кирәкле шәйдер» дип исемләнгән мәшһүр әсәрен һәм фельетоннарын «Әлислах»та бастыра[3]. Тукай шигырьләре басылу газетаның дәрәҗәсен күтәргән, аны халыкка таныткан. И.Сафинның язуына караганда, Вафа Бәхтияров хәтта үзенең хезмәт хакыннан айлык 25 сум акчаның 15 сумын Тукайга биреп барган[4].

Газетаның әдәби мөхәррире Фатих Әмирхан «Әлислах»ның иң актив авторыннан булган. Анда мәшһүр әдипнең «Татар шагыйрьләре» исемле мәкаләсе, «Гарәфә кич төшемдә», «Авырулар галәмендә», «Хәкарәт саналган мәхәббәт», «Картайдым» һ.б. исемдәге әсәрләре дөнья күрә. Сәгыйть Рәмиевнең «Уку», «Авыл», «Таң вакыты», «Мин үләм», «Алданган» кебек шигырьләрен шәкертләр аеруча яратып укыган, төрле әдәби кичәләрдә яттан сөйләгән. Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән повесте, газетаның 17 санына бүленеп, укучыларга барып ирешә. Бу әсәр Г.Тукайда каршылык тудырса да (шагыйрьнең Г.Ибраһимов белән мөнәсәбәтенә бәйле булса кирәк), Ф.Әмирхан: *«Мәдрәсәләрдә булган хәлләрне, шәкертләр тормышын сурәтләгән бер әсәр, безнең тоткан юлыбызга кирәкле, кертәбез»*, – дип, газетада бастырган. Театр тәнкыйтьчесе Кәбир Бәкернең спектакльләргә бәяләмәләре, Йосыф Акчура, Хөсәен Әбүзәров, Маһруй Мозаффария, Ризаэддин Фәхреддин, Ибраһим Бикколов кебек мәшһүрләребезнең дә кайбер мәкаләләре, милли мәгарифебезгә бәйле тәнкыйди язмалары, киңәш-табышлары игътибарга лаек.

Газетаның максаты, исеменнән үк аңлашылганча – мәгарифкә һәм уку-укыту аша татар тормышына реформа ясау. Бу турыда газетада менә ниләр язылган: *«Халкымыз арасына гыйлем-мәгариф тарату юлларын җиңеләйтү вә шул юл белән хәятебезне һәр ягыннан яңарту вә ислях итү. Яшьләребезнең, аеруча шәкертләрнең гомерләрен әрәм итә торган иске ысулларның кимчелекләрен халкыбызга белдертү вә милләтемезгә җентекле мәгълүмат биреп тору. Бу мәсьәләгә үзенең бөтен сәхифәләрен багышлаган бер генә татар гәзитәсе дә булмаганлыктан, гәзитәмездә мәшһүр мөхәррирләребезнең бик күбесе катнашачак»*. Газета яшьләргә, аеруча мәдрәсә шәкертләренә һәм мөгаллимнәргә адресланган: *«Без яшь зыялыларымызны мәдрәсәләрне шул хәлендә калдыруга димләргә түгел, бәлки иске мәдрәсәләрне ислях тугрысында хезмәт итәргә үтенәмез һәм бу исляхның тиз заманда вөҗүдкә (барлыкка) килүенә ышанамыз»*. Басманың шигаре: *«Гыйлем һәм мәгарифнең милләтебез арасына таралуы вә сәгадәте гомумия»*, – дип яңгыраган. Газета авторлары фикеренчә, фәкать гыйлем һәм мәгариф аша гына татар халкын бәхетле итеп була. Әмма 1908 ел башында чыккан кереш мәкаләдә: *«Безнең яңа елда яңа лозунгымыз: никадәр вакыт булса да – эш; сүз белән генә ерак китеп булмый икән, булырга тиеш», – дип язылган.* «Фәкать бер чара» исемле мәкаләдә: *«Милләтнең алга китүе ул милләтнең зыялыларының артуы вә шулар сәясендә икътисад мәсьәләләренең төзәлүе белән була. Зыялылар исә*

[2] Әхмәтҗанов М. Бәхтияров Вафа /Габдулла Тукай энциклопедиясе. – Казан, 2016. – Б.114.
[3] «Әлислах» / Габдулла Тукай энциклопедиясе. – Казан, 2016. – Б.67.
[4] Сафин И. «Старокулаткинский» след на земле Татарстана. – Старая Кулатка, 2016. – С.10.

түбән баскычта торган милләтнең үз арасында җитешүе мөмкин түгел нәрсә. Һәр милләт йокыдан күршеләренең җәбере вә аларның кысуы аркасында уйгана вә араларыннан фикер йөртерлек кешеләр туа, алар сәясендә милләткә кирәкле кешеләр җитештерү кайгысы вә шулар аркасында күршеләренең дәрәҗәсенә җитү, шуларны узу, кыскасы, мәдәният җәһәтеннән өскә чыгу кайгысы күрә», – дип ислях кылу, алдынгы милләтләрнең мәктәпләрендә укымышлылар җитештереп, аларны үз милләтебезгә хезмәт иттеререгә кирәклеге ассызыклана.

«Әлислах»ның библиографик күрсәткечен төзегән галим Раиф Мәрданов исляхчылыкка омтылышның юнәлешләре газетада менә болай чагылыш тапкан дип күрсәтә: 1) мәктәп-мәдрәсәләрне схоластикадан, фанатизм чолганышыннан аралап алу; 2) алдынгы рус һәм Европа мәгариф системасы үрнәгендә татар мәктәп-мәдрәсәләрен яңартып, заман таләпләренә җавап бирерлек рәвешкә китерү, дөньяви фәнннәр укыту; 3) реформаның тактикасы, тормышка ашыру юллары күрсәтелә (кадрлар мәсьәләсе, дәреслекләр һ.б.; 4) газетаны татарлар яшәгән барлык төбәккә дә тарату[5].

Басма аз тиражда чыгуга карамастан (700-1000 данә), шәкерт-мөгаллимнәр арасында бик тиз тарала. Аны кулдан-кулга йөртеп укыганнар, авторлар һәм газетага килгән хатларга караганда, аерым нөсхәләре, анда язылган фикерләрнең бөтен Россия империясендә таралганлыгы аңлашыла. Газета «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре өчен дә бер мәктәп булган, алар «Әлислах»ны укучыларга таратуда һәм башка хезмәтләрдә ярдәм дә иткән. Бу турыда Зариф Бәшири: «Замандашларым белән очрашулар» дип исемләнгән истәлекләрендә: *«Әлислах» редакциясе ул бер газета редакциясе булып кына калмады. Тора-бара ул Ка-*


۲نچی غنوارده، چهارشنبه کون
کوپیچسکی صابرانیه زالنده بولاچق
ادبیات کیچهسینك
پروغرامهسی
I نچی بولم
۱) شاکردلر صداسی .... خور
۲) عرفه کون توشمده اوقی اصلاحچی
۳) بزنی اورنسز یمانلیلر شعر اوقی اصلاحچی
٤) شعر قرغزچه جرلی قرغز
٥) علی برله ولی اوقی بالغون
II نچی بولم
۱) تاتار شعر خور
۲) طاڭ وقتی اوقی سبکتگین
۳) موزیقه » » » »
٤) خاتون قز عالمندن اوقی مرادوا
٥) خدابارغان مارشی صارتچه جرلی صارت
III نچی بولم
۱) بحیللهشو .... خور
۲) عالم اسلام حقنده اوقی * * *
۳) اصلاحچیلردن اوقی اصلاحچی
٤) أی خاتونلار! .... خور
کانسیرتدن صوڭ ساعت ۳ که قدر
تانسهلر بولاچاق
کیچه نڭ ساعت ۸ده باشلانور.

2 нче гыйнварда чәһаршәнбә көн Купеческий Собрание залында булачак әдәбият кичәсенең программасы. 1 нче бүлем: 1) «Шәкертләр садасы» – хор; 2) «Гарәфә көн төшемдә». Укый – исляхчы; 3) «Безне урынсыз яманлыйлар». Шигырь укый – исляхчы; 4) Шигырь. Кыргызча. Җырлый – кыргыз; «Гали берлә Вәли». Укый – Ялкын. II нче бүлем: 1) «Татар». Шигырь. Хор; 2) «Таң вакыты» – укый Сәбуктәгән (С.Рәмиев); 3) Музыка ; 4) Хатын-кыз галәменнән – укый Морадова (С.Коләхмәтова); 5) «Ходаяр хан маршы». Сартчы җырлый. III нче бүлем: 1) «Бәхилләшү» – хор; 2) «Галәм ислам» хакында – укый...; 3) Исляхчылардан – укый исляхчы; «Ай, хатыннар!» – хор. Концерттан соң сәгать 3кә кадәр тансәләр булачак. Кичә нәкъ сәгать 8дә башлана.

[5] Мәрданов Р. «Әл-Ислах»ның библиографик күрсәткече. – Казан, 1991. – Б.7.

зандагы бөтен алдынгы, аек фикерле татар яшьләренең җыелышып, төрле киңәшләр, фикер алышулар урыны булып китте. Анда яшерен киңәшләр үткәрелгән чакларда, әлеге игъдади шәкертләре, полиция килеп басмасын өчен, урамда күзәтчелек эшен алып баралар иде. Һәр көнне дәрестән бушагач та алар шунда китәләр, алдынгы яшьләрнең сүзләрен, фикерләрен, үзара сүз көрәштерүләрен тыңлыйлар, шулай итеп җан азыгы алып кайталар. Бигрәк тә Фатих Әмирхан һәм Габдулла Тукайлар иҗат эшенә омтылган яшьләргә шул юлда ярдәм күрсәтәләр иде», – дип язып калдырган[6].

«Әлислах»та мәктәп-мәдрәсәләрне, татар җәмгыятендәге тискәре күренешләрне тәнкыйтьләгән язмалар шактый басылган. Шуларның берничәсен мисалга китерик: *«Хәзергә кадәр Сәйфи мелланың үзе кеби бик мәһабәт. Урынында торадыр, фәкать ишекләре бикле. Хәзрәт «Макарья»дан икешәр сәгатьле вәгазьләр сөйли-сөйли арып кайтып ял итә булырга кирәк. Хәер, мондый хәзрәтләргә ял итәргә күптән вакыт! Милләт өчен тик торулары файдалырак булыр».* («Сәйфи мелла мәдрәсәсе»)*; «Мәдрәсә үзе инсафка килеп ислях кыйлмаса, бу мәдрәсә дә бетә, шәкертләрнең исе дә калмый, дип хөкем кылырга хәзердән үк мөмкиндер».* («Түнтәр мәдрәсәсе»)*; «Казанда уннан артык татар фәхешханәләрен баетучы сез түгелме соң? Шәһәрнең кай йирләрендә булса булсын, пивоханәләрнең дәвамын тәэмин итүчеләр вә шуларга йөзләр-меңнәрчә акча калдыручылар, сезләр булмый, кемнәр?»* («Мөтәгассыйб Казан татарларына ачык хат»[7]).

Кайбер мәкаләләрдә татарларның гыйлемгә сәләтлелеге искәртелә. Мәсәлән, Йосыф Акчура: *«Уку-язу, дин белү, хәтта гыйлем мөселманнар арасында христианнарга караганда артык иде. Кайбер җирләрдә, мәсәлән Русиядә хәзергә кадәр мөселманнарның язу танулары руслардан өстендер. Казан губернасында татарлар руслардан артык язу таный, дияргә мөмкиндер»*, – дип билгеләп үтә.

М.Әхмәтҗанов тикшерүләренә караганда, «Әлислах» редакциясе 1907 елның азагыннан 1908 елның маена кадәр «Болгар» кунакханәсенең 12 нче бүлмәсендә урнашкан була, ә аннары, газетаның матди хәле авырайгач, Фатих Әмирхан мөхәррирләрне җизнәсе (апасы Мәрьямнең ире) Шәкүр Апаков йортына күчерә[8]. «Әлислах» газетасы «Матбагаи Кәримия»дә басылып, халыкка таралган.

Газетаның финанс чыгымнарын нигездә Вафа Бәхтияров үзе күтәргән. Аеруча 1907 елда, Фатих Әмирханның параличлануы сәбәпле, күп эш аның җилкәсенә йөкләнгән. «Әлислах»ның Матди хәлен тәэмин итү эшенә туган авылы Яңа Зимничәдә (хәзерге Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы) яшәүче үзенең нәселеннән булган зыялыларны, имам-мөәзиннәрне дә җәлеп иткән. Вафа Бәхтияров кайбер саннарның азагында *«гәзитәмезнең хидмәтенә сәбакать итмеш»* һәм *«чит шәһәрләрдә гәзитәмезнең интишарына (таралуына) гайрәт»* иткән, *«Әлислах»ның кувәи маддиясен (матди хәлен)»* арттырган *«ачык фикерле имамнар»*га, мәдрәсә мөгаллимнәренә һәм шәкертләренә рәхмәтен белдерә. Абунәчеләрдән, шулай ук «Әлислах» оештырган төрле әдәби кичәләрдән һәм башка нәшриятларга рус, гарәп һәм төрек телләреннән китаплар тәрҗемә итүдән кергән акча да газета чыгаруга, аның хезмәткәрләренә түләүгә тотылган, дип уйларга нигез бар. Газетаның соңгы, 68 нче саны 1909 елның 22 июлендә басылып чыга.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[6] Зариф Бәшири. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б.59-60.
[7] «Казан шәкертләре» имзасы белән басылган бу мәкалә, Фатих Әмирханныкы буларак, язучының сайланма әсәрләренә кертелгән.
[8] Әхмәтҗанов М. «Әлислах» идарәсе урнашкан биналар/ Габдулла Тукай энциклопедиясе. – Казан, 2016. – Б.68.

Безнең мирас №2 февраль 2018

Сафакүл

Узган елның җәендә Курган өлкәсенең Сафакүл һәм Әлмән районнарына сәфәребез турында алдагы санда язган идек. Шунда күргән-белгәннәр белән сезне таныштыруны дәвам итәбез. 2010 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Сафакүлдә 3629 кеше яши. Шулар арасында сан ягыннан беренче урынны татарлар (60%), аннан кала урыслар (23,9%) һәм башкортлар (15,2%) алып тора. Район буенча исә башкортлар күбрәк (43%), икенче урында – татарлар (33,7%), ә аннары урыслар (21,3%). Карасу, Мансур, Сөлекле һәм Күбәкәй авылларында татарлар гына, ә Атҗитәр һәм Боровичида башкортлар белән урыслар да яши.

1932 елның 1 августына район һәм авыл советларында эш кәгазьләрен милли телләрдә алып баруны гамәлгә кертү, мәктәпләрдә тулысынча татарча яки башкортча укытуга күчү турында мәҗбүри канун булган. Җитәкчеләрдән татар һәм башкорт телләрендә укый-яза белү катгый таләп ителеп, белмәгәннәргә өйрәнү өчен нибары бер ай вакыт бирелгән. Район газетасы ике телдә басылган, мәдәният коллективлары гөрләп эшли башлаган, Татарстан һәм Башкортстаннан дәреслекләр, методик ярдәмлекләр китертелгән, махсус курслар оештырылган.

Әмма 1940, аеруча 50 һәм 60 нчы елларда вазгыять кискен үзгәрә. Милли телләр, мәдәният арткы планга күчә. Район газетасының татар редакциясе ябыла, Сабан туйлары үткәрелми башлый. Картларның каршылык күрсәтүенә карамастан, иң соңгы мәчет тә сүтелә. Әлегә күренешләр район халкына да йогынты ясый, аларда туган телгә карата: «Нәрсәгә миңа башкорт теле?» яки «Нәрсәгә миңа татар теле?» – дигән битараф караш формалаша. Хәтта күп мәктәпләрдә фәннәрне укыту ата-аналар теләге белән «ирекле рәвештә» урыс теленә күчерелә. Татар авылындагы мәктәптә аксакалларның берсе: «Урысча укытыйк! Минем балам һәм оныгым сукыр шәйтан булганчы, күзе ачык шәйтан булсын!» – дип әйтә һәм эти-әниләр бертавыштан урысча укытуны яклап тавыш бирә. Татар теле фән буларак укытылса да, соңрак анысы да онытылган.

1980-1990 елларда районда яңадан милли җанлану сизелә. Кайбер мәктәпләрдә татар һәм башкорт телләре фән буларак укытыла, милли бәйрәмнәр, Сабан туйлары үткәрелә башлый, авылларда, район үзәгендә сәнгать коллективлары оеша. Татарстан һәм Башкортстан Республикалары белән рухи-мәдәни хезмәттәшлек ныгытыла.

НИ ӨЧЕН САФАКҮЛ?

XVIII гасырның 80 нче елларында бу җирләргә Сафа Юмагулов исемле крестьян күчеп килә. Авылдашларына сөйләвенә караганда, аның гаиләсе кайчандыр Идел буеннан китеп, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Верхнеуральск районында яшәгән, ә бирегә исә яңадан яхшырак җирләр эзләп килгән икән.

Шулай итеп, мосафир каен урманы һәм биек камышлар белән уратып алынган искиткеч гүзәл күл буена килеп чыга. Балык, киек җанварлар, кош-корт гаять күп, суы чиста һәм тәмле... Шуннан бирле бу күлне «Сафа күле», ягъни «Сафакүл» дип атап йөртә башлаганнар. Табигатьнең хозурлыгына таң калган Сафа Юмагулов шунда яшәп тә калырга уйлый, землянка, атлар өчен киртә корып куя. Бу якларга элегрәк килеп, биләмәләргә хуҗа булган Ямар исемле кеше белән җирне арендалау хакында килешеп, кире кайтып китә. 1781 елда бирегә бер төркем дус-ишләре белән килә һәм күлнең көнчыгыш яр буенда йортлар төзелә башлый. Шулай итеп, 1782 елда кечкенә генә авыл барлыкка килеп, аңа Сафакүл дип исем кушалар. Шул ук елда Сафа гаиләсендә авылның беренче кешесе туа. Аңа Габдрахман дип исем кушалар. Акрынлап Сафакүл авылы үсә, 1816 елда беренче мәчет салына. Мәчет өчен ташны Уралдан алып кайталар.

Күпмедер дәрәҗәдә бу риваятьне авыл зиратында Габдрахман Юмагулов каберенә куелган таш та дәлилли. Ул 1845 елда 63 яшендә вафат булган. Дөрес, әлеге риваятьне инкяр итүче, Сафакүл исемен саф сулы күлгә генә бәйләп аңлатучы галимнәр дә бар. Бу турыда киләсе саннарыбызның берсендә язарбыз.

МУЗЕЙ

Сафакүл тарихи биналарга бай түгел. Шуларның берсе Карасу волость идарәсе старостасы Закир Хөсәенов 1890 елда салдырган агач бина. Соңрак бу йортны Мартыновкага,

ә аннары Сафакүлгә күчереп салганнар икән. Совет чорында анда партия вәкилләре, ә соңрак балалар бакчасы эшли, сугыш чорында Ленинградтан эвакуацияләнгән балалар яши. Алар туган якларына кайтып киткәч, бинага мәктәп, Пионерлар йорты, яңадан хакимият оешмалары урнаша. Ә инде 1982 елның декабрендә биредә «Трудовая слава» газетасы мөхәррире, Бөек Ватан сугышы ветераны, төбәкне өйрәнүче Сафиулла Госман улы Иргизов тырышлыгы белән тарих-этнография музее ачыла. Гасырлар тузанын сеңдергән, иңенә тарих йөген салып, җиргә иңеп баручы, инде берничә ел ремонттөзекләндерүне күрмәгән борынгы әхрамны табу безгә әллә ни авыр булмады. Башка районнардагы кебек үк, ул да Сафакүлнең үзәгендә.

Музей мөдире Идия Гарифулла кызы

Музейдан бер күренеш

Үгез богавы

Музей мөдире Идия Гарифулловна, актлар залында бинаның тарихы белән таныштырганнан соң, безне «Крестьян йорты» залына алып керде. Биредә бар да безнең район музейларындагы кебек: милли киемнәр, читекләр, шундагы халыкның гореф-гадәтләрен чагылдырган төрле предмет, савыт-саба, туку станогы, киле-кисап, йон эрләгеч һәм башкалар. Әмма бер крестьян йортында өч милләтнең әйбере тупланган: татар, башкорт һәм, әлбәттә, урысларныкы.

Алдагы заллар Октябрь түнтәрелеше вакыйгаларына, районның үсешенә, авыл хуҗалыгы һәм Бөек Ватан сугышына багышлана. Алар арасында биш сугышчан орден кавалеры Гыйният Ибраһимов, күпләрнең беренче мөгаллиме Мәрхәбә Ибраһимоваларга багышланган экспозиция белән танышырга мөмкин. Районның флора һәм фаунасына багышланган экспозиция мәктәп балалары өчен иң кызыгы икән. Биредә урманда, далада, күлләрдә, сазда яшәүче җанварларның, киек кошларның 60тан артык карачкысы тупланган. Аларны музей экспонаты рәвешенә китерү, фән телендә әйткәндә, таксидермия белән Сафакүлдә яшәүче аучы Габдерәшит Нагуманов шөгыльләнә.

«КАЗАННЫҢ ЯРДӘМЕН ТОЕП ЯШИБЕЗ»

Сафакүлдә безне татар-башкорт үзәгенең җитәкчесе Земфира Загурдаева каршы алып, озатып йөрде.

– «Казанның ярдәмен тоеп яшибез», – диде ул.

– Фольклор фондыбыз бар. «Җидегән чишмә» татар традицон мәдәните фестивале оештырабыз. Анда Сафакүл районыннан барлык фольклор төркемнәре дә җыела. Карасудан – «Ак каен», Сафакүлдән – «Ләйсән», Сөлекледән – «Сандугач», Мансурдан «Салават күпере» төркемнәре уңышлы чыгыш ясый. Бу фестиваль башта район күләмендә генә үткәрелә иде, соңрак өлкә дәрәҗәсендә уздырыла торган бәйрәмгә әверелде.

Инде икенче мәртәбә «Чалгы бәйрәме» уздырдык. Ирләр һәм хатын-кызлар аерым ярышты, барлыгы сигез команда катнашты. Шунда ук «Урман ашы», «Кыр чәе» бәйгеләрен дә уздырабыз, концерт, милли уеннар мәйданы да гөрли. Бу бәйрәмне алдагы елда ТР Мәдәният министрлыгы грантына оештырган идек, быел исә матди якны җирле хәйриячеләребез кайгыртты: Мәскәүдә яшәүче эшкуар Марс Гайнетдинов һәм Урал арты татарлары конгрессының җитәкчесе Марат Юнысовларның ярдәме зур булды.

Һәр авылда диярлек хатын-кыз клублары эшли. Балаларны татарча җырларга һәм биергә өйрәтәбез. «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасының җирле бүлекчәсен оештырырга уйлыйбыз. Казанның, Конгрессның, Фәнзилә Хәкимовна җитәкчелегендәге татар традицион мәдәниятен үстерү үзәге белгечләренең ярдәмен һәрвакыт тоеп яшибез.

Безнең мирас №2 февраль 2018

«ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ КЕРТЕРГӘ ТЫРЫШАБЫЗ»

Сафакүл районы хакимияте башлыгы **Рәшит Хәернәсов** белән дә очраштык. Ул безгә районның икътисади тормышы, киләчәге һәм татар теле турында сөйләде:

– Белүегезчә, Сафакүл районы бай төбәкләрдән түгел. Аның иң зур байлыгы – эшчән кешеләре. Халык биредә элек-электән авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгән, колхоз-совхозлар гөрләп эшләгән. 1978 һәм 1986 елларда районыбыз игенчеләре атаклы агроном Т.С.Мальцев исемендәге премия лауреаты булган. Хәзер авыл хуҗалыгын крестьян-фермер хуҗалыклары ярдәмендә саклап калырга тырышабыз. Тиздән теплица хуҗалыгы, тегү цехы, кәҗә фермасы, форель балыгы җитештерә торган оешма ачарга уйлыйбыз. «Сафакүл» балык хуҗалыгы үз эшчәнлеген дәвам итә. Боровичида линда һәм Күбәкәйдә Урал токымлы казлар үрчетә торган фермалар яңа гына төзелеп, эшен башлап җибәрде. Гомумән, бездә татар-башкорт халкы гомер буе каз асрарга яратты, ялкаулар гына бу эш белән шөгыльләнмидер. Кош гриппыннан вакцина ясаганда районда 75 меңнән артык каз булуын ачыкладык. Бирегә кунакка килүчеләр күлләр тулы казларны күреп гаҗәпкә кала. Күлләр – Курган өлкәсенең байлыгы. Сафакүлдә генә дә 200дән артык күл бар. Районның киләчәге өметле, дип уйлыйм. 500 балага исәпләнгән мәктәп тә төзелеп килә.

Мин Мансур авылында 9 нчы класска кадәр барлык фәннәрне дә татарча укыдым, әмма соңрак татарча уку бетте. 9-10 классларны Сафакүлдә – урысча. Хәзер яңадан мәктәпләргә татар теле дәресләре кертергә тырышабыз. Әмма моңа, беренчедән, ата-аналар каршы, икенчедән, белгечләребез бик аз. Элек Татарстан һәм Башкортстаннан килгән укытучыларыбыз пенсиягә чыкты. Татарстан белән элемтәләр урнаштырабыз. Бу эштә милләттәшебез Марат Юнысовның ярдәме зур. Һичшиксез, мәктәп укучылары татар телендә аралаша белергә тиеш. ■

«Сафакүлдә казларны ялкаулар гына асрамый»

Безнең мирас №2 февраль 2018

ЯДӘЧ ҺӘМ ЯДӘЧИЛӘР

(Бер фараз)

Ринат Фәхретдинов



Ядәч уенында куллана торган оча сөяге

Татар халкы гомер-гомергә уеннарга бай. «Йөзек салыш», «Чума үрдәк, чума каз» (кайсыбер төбәкләрдә «Капкалы», «Су агу» дип тә билгеле), «Буяу сатыш», «Ядәч» уеннары әле дә популярлыгын югалтмый. Туйларда, юбилейларда һәм башка мәҗлесләрдә халыкны җәлеп итә торган мавыктыргыч, үзара ярыштырулы уеннар күбрәк уйналса, «Ядәч» уены исә, үтә гадилеге аркасында, көнкүрештә киң таралыш тапкан. Чөнки бу уен өчен шарт булып кошның – күпчелек очракта тавыкның – оча сөяге һәм ике кешенең булуы да җитә. Уен башланыр алдыннан шаһитлар каршында җиңүчегә бүләк турында килешенә. Октябрь революциясенә кадәр бай кешеләр бүләккә дип хәтта ат бирергә вәгъдә иткән, ә хәлсезрәк кавем тавык, йә булмаса пар чабата белән чикләнгән. Вәгъдә итеп тә бирелмәгән бүләк намуссызлык билгесе саналган һәм шартны үтәмәгән кеше, әлбәттә, җәмәгать алдында хөрмәт казанмаган.

Уенны уйныйбыз, тик ни өчен ул уен «ядәч» дип атала соң?

Борынгы заманнарда безнең төрки бабаларыбыз Күк Алласына – Бөек Тәңрегә табынган. Бу күренеш татарның «Күрше хакы – Тәңре хакы» дигән хикмәтле мәкалендә чагылыш тапкан. Тәңречелек дине мәҗүсилекнең бер төре булып тора. Ә мәҗүсилек сихерчеләргә, багучыларга бик тә бай. Әйтергә кирәк, төрки кавемнәр сихерчеләренең бер төркемен ***ядәчиләр*** дип йөрткәннәр. Атаклы галим Лев Гумилев «Борынгы төркиләр» дигән фәнни хезмәтендә, борынгы кытай чыганакларына таянып, ядәчиләрнең табигать көчләрен – суык, яңгыр, йә булмаса кар яки ком буран-



нарын кузгата торган кешеләр булуы турында яза. Ядәчиләрнең уникаль сәләтләре табигать көчләрен генә уятудан һәм аларны үз файдаларына куллланудан гына тормаган. Мәсәлән, бөек шагыйрь Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә төркиләр белән яу алдыннан фарсы гаскәренең җитәкчесенә – Бахрамга куркыныч төш керә. Төшендә ул төрки сугышчыларының, арысланга әйләнеп, фарсы гаскәрләрен тар-мар иткәннәрен күрә. Шулай да фарсылар сугышта җиңүгә ирешә. Яудан соң әсир ителгән төркиләр арасында сихерче дә булганы ачыклана. Ул төшне Бахрамга махсус җибәргәнен раслый. Әлбәттә, безнең **матди тормыш** хөкем сөргән җәмгыятебездә мондый шаккатарлык сәләткә ия булган сихерчеләрнең кайчандыр бу дөньяда яшәгәнлегенә ышанасы килми.

Әйдәгез, ядәч уенын күзәтик. Ике уенчы иң башта оча сөяген тартып сындыра. Бу уенның башланганын аңлата. Уенда катнашучылар бер-берсенә ни генә бирмәсен, кулына әйбер алучы алдан «исемдә», дип әйтергә тиеш. Әгәр дә кулына әйбер алучы бу сүзне әйтергә онызта икән һәм әйбер бирүче «ядәч», дисә, ул җиңүгә ирешкән була. Хәзер исә уенга йомгак ясыйк. Ике уйнаучы да бер-берсенең хәтерен оныттырырга, «җуйдырырга» тырыша. Ядәч уены борынгы сихерчеләр-ядәчиләр кулланган ысулны кабатлый түгелме? Кешенең хәтерен җуйдыруны борынгы төркиләр генә түгел, кайбер башка халыклар да кулланган. Мәсәлән, монгол кабиләләре төркеменә кергән жужаннар, кулга алынганнар арасыннан яшь һәм көчле сугышчыларны сайлап, аларның чәчләрен кырдырып һәм яңа суйган терлек тиресен башларына урап, кул-аякларын бәйләп, җәйнең кызу вакытында далага ташлый торган булган. Эссе кояш астында уралган тире берничә көннән, кибеп, башны каты кыса башлаган, ахырда, кеше сусаудан һәм коточкыч баш авыртуыннан йә үлемгә дучар булган, йә бөтенләй хәтерен җуйган. Андый кешеләр даладан килеп алган яңа хуҗага тугры эт кебек хезмәт итә торган була. Хәтерләрен җуйган кешеләрне ***манкортлар*** дип атаганнар. Африканың кайбер кабиләләрендә кешене клиник үлемгә дучар итеп, берничә мизгел арасында яңадан сулышын һәм баш миенең эшен торгызганнан соң да шундый ук нәтиҗәгә ирешкәннәр. Андый бәндәләрне ***зомби*** дип йөрткәннәр. Күрәсең, безнең төрки бабаларыбызның кешенең хәтерен җуйдыру методикасы югарыда китергән мисалларга караганда күпкә камилрәк булгандыр. Әгәр дә, ядәч уены төрки сихерчеләрнең ысулын кабатлаучы фактор булып тора, дигән фараз дөрес булса, ядәчиләр кешенең аңына кабат-кабат һөҗүм ясап, аның хәтерен киметә, йә булмаса, бөтенләй җуйдыра алганнардыр.

Ислам дине ядәчи сихерчеләргә каршы чыгып, кешеләргә сихер куллануны тыя. Бу, чын мәгънәсендә, мәрхәмәтлелек акты булып тора. Чөнки сихер аркасында күпме кеше саулыгыннан ваз кичкәнлеген бер Аллаһы Тәгалә генә беләдер. Ислам сихерне куллануны тыю гына түгел, ә аннан саклану өчен «Фәләкъ» («Таң»), «Ән-нәс» («Кешеләр») сүрәләрен укырга тәкъдим итә.

Ядәчиләр кебек сихерчеләр төрки бабаларбыз белән тарих битләрендә калса да, аларның кайтавазы ядәч уенында сакланган. Уенның үзенә килгәндә, аны олысы да, кечесе дә рәхәтләнеп уйный бирә. Хөрмәтле укучым, ә син ядәч уенын уйныйсыңмы? ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

ТӘҢРЕ, ДИНГИР ВӘ УМАЙ...

Айрат Галимҗанов

Борынгыдан килгән ышанулар

Себер татарларында утка табынуның (утны хөрмәтләүнең) борынгы гореф-гадәтләре бар.

Әйтик, утка төкерү тыела; ут шулай ук чистарыну чарасы буларак карала, шуңа күрә эпидемияләр вакытында алар ут аша сикерүне гадәт иткән.

Гагаузлар, алтайлылар, чуашлар, болгарлар, кумыклар һәм башка төрки халыклар елның беренче яшен яшьнәгән вакытында төрле ырым, йолалар башкара.

Башка төркиләр кебек үк, балкарлар һәм карачайлар андый чакта зур учаклар ягып, шулар аркылы сикерүне гадәткә керткән.

Кырым татарларының яшенгә табынулары учак тирәли үткәрелгән тамашаларда һәм ут аша сикерүдә чагыла.

Хакаслар (Абакан татарлары) җәйге **«Тигир тайи»** бәйрәмен үткәргән вакытта,

*Ахыры. Башы журналының 1 нче (2018) санында.

бергә тәкәләр чалып бәйрәм иткәндә, белтир вә качин ыруглары каенлы Изге Тауда ике зур учак ягалар да шуларның берсенә үзләре эчәсе хәмернең берничә тамчысын тамызалар (нәкъ чуашлардагы кебек!).

Мондый бәйрәмнәргә хатын-кызларны катнаштырмыйлар.

Төркиләрнең гореф-гадәтләрендә нәкъ шулай ук Суны данлау ырымнары һәм гадәтләре чагыла.

Әйтик, алтайлылар Су иясе – **«Суу ээзи»** – барлыгына ышанган һәм аны хөрмәтләү билгесе итеп, ат чалган.

Кырым татарлары, эңгер-меңгер төшкәч, коедан су алмыйлар. Әгәр дә инде бик кирәк икән, су чыгарыр алдыннан Су иясеннән **(«Сув анасы»)** рөхсәт сораганнар.

Балкарлар исә аны элек-электән «Суу анасы», казан татарлары – «Су анасы» дип атап йөрткән. Тувалылар балык тотарга керешкәнче елгаларга, күлләргә һәм аларның хуҗалары-ияләренә – **«Суг иязи»**енә багышлап дога кылган.

Умай образы тасвирланган борынгы колак алкасы

Хакасларда ул «Сух ээзи» («Су иясе») дип йөртелгән.

Ислам дине кануннарына карамастан, себер татарлары хәтерендә борынгы төрки алиһәсе Умай (Ымай) турындагы хатирәләр сакланып калган.

Себердәге тар татарлары карашынча, Умай – һәр кешедәге тән һәм рух саклагычы. Шор вә тубыл татарлары Умай төшенчәсен сабыйның кендек бавына тиңләгән, ә борынгы төрки телдә «Умай» төшенчәсе мондый мәгънәләргә ия булган:

1) Соңгылык (бала чүбе), бала урыны, ана карыны;

2) Алиһәнең үз исеме.

Тар татарлары күзаллавынча, Умай кешенең тәнендә аның гомере буена урнаша. Кумандиннар фикерләвенчә, Умай баланың ана карынында яралган чагында ук була һәм баланы дөньяга килгәннән соң да, бала чагында да, бөтен гомере буе да саклый.

Хакасиянең Аскиз районындагы белтирләр баланы өч яшенә кадәр «Умай» сүзе белән атап йөрткән (шунысы да кызык: япон гаиләләрендә өч яше җиткәнче баланың кылган галәмәтләренә игътибар итмиләр); хакас гаиләсендә фәкать өч яше тулгач кына кешенең җанын «кут» дип атаганнар.

Алтай шаманнарының «кут» дигән чакырмаларында рух дигән мәгънә бар. Мондый «кут»-«кот» дигән сүзне казакълар, башкортлар, казан татарлары да куллана. «Кот» гыйбарәсенең бөтен төрки халыкларында «җан» дигән мәгънәдә йөргәнлеге гомум мәгълүм.

Тувалыларның «кут» – җан мәгънәсен аңлаулары яшәү көчен белдерә, ә якутларда ул җаннарның берсе дип кабул ителә.

Хакас камнары (шаманнары) югары Аллаларына болай дип тәкъбир кылган:

Ай астында халык яшәмәс,
Чирләр һәм газаплар ташланмас.

Мал-туар үләр, чәчкәннәр шытмас,
Синсез бер җан да авыз-сүз дәшмәс.

(«Образцы народной литературы тюркских племён», Н.Ф.Катанов, часть 9-я, С.-П., 1907, с.608-609)

Гыйбадәт кылуда катнашкан хакаслар үз тирмәләренең төнлегенә бүрекләрен куеп, күктән күбрәк кот килгәнен теләгәннәр. Хакасларда кавем дәвамы һәм кешеләргә «кут» бүләк итүе таш балбаллар – менгирләр алдында үткәрелгән.

Татарстанда «Мәңгәр» исемен йөрткән авыллар булуы да очраклы түгел.

Теленгитлар һәм себер татарларында яман көчне эзәрлекләүче **Натигай (Нацигай)** атлы рухка ышану сакланып калган. Ул көчле күк күкрәве вакытында яшьнәгән аркылы-торкылы яшен сурәтендә гәүдәләнгән.

Кыпчаклар шулай ук Натигайга ышанып яшәгән. Бу хакта итальян сәяхәтчесе Марко Поло язып калдырган.

Төркиләрнең тылсымга ышанулары үсемлекләргә карата да сакланып калган. Идел буе, себер татарлары һәм алтайлылар миләш белән артышны хикмәтле көчкә ия, дип санаган.

Себер татарлары биеклекләре белән аерылып торган каен һәм наратны үз иткән, балкарлар белән карачайлар исә аерым үскән зур нарат, кыргый грушаларны (армутларны) хикмәтле санаган.

Хәзерге Дагыстанның төньягында – һуннарның әүвәлге таш калалары Варочаннан ерак түгел генә һуннар Тәңренең гәүдәләнеше дип санаган бик зур бер имән агачы үсеп утырган (сүз уңаеннан әйткәндә, Америка индеецлары шулай ук имәнгә табынган булган).

Америкадагы индеецлар сыман ук, себер татарлары да тотемизмга (кешеләр төркеменең ырым ышанулары һәм гореф-гадәтләре белән бергәлегенә) тугры булган. Шуның нәтиҗәсендә, әйтик, себер татарлары кавемендә «аю тухум» («аю токымы»), «торна тухум» («торна токымы»), «аккош тухум» («аккош токымы») очрый.

...Себер татарлары авылларында карга, кырмыска, сарык, бүре, үгез һәм бака дигән аз санлы кушаматлар күзәтелә.

Аккош саха-якутларда да изге кош саналган, ә аюның тотемик культы киңрәк аралыкта – якутлар, алтайлылар, теленгит, шор, хакас һәм тувалылар арасында саклана.

Башкортларның катай кабиләсендә козгын ыруы да, торна ыруы да булган. Хәзерге заман кореялеләр Конвондо провинция-өлкәсенең тотем мәгънәсен аю дип санап, үз итәләр.

Кюсю утравындагы японнар арасында да аю өстенлекле мәгънәгә ия.

Алтай шагыйре Борис Укачин аюга түбәндәгечә хөрмәт күрсәтә:

Алтай ерткычларының башчысы
Акыллы, хөрмәтле Аю.
Алтай ерткычларының башчысы
Куркыныч, табынган Аю!

Себер татарлары төрле чирләргә, яман рухларга, яшен, күк күкрәүләргә каршы аюның азау тешләрен һәм тырнакларын тагып йөрткән, кызларның чибәрлеген һәм сәламәтлеген саклау өчен төрле төстәге тасмалар, муенсалар таккан, ә балаларның маңгайларына, күз тимәсен өчен, корым сөрткән.

«Күз тимәслеккә» себер татарлары күпчелектә зәңгәр төс кулланган. Бу түгәрәк төймә, берәр бакыр җисем ише әйбер булган.

Карачайлар балаларга күз тимәсен дип аларның җәймә-төрүләренә бүре, кыргый мәче тырнаклары, керпе энәләре, эт танавы сөякләре, кучкыл төстәге тукыма кисәкләре, перламутр (сәдәф) тегеп куя торган булган.

Башкортларда, яман рухлар – албастылар басмасын өчен, йөкле хатынның киеменә бер әчмуха каз мамыгы теккәннәр яки бусагасы төбенә бүре башы салганнар.

Баланы бишеккә салу алдыннан, карачайлар, ырымнары буенча, башта ул бишеккә мәче яки эт баласын иңдереп, сабыйга «бәхетле киләчәк» теләгәннәр, баш турысына бүре тырнаклары, селәүсен йоны, камыр агачы (боярышник) ботагы, адәми зат кулының сурәте төшерелгән камыр ашы, киптерелгән кендек бавы кисәге салынган төенчек, ә баш астына пычак (малайларга) яки кайчы (кызларга) куйганнар.

Тимер әйберләр баланы шәйтаннар бумасын йә үзләренә алып китмәсен өчен куелган.

Каенана корбанга чалынган терлекнең канына бармагын манчыган да сабыйның яңагына шуның кан эзен төшергән.

Күз тиюдән һәм яман рухлардан саклар өчен, баланың баш түбәсендәге чәч катлавына сумала төерчекләре ябыштырганнар, ә бүре йоныннан тасма үреп, шуны бораулап тишелгән сарык сөяге һәм тоягы белән бергә бишекнең сабый башы турысындагы сиртмәсенә бәйләп куйганнар.

Карачайлыларда тылсымлы сүз һәм язмалар мөһим урын алып торган. **«Байчы»** («байлык китерүче»), дисең икән, явыз рухны куркытып җибәрер өчен шул җиткән.

Карачай ышануынча, өйдә, йортта байчы, йорт иясе, йорт башлыгы, озын чәчле («чачлы») су анасы, урманда исә агач кешесе бар икән. Казан татарларында да чәч белән бәйле төрле ышанулар булган...

Татар хатыннары, сәламәт булыр вә озак яшәр өчен, көзгегә карап чәч тараганда бу сүзләрне әйткәннәр:

Нурлы йөзем караем,
Чәчләремне тараем,
Тау буйларын ураем,
Су буйларын буйлаем,
Урманнарга бараем,
Озын чәчләрем кебек
Озын гомер сораем».

Карачайлылар белән уртак булган болгар һәм казан татарлары арасында Ана культының охшашлыгы сизелә: Йорт анасы, Су анасы, Кое анасы, Җил анасы, Басукыр анасы һәм башкалар.

Җир тәңресе, димәктән, карачай, балкар кешеләре абзар-кура, йорт салыр, тергезер алдыннан, ул урында Җир тәңресенә, Җир иясенә багышлап сөтле савыт калдыра торган булганнар.

Шулай итеп, төрки халыкларның карашлары, Җиргә генә юнәлмичә, Күккә дә юнәлгән булган.

Әйе, төркиләрнең дөньяны аңлаулары салават күпере төсләре кебек күптөрле булган. Тик шул ук вакытта төрки халыкларның төрле кавемендә бу мәгълүм бер уртаклыкка да ия. Җыеп әйткәндә, барча төрки кавеме, японнарның синтоизмы төсле, борынгыдан ук уртак диннәренә, гасырлар буена тайпылмаслык ышануларына ия булган.

Менә шушы уртак күчәрдә бер тәгәрмәч булып әйләнгән сурәттә, ата-бабаларыбызның киләчәк буыннар, ягъни безнең өчен кабызган учагы тирәли бергә-бергә җыелсак кына, киләчәгебез булыр! ■

БАЛКАР ХАЛКЫНЫҢ СӨЕКЛЕ ШАГЫЙРЕ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара.

Күренекле балкар шагыйре, СССР һәм Россия Дәүләт премияләре лауреаты Кайсын Кулиев 1917 елның 1 ноябрендә Югары Чегем дигән авылда аучы һәм терлекче гаиләсендә туа. 10 яшендә беренче шигырен яза. 1935 елда Мәскәүгә килә һәм А.В.Луначарский исемендәге Театр институтына (ГИТИС) укырга керә. Берүк вакытта А.М.Горький исемендәге Әдәбият институтында да лекцияләр тыңлый.

1940 елда Нальчикта К.Кулиевның «Салам, эрттенлик!» («Исәнме, иртә!») дигән тәүге шигырьләр китабы дөнья күрә.

Ул 1945 елда Кыргызстанга килеп (1944 елда Сталин фәрманы белән балкар халкы Кыргызстанга сөрелә), Язучылар берлегендә эшли башлый. Бик күп шигырь яза, әмма берсен дә матбугатта бастыра алмый. Шул сәбәпле, тәрҗемә итү белән генә шөгыльләнергә мәҗбүр була. 1956 елда Нальчикка кайта һәм чын-чынлап иҗат эшенә чума. Бер-бер артлы «Тау» (1957), «Икмәк һәм роза» (1957), «Мин таулардан килдем» (1959) дигән китаплары басыла.

К.Кулиевның «Яралы таш» дигән шигырь китабы 1966 елда – РСФСР Дәүләт премиясенә, «Җир китабы» исә 1974 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек була.

Шагыйрьнең рухи остазлары – Низами, М.Лермонтов, А.Пушкин, Г.Тукай, Ф.Тютчев, Д.Байрон, Г.Лорка, Б.Пастернак, А.Твардовский.

«Кешеләргә сөйлим» (1985) – К.Кулиевның үзе исән чагында басылган соңгы китабы. 1985 елның 4 июнендә шагыйрь вафат була.

Кайсын Кулиев шигырьләре

БЕР ХАТЫН ЕЛГАДА КОЕНА

Кояштан алтын нур коела,
Бер хатын елгада коена.

Иңнәре кояшта елкылдый.
Су чәчрәп, уйната дулкынны.

Тын калган ярдагы чирәмнәр,
Тын калган ташлар һәм тирәкләр.

Сак кына кагылып иңенә,
Иркәли һәм назлый җил генә.

Гүяки дөньяда золым юк,
Афәт юк, михнәт һәм үлем юк.

Давыллар, бураннар юк җирдә,
Юк төрмә, юк сөрген – берни дә!

Сугыш юк шикелле тоела...
Бер хатын елгада коена.

1964

***

Камыр баса уңган хуҗабикә
Таң атканда яисә ай калыккач...
Бу картина таныш барчабызга –
Ерак чордан хас бу бар халыкка.

Сүз шикелле бик борынгы ипи:
Кара ипи булсын, булсын агы...
Миңа һәрчак газиз бу күренеш:
Хатын-кызның камыр баскан чагы.

1961

***

И кояш, и һава... Җир, су, таш, үләннәр...
Бу сүзләр үткәннән ятланып килгәннәр.

Су эчеп, күп ашап туенган үгезләр...
Агачка, ташларга ышкыла мөгезләр.

Көн ни ул, вакыт ни? –
Буйволга барыбер.
Ачыкса, туйганчы ашар ул тагы бер.

Ак кораб шикелле күренә ак таулар...
И җирем-бәхетем, сиңа бу – мактаулар!

1965

***

Чакматаш – чакматаш инде ул, шул гына,
Ә менә
Ике таш очрашса –
Балкып ут кабына.

Йөрәкләр дә шулай: булсалар янәшә –
Гел якты, гел җылы өләшеп яначак.

1960

Л.Лерон *тәрҗемәсе*

Кайсын Кулиев Габдулла Тукай турында

«Төрки телләрдә язган язучыларның татар әдәбиятыннан өйрәнмәгәннәре юктыр, дип беләм мин. Казакъларга, кыргызларга, үзбәкләргә, төрекмәннәргә дә, безгә – Кавказда яшәүче балкарларга, карачай, кумык, азәрбайҗан халыкларына да – татар әдәбиятының шифасы, файдасы бик күп булды. Без бүген дә меңьеллык тарихы булган бу әдәбиятка, аның язучыларына зур рәхмәтлебез. Тукай... Тукай – иң олуг уртак шагыйрьләребезнең берсе. Безгә аның иҗаты яхшы таныш, Кавказда аны укыйлар, татар телендә дә укыйлар, тәрҗемәдә дә. Ул – безнең сөекле шагыйребез генә түгел, халыкларны берләштергән күңел күпере дә». ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

МИРАСЫБЫЗ САГЫНДА

(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

Бөек мәгърифәтче, дин галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ 2018 елны «Мәрҗани елы» дип игълан итте.

– Лотфулла әфәнде, Сез СССР вакытында хәрби кеше булгансыз. Бер караганда, совет идеологиясенең иң көчле басымы астында яшәп, бөтенләй башка юл белән китәргә тиеш булгансыз кебек. Татар мәгърифәтчеләре, шәхесләре, авыллар тарихы белән кызыксынуыгыз, аларга бәйле истәлекле урыннарны яңарту кебек изге, игелекле эшкә алыну теләге кайчан уянды?

– Без берәүнең дә әмере белән эшләмибез. Күп эшләрнең идеясе үзебезнең башка килеп, аны ике-өч ел уйлап йөргәч кенә гамәлгә ашырырга күнеккәнбез. Мин озак еллар чит җирдә хәрби хезмәттә булып, республикабызга 1990 нчы елларда гына кайттым. Бу

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов кабат торгызылган «Апуш коесы» янында

халкыбызның милли яктан уянган заманы иде. Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗаниләрнең исемен белдек, әмма аларның кем икәнен берәү дә тәфсилләп аңлата алмады. Ә күпләр бу олуг шәхесләребез турында берни дә белми иде. Аларга бәйле тарихи истәлекләрне торгызу – нәкъ менә шушы бушлыкны тутыру, халыкның берникадәр булса да күзен ачу теләгеннән башкарылган гамәл.

Бер елны Иске Казанда Җәүдәт Сөләйманов «Сәләт» лагерен җыйган иде. Миңа да анда булырга туры килде. Ни күрәм: Казан исеме белән бәйле бердәнбер музей җимерек хәлдә, җылыту системасы юк, экспонатлар иске сарайга урнашкан. Хатыным шунда: «Ничек сиңа үз халкың алдында оят түгел. Шул балалар өчен берәр нәрсә эшлә инде. Монда чит җирдән күпме кеше килә, алар, туган якларына кайтып, Татарстан турында матур итеп сөйләргә тиеш», – диде. Шуннан соң «Иске Казан» музеен төзекләндерү эшенә керештек, анда затлы кирмән дә корып куйдык.

Узган ел Курса авылында булдым, анда әлеге шәхес хакында бернинди истәлек юк иде. Дөрес, XIX гасыр уртасында салынган мәчет бинасы бар, әмма ул турыдан-туры Габденнасыйр Курсави белән бәйле түгел. Без тарихи мәчет янында мемориаль һәйкәл ачтык, авылдагы чишмәне төзекләндереп, аңа «Курсави» исемен бирдек. Бу галим һәм әдипнең төп казанышы – татар халкын караңгылыктан яктылыкка чыгаруыдыр, мөгаен.

Эшкә керешер алдыннан һәрвакыт тарихи хезмәтләрне өйрәнәм, шәхесләр турында нәрсә басылган, барысын да укып чыгам. Кызганыч, күпләрнең мирасы гарәп теленнән тәрҗемә ителмәгән, аларның эчтәлеге хәзерге укучыларыбызга бик аз мәгълүм.

Ябынчы авылына без килеп төшкәндә өй нигезе билгеләнгән, анда истәлек ташы һәм тимер киртә бар иде. Шуның алдына Мәрҗаниләргә багышлап һәйкәл куйдык. Уң якка – Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга – һәйкәл, түбәндәрәк «Муллалар» коесын да эшләдек. Мәрҗани туган нигез эзсез югалырга тиеш түгел. Анда барып, әлеге

Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм килгән кунаклар Кырлайдагы Әдәби сыннар паркы белән таныша. 2016 ел

шәхеснең әти-әнисе, бабалары ничек яшәгәне, кайларга йөргәне турында күзалларга мөмкин.

Без, татар теле бетә, дип сөйләргә яратабыз, әмма бу проблеманың тууына без – татарлар үзебез гаепле. Борынгы мирасыбызны югалтуда да гаеп фәкать үзебездә генә. Унынчы классны бетереп Казанга килгән вакытта, шәһәр транспортында татарча сөйләшеп булмый иде. 1990 нчы елларда нинди дәрәҗәгә ирештек, ә хәзер тагын барысын да югалтып барабыз. Тарихи ядкәрләр белән дә эш шуңа охшаш. Борынгылар безгә нинди зур, бай мирас калдырып киткән, ә без шул бәһасез байлыкның кадерен белмәгәнбез. Ул безнең күз алдында елдан-ел җуела бара, архитектура ядкәрләре дә җимерелеп юкка чыга.

Мәрҗанине дә ике гасыр дәвамында халкыбыз онытып бетергән диярлек. Безнең егетләр тырышлыгы белән аның истәлегенә Ташкичү мәктәбендә музей, мәктәп ишегалдында мемориаль һәйкәл ачылды һәм авылдан ерак булмаган чишмә, төзекләндерелеп, аңа галимнең исеме бирелде. Юлчылар олы юлдан узганда Шиһабетдин Мәрҗанине искә төшерсен, чишмә суын эчеп сихәтләнсен, дидек.

Заманында Мәрҗанинең йөз еллыгына багышлап затлы китап чыгарылган. Аны укысаң, Шиһаб хәзрәтнең бөеклегенә таң каласың. Без дә быел Мәрҗанинең 200 еллыгына китап чыгардык, аны мәктәп укучыларына таратырга уйлыйбыз. Һичшиксез, балалар аның нинди бөек шәхес икәнен белеп үсәргә тиеш. Бик аяныч, бүген Мәрҗанинең кем икәнлеген белмәүчеләр арасында хәтта муллалар да бар.

Минем фикеремчә, нәкъ менә Шиһабетдин Мәрҗани тәрбиясендә, аның рухында бер төркем татар зыялылары үсеп чыккан. Хөсәен Фәезханов, Исмәгыйль Гаспринский, Гаяз Исхакый кебек бөекләребезнең татар һәм ислам дөньясына танылуында, әлбәттә, Мәрҗанинең йогынтысы, һичшиксез, зур. Һич арттырусыз әйтәм: Мәрҗани – татарның Геродоты.

Арча районы Ташкичү авылында Ш.Мәрҗанигә багышлап ачылган мемориаль һәйкәл. 2017 ел

Туган авылым Симетбаш белән Ташкичү авылы арасы ерак булмагач, кечкенәдән Шиһабетдин Мәрҗани исемен ишетеп үстем. Ә ул кем булган? Нинди эшләр башкарган? Монысы миңа сер булып кала иде. Хәзер мин әлеге шәхеснең бөеклегенә, аның асылына күпмедер дәрәҗәдә төшендем, дип саныйм.

Яңа Кырлай мәктәбен тәмамлагач, документларымны пединститутның тарих бүлегенә тапшырдым. 1 сентябрьдә ни күрәм: төркемдә барысы да кызлар, егетләрдән мин генә, дисәм, тагын берәү бар иде шикелле. Шунда үземә билгесез сәбәпләр аркасында татар теле һәм әдәбияты бүлегенә эләккәнемне аңладым. Бер үк вакытта документларымны хәрби училищега да тапшырган идем. Күрше Кышкар авылында туып үскән галим Рүзәл Йосыпов янына кереп хәлне аңлаттым һәм хәрби училищега укырга киттем. Шулай итеп, профессиональ тарихчы була алмый калдым. Әмма үткән тарих, борынгы бабаларыбызның язмышы, тормыш-көнкүреше белән кызыксынуым хәзергә кадәр сүрелмәде.

– Һәркемнең үз Болгары булырга тиеш, диләр. Минтимер Шәймиевнең – үз Болгары... Сезнең өчен Арча-Әтнә төбәге, Казан арты – үз Болгарыгыз. Җитәкче булган яки мал-мөлкәткә ия һәр кеше туган төбәге өчен нинди дә булса изге эш башкарырга тиеш, минемчә...

– Без торгызган объектларның бәһасе белән кызыксынучылар бар. Мин аларга: «Бу эшнең бәясе юк! Гадел бәяне тарих, киләчәк үзе бирәчәк», – дим. Дөрес, мин аны үземнең һәм кайбер дусларымның акчасына эшлим. Мәскәү яки Петербургтан килеп безнең җирдә беркем дә бернәрсә дә эшләмәячәк. Борынгыларның мирасын кайтару эшен үзебез башкарырга тиеш. Әмма һәркемнең Болгары беренче чиратта аның туган җире булсын иде.

Шулай бервакыт уяндым да башыма бер уй килде: зиратларда безнең хәлләр ничек? Борынгыларның каберләре нинди хәлдә? Иң башта әтием һәм әнием ягыннан зират-

ларда йөреп, каберләрне карап чыктым. Цементны катырып эшләнгән 16-17 кабер ташын мәрмәр-гранитка алыштырдым, өр-яңа тимер чардуганнар ясаттым.

Аннан тарихи зиратлар белән кызыксына башладым. 2015 елда Иске Мәңгәр авылы янында Алтын Урда чорына караган зиратны төзекләндереп, тәртипкә китердек. Кабер ташларының күбесе, авып, туфракка күмелгән иде. Аларны җир өстенә күтәрдек, чистартып, бастырып куйдык, чардуганнар белән уратып алдык. Галимнәр ярдәмендә ташларга ниләр язылганын мөмкин булганча ачыклап, истәлек тамгалары да куйдык. Заманында булачак кәләшем янына, Олы Әтнә авылына барып йөргәндә юлым гел шул зират буеннан үтә иде. Зират өстендә бала-чаганың футбол уйнавы, кабер ташларын капка итеп файдалануы шул вакытта ук йөрәгемне әрнетте. Соңгы елларда бу зиратны сыер көтүе таптап изде.

Мондый эшләрне башкарыр өчен тәҗрибә дә, әрсезлек тә, аң-зиһен һәм инде җәмгыятьтә берникадәр дәрәҗәң дә булуы кирәк. Тарихи ядкәрләрне саклау гади генә эш түгел.

– Тарихи-мәдәни истәлекләрне яңарткан вакытта нинди каршылыкларга юлыгасыз? Мин беләм: барысы да шома гына бармый бит...

– Яшермим, Шиһабетдин Мәрҗанинең һәм Каюм Насыйриның каберләрен элегрәк, барып, үз күзем белән күргәнем юк иде. Соңгы елларда Татар бистәсендәге зиратка барып, бөек шәхесләребезнең каберләре ташландык, ташлары җимерек хәлдә икәнен күреп, гаҗәпкә калдым. Биредә татарның шундый бөек шәхесләре җирләнгән, ә аларның каберләре һәм ташларына тиешле дәрәҗәдә игътибар юк. Миңа халкым өчен бик оят булды. Аерым егетләрне билгеләп, К.Насыйри һәм Ш.Мәрҗани каберләрен төзекләндерә башладык. Шулвакыт зират администрациясеннән түрә кисәкләре килеп чыгып: «Сез нәрсә аңа кагыласыз! Тиз арада туктатыгыз! Мәдәният министрлыгының рөхсәте кирәк...» – дип, эштән бүлде. Эшне ярдәмчем, шагыйрь Рөстәм Зәкуанга тапшырып, аны көне буе кәгазь артыннан йөрттем, әмма бер ишектән икенчесенә йөгереп, барлы-юклы түрәгә ялынып-ялварып та тиешле рөхсәтне алып булмады. Икенче көнне егетләргә: «Зиратта түрә-кара килеп чыкса, син – Мәрҗанинең фәләненче буын оныгы, ә син Каюм бабаныкы буласың!» – дидем дә, тиз арада ташларны яңартып, чардуганнарны буяп, эшне тәмамладык. Дөрес, «зират ияләре» янә килеп чыкты, аларга: «Туганнары!» – дигәч, берни эшли алмадылар. Ә бит бу зиратта халкыбызның иң мәшһүр кешеләре җирләнгән, аларның кабер ташлары гына түгел, ә каберләре дә юкка чыгып бара... Әгәр дә Казандагы берләнбер тарихи татар зиратын карап-чистартып торуга үзебез үк каршылык тудырабыз икән, без нинди халык?! Туган телебезнең бүгенге хәле дә менә шушы ташландык зират хәлендә. Аңа элек-электән һәм хәзер дә тиешле хөрмәт булмады. Татар телен кадерле мирас, борынгылар ядкәре итеп саклый белмәдек.

Үзебезнең татарлар китереп чыгарган проблеманың тагын берсен искә төшерим әле. «Ш.Мәрҗани утызлап китап язган», – дибез. Ни өчен аның хезмәтләрен хәзерге заман укучысы белми? Мин атаклы дин әһелләре белән сөйләштем: бу мирасны тәрҗемә итүче белгечләр бездә бар. Әмма Ш.Мәрҗани, Г.Курсави кебек бөекләребезнең кульъязма китап күчерелмәләрен алыр өчен университет җитәкчеләре, үзебезнең үк татар егетләре бер биткә фәлән йөз сум кадәр акча сорый. Эшлим дигән кешегә киртә кору, юлны ябу – бу бит ахмаклык!

Район үзәкләрендә һәм авылларда безнең тарафтан музейлар ачыла, әмма аны карап тору, эшне оештыру мәсьәләсен кайбер район җитәкчеләре хәл итә алмый. Гомумән, алар музей эшен, эчке туризмны оештырырга шәхес буларак җитлекмәгән. Әйтик, Кама Тамагындагы Олы Мәрәтхуҗада Туфан Миңнуллин нигезендә затлы музей оештырдык. Әмма эшне район җитәкчеләре күтәреп алырга һәм дәвам итәргә теләми. Ә

Туфан Миңнуллинның туган авылы Олы Мәрәтхуҗадагы музей-йорты

бит эшлим дип теләк белдерүче кешеләр дә бар. Ә менә Арча районының Иске Кишет авылында Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин истәлегенә ачылган музейда эш яхшы оештырылган. Аеруча хәрби-патриотик чаралар әйбәт бара, әмма бина, хуҗалык чыгымнары, андагы белгечкә айлык хезмәт хакын түләү өч ел дәвамында инде безнең өстә. Без ачкан музейлар муниципаль карамакка күчеп, төп музей яки китапханәләрнең аерым бүлекчәсе буларак, аларда төрле юнәлештә эш дәвам итсен иде. Моны тиешле югарылыкта оештыру – район һәм республика җитәкчеләренең бурычы.

Мине халкыбызның битарафлыгы гаҗәпләндерә. Курсави чишмәсе, төзекләндергәнче, сазлык эчендә иде, хәтта авыл җитәкчеләреннән, су юк анда, саташып йөрмәгез, дип әйтүчеләр дә булды. Хәзер төзекләндерелгән, ургылып аккан чишмәне күреп, халык шакката.

Кылган гамәлләребез аша без кешеләрнең табигатькә, аның байлыгына карата мөнәсәбәтен дә үзгәртергә тиеш. Чишмә – табигатьнең илаһи могҗизасы. Чишмә агып утырган җирдә халыкның күңеле йомшак, саф була. Чишмә – шигъри күренеш, язучы-шагыйрьләребезнең илһам чыганагы.

– Сез милләткә ярдәм итүдән ямь табасыз. Бу – Сезнең тормыш кыйблагыз. Татар теле мәктәпләрдән кысрыкланган заманда Сезнең кебек затлы шәхесләргә милләтне саклап калу өчен шәхси милли мәктәпләр ачу зарур булмасмы? Мәсәлән, элеккеге «Касыймия», «Гобәйдия», «Мөхәммәдия» мәктәп-мәдрәсәләре кебек, «Миңнехания», «Шәймия», «Шәрипия» мәктәпләре... Сез моңа ничек карыйсыз?

– Дөньяви мәктәп турында әйтә алмыйм. Элеккеге мәктәпләр тулысынча дөньяви булмаган, алар дини белем бирүне нигез итеп алган.

Мин үзем дә милли мәктәптә белем алдым. Дөрес, үзлегемнән урыс әдәбиятын күп укыдым. Һәр татар кешесе туган телен белергә тиеш. Әгәр дә син татар булып та туган телеңне белмисең икән, тулы канлы кеше түгелсең. Әмма бездә БДИлар урыс телендә. Имтиханыңны начар бирәсең икән, беркая да укырга керә алмаячаксың. Мин хәрби училищеда, белер-белмәс урысча сөйләшеп, ике ел буе интектем. «КПСС тарихы»н, «Философия»ләрнең барын да урыс телендә аңлатырга, сөйләргә кирәк иде.

Лотфулла Шәфигуллинның әнисе Кафия Зариф кызы һәм әтисе Нурислам Шәфигулла улы

Һөнәреңне татар мәдәнияте, теле белән бәйләргә телисең икән, бәлки татар мәктәпләре һәм гимназияләрендә уку кирәктер. Хәзерге технологияләр заманында татарча, урысча, инглизчә һәм кытайча да камил белү зарур.

Шәхси мәктәпкә килгәндә, элек, революциягә кадәр халкыбыз мәктәп-мәдрәсәләрне үзе ачып, аның матди хәлен дә үзе тәэмин иткән. Күптән түгел туган авылым Симетбашта «Нурислам» мәчетен ачу тантанасы булды. Проект буенча, бинаның икенче өлеше тулысынча мәдрәсә итеп эшләнгән. Алга таба остазлар чакырып, аларга яшәү шартлары булдырып, шунда шәкертләр укытырга, милли һәм дини рухлы балалар тәрбияләргә хыялланам.

Патша заманында да дәүләт татар теле дип баш ватмаган, урыс булмаган халыкларның динен, телен кайгыртмаган. Туган тел, милли әдәбият, дин халыкка мәдрәсәләр аша сеңдерелгән. Күпме зыялыларыбыз татар мәктәп-мәдрәсәләрендә, Кышкар, Курса, Ташкичүләрдә тәрбияләнеп, милләтебезгә хезмәт иткән.

– Лотфулла әфәнде, әти-әниегезне, әби-бабаларыгызны искә төшереп китик әле. Аларның тормышыгызга йогынтысы ни дәрәҗәдә?

– Әти дә, әни дә гади кеше иде. Әтием Нурислам 39 ел буе тракторда эшләде, безне үз хезмәт үрнәгендә тәрбияләде. Ул гадилеге белән бөек, гаҗәеп кеше иде. Туган авылымда «Жданов» исемендәге колхозның Симетбаш бригадасы тракторчыларына багышлап махсус һәйкәл куйдырдым. Алар барлыгы 22 механизатор, араларында хатын-кызлар да бар. Икмәк өчен тир түккән шәхесләрнең, кыр батырларының да исемнәрен безнең һәм киләчәк буын, аеруча шундагы кешеләр онытырга тиеш түгел. Бу Татарстан Республикасында сабанчыларга, тракторчыларга куелган беренче һәм бердәнбер һәйкәл түгелме икән?

Әбием абыстай, изге күңелле кеше иде. Ул – Ташчишмә авылыннан. Анда, үземнең һәм хатынымның әбиләренә багышлап, «Әбиләр» чишмәсен төзекләндердем. Барлыгы – җиде әби. Мәрхүмәләрнең урыны җәннәттә булсын.

Әбиемнең Лотфулла исемле улы булып, ул 1943 елда Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган, аның исемен миңа биргәннәр. Әбием мине үз улы кебек гел янында йөртте. Ул гаять укымышлы, диндар әби иде. Аннан күпмедер дәрәҗәдә динне, догаларны, гарәби язуны өйрәнеп калдым, дип әйтә алам.

Әни ягыннан бабам урманчы булган. Без ул 1930 нчы елларда эшләгән кордонны

таптык. Үзем дә бабам эшләгән җирдә булдым, әнием бит заманында шунда тәгәрәп үскән. Мари урманы чигендәге Югары Оры авылында кордончыларга багышлап гранит һәйкәл дә куйдырттым.

– Кешенең күңелендә игелек булырга тиеш. Сезнең кылган гамәлләрегез республикабыз һәм аннан читтә яшәүче башка татар җитәкчеләре өчен дә үрнәк гамәл булсын иде. Әгәр дә бер җитәкче республикабызның берәр авылына кайтып, анда мәчет, күпер яки юл сала, чишмәләрне төзекләндерә икән, мин моңа бик сөенәм, чөнки татар халкы яшәгән бер җир азмы-күпме яхшыра, анда тормыш уңай якка үзгәрә.

– Һәр кешенең үз хоббие бар. Кемдер ау белән күңеленә юаныч таба, берәүләр балыкка йөри, ә кайберәүләр хатын-кызларны кармакка каптыру турында хыяллана. Ә минем хобби – тарихи истәлекләр. Без һәр шимбә көнне үзебез төзекләндерә торган объектларга чыгып китәбез, елларны тулысынча шунда үткәрәбез диярлек. Әле бит аларны, аеруча чишмәләрне һәр елны яз-көз айларында карап торырга да кирәк.

Бер изгелек икенчесенә сәбәп. Шиһабетдин Мәрҗанинең каберен эзләп, Татар бистәсендәге зиратка килсәм, Миркасыйм Госмановның кабере янында бер апа елап утыра. Бәлки берәр ярдәм кирәктер, дип, аның янына үземнең кешеләрне җибәрдем. Ул галимнең хатыны Салисә ханым булып чыкты.

Миркасыйм Госманов ун ел дәвамында җәйләрен Наратлык авылында яшәгән икән. Шул йорт шактый искергән булып чыкты. Безнең егетләр Наратлыкка кайтып, анда балаларга спорт мәйданчыгы ясады, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл торгызды, мәшһүр академик истәлегенә таштакта куеп, йортын тулысынча төзекләндерде. Миркасыйм ага Госманов – даһи кеше, мин аның дәрәҗәсендәге татар академигын, тарихчыны белмим. Төзекләндерелгән йортны, барып, үзем дә күрдем. Салисә апага җан кергән, ул яшәреп киткән, өйдә йөгереп кенә йөри... Аның белән чәй өстәле янында Миркасыйм ага Госмановны искә төшереп утырдык.

Без – татарлар Хотня чиркәвен дә күтәрдек, ул ташландык, янына килергә дә куркыныч, хәрабә хәлендә иде. Россиядә татарларның чиркәү төзекләндерүе беренче вакыйга. Халкының 92 проценттан артыграгы татарлардан торган Арча районында бу эшнең башкарылуы гайре табигый күренеш, дип әйтер идем. Чиркәүнең бер өлешендә музей, ә икенче ягында алтарь эшләдек. Читтән килүче урыслар, яһүдләр, безнең бу эшне күреп, шаккатып китә: татарлар моны булдыра аламыни, диләр. Хәтта килеп елаучылар да бар... Без бу эшләребез белән урыс һәм башка халыкларда татарга карата уңай мөнәсәбәт тудырабыз, толерантлык мөнәсәбәтләрен ныгытабыз. Аннары Хотня авылының кайчандыр, урта гасырларда татар авылы булганын да онытырга ярамый. Безнең әби-бабаларыбыз аның изге чишмәсенә ел саен бара иде. Тарихи гаделлекне торгызу өчен, Хотняда часовня һәм аның янына намаз уку бүлмәсе дә салып куйдык. Хотня – мөселман кардәшләребез өчен дә изге урын. Сез анда барып карагыз: искиткеч гүзәл табигать, урманның саф һавасы...

Казан арты буенча тарихи-географик фонд оештырып җибәрдек. Аның башкарма директоры итеп Рөстәм Зәкуан тәгаенләнде. Әмма минем өчен иң мөһиме үземнең туган авылым Симетбаш булып калачак. Кызганыч, без, эшләрне иртәгәгә дип калдырып, күп әйберне югалтабыз. Ә иртәгә инде соң була... Шуңа күрә бүген, берәгәйле итеп эшләргә кирәк. Безгә Ходай Тәгалә тарафыннан чикле вакыт бирелгән, аның кадерен белсәк иде.

Бу елны «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ «Шиһабетдин Мәрҗани елы» дип игълан итте. Татары да, урысы да, хәтта республикабызга килгән чит ил кунаклары да әлеге мөхтәрәм шәхесне белергә тиеш...

Текстны журналга ***Л.Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ТОМСК

ТОМСК ДЕПУТАТЫ НЕКРАСОВ

Некрасов түбәндәге чыгышын ясады: *«Әфәнделәр! Мин сезгә бу юлы безнең Русия Думасының эшләү рәвеше турында мәгълүмат бирергә телим. Моны вөҗданымның бурычы дип беләм, чөнки мине сайлаган вакытта сез миңа кеше хокуклары арасындагы бер вазыйфаны, әлбәттә, шактый авыр вазыйфаны ышанып тапшырдыгыз.*

Билгеле булганча, депутатлар үзен сайлап куйган төбәк халкының һәрвакыт күзәтүе астында булырга тиешләр. Мине сез сайлаганга күрә, күзәтү астын-

---

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

да тотмасагыз да, вөҗданым белән мин үзем сезнең күзәтүегез астында булырга тиешмен, дип саныйм. Менә шул сәбәпле, вөҗданым шулай кушканга, Думаның бүгенге һәм киләчәктәге хәле белән бәйле рәвештә сезгә хисап тотуны, мәгълүмат бирүне үземнең бурычым дип беләм. Сез миңа ышаныгыз, мин исә, сезнең ышанычыгызны акларга тырышырмын. Сездән дә кайчакларда мине аңлавыгызны һәм кичерүегезне үтенсәм, үтенечемне кире какмавыгызны сорыйм.

Бүген безнең илебездә Дума бар, тик сез барыгыз да бик яхшы беләсез: Думада күпчелекне тәшкил иткән партия хөкүмәт коралы булып тора. Күпчелек алар кулында булганга, бүген, ничек телиләр, шулай борып йөртә алалар.

Менә шундый хәлдә безнең вазыйфабыз нидән гыйбарәт соң? Сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәргә теләгән мәсьәлә дә бу. Бүгенге Думада без башкара торган эш бик авыр, чөнки азчылыкны тәшкил итәбез, ләкин шулай булса да, милләтнең, халыкның киләчәген уйлап эш итәргә тиешбез.

Бүгенге көндә безнең партиябезнең бөтен эш-хәрәкәте шушы мәсьәләгә юнәлдерелгән. Безнең бүген бердәнбер вазыйфабыз – Конституция исемен саклап калу. Бөтен теләк-омтылышларыбыз шуңа юнәлгән булырга тиеш. Халыкны моннан соңгы сайлауларга әзерләргә тиешбез. Менә иң мөһим мәсьәлә шул. Бу чор ничек тә үтеп китәр, инде бер өлеше үтте дә. Халык сайлаулар вакытында бөтен көче белән хөкүмәткә каршы тора алса, өметсезлеккә төшмичә, бик тырышып, акыллы, сәләтле, гайрәтле, намуслы депутатлар сайлап куя алса, дүрт елдан соң булса да, мәмләкәтебезне коткарган булырбыз.

Андый очракта, әлбәттә, бүгенге хөкүмәт, сайлаулар вакытында, үзенә ярдәмче булачак депутатлар сайлансын өчен тырышачак, полиция янауларын да эшкә җигеп, бик зур көч куячак. Шуңа күрә безгә дә яхшы әзерләнергә кирәк. Әгәр халык шулвакыт гайрәтләнеп хөкүмәтне җиңә алса, Ватанны куркынычтан коткара алачак. Әгәр халык болай гафләт эчендә тәгәрәп барса, иле-ватаны өчен нибарысы бер ай гына гомерен сарыф итүдә йомшаклык, ялкаулык күрсәтсә, безнең киләчәгебез соңгы чиккә җиткән өметсезлек эчендә күмелеп калачак. Бөек дәүләтләр рәтендә яшәү турында сүз дә була алмый, хәтта дәүләтебезнең киләчәге дә бик шөбһәле. Нәкъ менә хәзер, бу мәсьәләне бик җитди игътибарга алып, кирәк булганның барысын да эшләргә кирәк.

Н.В.Некрасов

Дума шушы көнгә кадәр ниләр эшли алды соң? Министрларга карата нинди вазгыять алачак? Хәзерге көнгә кадәр Дума, никадәр генә көчсез булса да, хөкүмәт каршысында зур урын тотуын исбат итүгә иреште. Моннан тыш, комитетлар да күп кенә оештыру эшләре алып бардылар, бүген бу фактларны кабул иттерү никадәр генә авыр булса да, вакыты килер, шул вакыт өчен болар инде әзер булып торырлар.

Думаның министрлар алдындагы вазгыятенә килсәк, әлегә әллә ни дәрәҗәсе юк кебек. Шул ук вакытта, бөтенләй юк дип тә әйтеп булмый, министрларның агымдагы эшләренә караган хисаплар буенча инде билгеле бер күләмдә тикшерүләр алып барылган.

Аеруча Диңгезчелек министрлыгы белән Юл эшләре министрлыгына карата бик мөһим тәнкыйтьләр ачыкланган һәм чагыштырып, тикшерү идарәсенә тапшырылган. Бигрәк тә юл эшләре министрының хисаплары шулкадәр начар ки, дөреслекне белеп, шаккатырлык. Сезгә үрнәк итеп, биредә бары тик бер генә мәсьәләне күрсәтеп үтәм. Көнчыгыш Кытай тимер юлы безнең Русия хөкүмәтенә ел да 35 мең сум зыян китерә, бу зыян ел саен арта гына бара, тик Юл эшләре министрлыгы моңа каршы тору өчен берни дә эшләми. Гомумән, бу министрлыкларның эшләре шулкадәр начар ки, хәзерге вакытта яхшыга үзгәртү дә мөмкин түгел, дәфтәрләре буталып беткән. Инде менә Дума әле генә әйтеп үткән ике министрлыкның идарәләрен тикшерүгә ирешә. Нәтиҗәдә бу ике министрны җаваплылыкны үз өсләренә алырга мәҗбүр итә алса, бу алга таба бер адым булыр иде.

Думаның киләчәге турында да әйтергә теләгән идем. Алда сөйләгәннәрем турында ныгытып уйланылса, киләчәкне дә бераз аңларга мөмкин. Чынлыкта, киләчәкне нәкъ күз алдында тотылганча тормышка ашыра алу өчен, сайлаулар вакытын көтәргә кирәк. Кабатлап әйтәм: бөтен халыкның өмете шул сайлауларда, тик халык шөһрәт артыннан куса яки хөкүмәт күрсәткән кешеләрне сайласа, Думадан хәер килмәячәк, моннан соң инде конституцион идарә дә юк дигән сүз. Әгәр халык сайлаулар вакытында күзен нык ачып, чынлап та үзе ышаныч белдергән кешеләрне сайлый алса, менә ул вакыт илебезгә янаган куркынычны юк итә алыр идек.

Инде килеп, безнең чит илләр белән мөнәсәбәтләрдә сәясәтебез бик түбән дәрәҗәдә, бөек дәүләтләр каршысында торган сәяси урыныбызның бу кадәр түбән булуының сәбәбе – Ерак Көнчыгыш [рус-япон] сугышында җиңелүебез.

Хәзер сезгә Себер депутатларының эшчәнлеге хакында бераз мәгълүмат бирәчәкмен. Бөтен Себердә земство ысулына күчүне тикшерү идарәсенә кую – бүгенге көндә безнең Себер депутатларының беренче вазыйфасы булып тора. Бу эш инде Дума әгъзалары, бөтен депутатлар тикшерүеннән үткән, кабул ителүе карарлаштырылган. Земство кануннамәләре һәм сайлау ысулы да тиешле рәвештә тәртипкә салынган.

Инде бер ун минутлык тәнәфес ясап алуны сорыйм. Әгәр берәр нәрсә исегезгә төшсә, язып китерегез, җавап бирергә тырышырмын».

Тыңлаучылар, урыннарыннан торып, тәнәфескә чыга башладылар. Без исә, бу тәнәфес вакытыннан файдаланып, Некрасов җәнапларының янына киттек. Профессор Соболев мине Некрасов әфәнде белән таныштырды. Ул миңа карата бик нәзакәтле итеп: «Без сезнең Себер кешесе булуыгыз белән горурланабыз. Бу юлы Думада исемегезне Себер депутатлары арасында берничә тапкыр телгә алдык. Сезнең белән танышуыма бик шатмын», – диде.

Мин, форсаттан файдаланып: «Чыгышыгызда Себер мөселманнарының җирләре хакында фикерегезне белдерсәгезче», – дидем. Бик канәгать булып, дәфтәренә теркәп куйды.

Некрасов җәнапларының чыгышы гаять тәфсилле иде, барысын да язып бару мөмкин булмады, әлбәттә. Шулай булса да, теркәргә өлгергән кадәресен сезнең игътибарыгызга җиткерергә телим.

Некрасов кабат трибунага килде, кабат алкышлар белән каршы алынды һәм сүзгә кереште: *«Безнең мәмләкәтебез мәгарифтән бик мәхрүм булганга, бу хакта Думада булган фиркабезнең [партиябезнең] фикерен җиткерергә*

Уртада – Н.В.Некрасов

телим. Мәгълүм булганча, безнең партиябез – «кадет» дип атала торган Конституцион демократ партиясе – Думада азчылыкны тәшкил итсә дә, халыкның күпчелеге тарафыннан үз ителә.

Безнең хөкүмәтебез хәзерге көнгә кадәр үзенә күпме түрә кирәк, шулкадәр кеше җитештерү сәясәтен алып барды, шуннан артыгын кирәксез дип санады. Хөкүмәтнең бу сәясәтенә бәлки гади халыкның наданлыгы да файда иткәндер. Шул сәбәпле, бездә иң фәкыйрь министрлык кайсы дисәгез, ***ул – Мәгариф министрлыгы.***

Әгәр, мәмләкәтебезнең бүгенге көндә иң зур ихтыяҗы ни, дип сорасагыз, мәгарифкә булган ихтыяҗ, диячәкмен. Хәзергә кадәр безнең авылларыбызда түгел, шәһәрләребездә дә Мәгариф министрлыгы тарафыннан ачылган мәктәпләр бик сирәк очрый. Бәрәкәт бирсен, бу соңгы елларда земстволарыбызның көче белән шактый гына авылларда башлангыч мәктәпләр ачылды. Безнең Себердә исә земство да юк, бу сәбәптән бөтен Себер җире мәгарифтән бөтенләй мәхрүм калган, дип әйтергә мөмкин. Унлап губернасы булган бөтен Себердә бары тик безнең Томск шәһәрендә генә университет бар. Русия дәүләте кебек халык саны йөз кырык миллион булган мәмләкәттә бу кадәр генә университет белән канәгатьләнергә ярый димени?!

Безнең партия нәкъ менә бу хәлләрне игътибарга алды, бу мәсьәләләрне үзенә вазыйфа итеп таныды. Бөтен көч-куәте белән эшләячәгендә уңышка ирешәчәге әлегә бик күренмәсә дә, вакыты җитеп, форсатлар кулга кергәч, вазыйфасын башкарачагында, яклау табачагында һич кенә дә шигем юк». **(Алкышлар.)**

Трибуна янындагы өстәл өстендә тәнәфес вакытында тыңлаучылар тарафыннан сораулар язылган шактый язу җыелган иде. Некрасов аларны кулына алып, берәм-берәм җавап бирә башлады. Сораулар бик күп иде, күбесен терки дә алмадым. Игътибарымны җәлеп иткән берничә сорауга гына тукталам. Некрасов сорауларны түбәндәге тәртиптә укыды һәм җавапларын да шул тәртиптә бирде: *«1) Башта Думаның мөселманнар фиркасе турында сорау бар. Мөселман фиркасенең бу көнгә кадәр җитди эшчәнлек күрсәткәне юк. Бары тик кыргыз җирләре мәсьәләсендә әллә ни әһәмияте булмаган бер талпынышлары гына булып алды.*

2) Күпчелекне тәшкил иткән «Октябрист партиясе»ннән сул канатның ае-

рылуы турында сорау бар. Миңа калса, бу була торган хәл түгел. Аларның аерылуы, безгә генә түгел, үзләренә дә зарар китерәчәк.

3) Думаның никадәр көче барлыгы турында сорау бар. Бу хакта чыгышымның беренче өлешендә бераз әйтеп үткән идем. Безнең халкыбызда милли вөҗдан һәм гайрәт калмаган.

4) Якын Көнчыгыш һәм Төркия мәсьәләсе хакында Думаның фикерен сорыйлар. Мин бу турыда үз фикеремне әйтим әле.

Босния-Герцеговина мәсьәләсендә Австриянең хәрәкәте безнең өчен мыскыл итү белән бер иде. Ләкин нишләмәк кирәк, бу мәсьәләдә дәрәҗәбезне саклап кала алыр өчен, безнең хәрби көчебез юк шул. Безнең армиябезнең көчсезлеге финанс ягыннан көчсезлегебезгә бәйле. Без, гомумән, бик тырышырга тиеш, хәлебез яхшыга үзгәрсен, дисәк, әхлагыбыз яхшыга үзгәрергә тиеш, эшләребез дә, сүзләребез дә яхшыга үзгәрергә тиеш. Бүген бөтен мәмләкәтебезнең сәүдә эшчәнлеге чит ил кешеләренең кулында. Болай барса, без читләр каршысында берзаман кеше хокукларыбызны да яклый алмаячакбыз. Шулай булгач, кеше булырга теләсәк, тырышыйк, булдырыйк та, кеше булыйк». **(Дәвамлы алкышлар.)**

Менә бу – Себердән чыккан бер рус депутатының халкы каршысындагы вазгыяте. Думаның һәр ялы саен без дә мөселман депутатларыбыздан шундый ук вазыйфалар көтсәк тә, кызганыч ки, мондый хәлләр әлегә күренми.

Мин биредә Некрасов җәнапларының чыгышыннан менә бу кадәр генә язып ала алдым. Болардан тыш, «Депутатлар кемнәр?», «Депутатлык нәрсә?» һәм «Депутатларның халык карашында тоткан урыннары нинди?» кебек темаларга да бик җентекле мәгълүмат бирде. Шуннан соң, тыңлаучыларга мөрәҗәгать итеп, болай диде: *«Мин биредә катнашучылар алдында вазыйфамны үтәп, вөҗданымны бераз тынычландырдым. Сездән дә, кайларда гына булсагыз да, милләтебезнең фикерен шулай агартырга тырышуны үзегезгә вазыйфа итүегезне сорыйм. Милләтебез, конституцияле тормышның яхшы якларын аңламыйча торып, тиешле депутатлар сайлануга ирешә алмаячак. Берничә кешенең фикеренә җиңелеп калган милләтләр бервакытта да әсирлектән котыла алмаячаклар...*

Н.В.Некрасов

«Әйе, менә шулай», – дип, Некрасов трибуна артыннан чыкты. Тынмаган алкышлар астында тагын ике кабат трибунага чакырылды, үзенә рәхмәтләр белдерелде һәм нәзакәт күрсәтелде.

Астөшермә:

Н.В.Некрасов – дәүләт эшлеклесе. 1879 елда туган. 1908-1917 елларда – III һәм IV чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты. 1919-1921 елларда Казанда яши һәм эшли. 1939 елның 13 июнендә кулга алына һәм 1940 елның 7 маенда атып үтерелә.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе.* ■

Ризаэддин Фәхреддиннең Гыймадеддин Җәмаледдин улына язган хаты

«Бисмилләһиррахмәниррахиим.

Хөрмәтле Гыймад* әфәнде! Үзегезгә, әхбәб *(сөеклеләр)* вә мусахибләрегезгә *(дуслар)* сәлам мәснүн тәблигъ *(ирештерү)* итәмез. Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ.

Ризаэддин хәзрәт җәмәгате Нурҗамал абыстай белән. Уфа. 1926 ел

Ноябрнең 20 көнендә язган хатыгыз үз вакытында сәламәт иреште. Язганларыгыз мәгълүм булды. Йөргән җирләрегездә дә безне хәтерегезгә алып йөргәнсез, бу хәл, әлбәттә, күңелле.

Үземез бер хәлдә көннәр үткәреп торабыз. Бу кадәр озын гомерле булырмын дип фикерләмидер идем.

Һиҗри берлә 1275 нче ел җүмәдә әл-ахыр 7сендә дөньяга килгәнмен. *(Милади берлә 1858 нче ел 31 нче декабрь-1859 нче ел 12 нче гыйнварда)*. Икенче анамнан дөньяга килгән кечкенә бер туганымнан башкалары (үз анамнан дөньяга килгәннәр) һәммәсе күчеп беттеләр. Замандашларым да калмады. Гомеремне язу вә бозу һәм дә аны төзәтү берлә үткәрәмен. Язганларымны укучылар булачакка өметем юк. Өметкә урын да юк. Ләкин язу вә моталага *(уку)* берлә шөгыльләнү сәбәпле, кайгылар онытыла вә гомер тынычлыкта үтәдер. Бу эш олуг ганимәт. Һәрхәлдә, кешеләр кулларында йөк булмасам иде. Аллаһ Тәгаләнең мәрхәмәте берлә иманлы бәндәләрдән булып җиңеллек үзәрендә дөньядан күчсәм иде.

Һәрхәлдә, әманәтегезне сәламәт алганым соңында Аллаһ Тәгалә насыйп итсә кичектерми җавабын язармын.

Үткән октябрь 20сендә сезгә мәктүб һәм дә ай башлары хосусында җәдвәл җибәргән идем.

Үземнән вә рафикамнан *(иптәш)* бөтен әкрибагызга, хосусан, хәлиләгез *(хатыныгыз)* Фатыйма ханымга, әүләд *(балалар)* гәзизәләрегезгә сәлам вә хәер догалар кылуыбызны тәблигъ итәмез.

Аллаһ Тәгалә һәрберемезгә үзенең әбәди *(мәңге)* булган мәрхәмәтен вә лотфын ихсан кылсын «лә хәүфүн галәйһим вә лә һүм йәхзәнүн *(аларга курку һәм кайгы ирешмәс)*» дигән бәндәләре җөмләсенә кертеп мәсгүд *(бәхетле)* итсен иде. Вәссәлам мәгәл-ихтирам *(ихтирам белән)*,

Ризаэддин бине Фәхреддин
1354-1935 ел 7 рамазан – 3 декабрь
Уфа, Тукай, 50».

Иске татар язуыннан бүгенге имляга ***Фатыйх Хәбиб*** *күчерде.* ■

---

*Гыймадеддин Җәмаледдин улы – Финляндия татары.

Безнең мирас №2 февраль 2018

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ХАТЛАРЫ

ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ

1966 ел, 8 март, Кисловодск.

Әмирхан абый!

Сәлам Сезгә!

Мин «Былбыл баласы» дигән пьеса язып йөрим. Үземчә, бик кирәкле, безнең халык өчен бик вакытлы тема ул. Соңгы елларда мине гел бер уй борчый: татарлар бик нык таралалар. Югыйсә, таралмаска да була ич! Менә яңа, салынып ята торган шәһәрләрдә меңәрләгән кешеләр була, дип сөйлиләр, нигә шуларга күчеп утырмаска? Милләт кайдадыр бер урында оешып утырганда гына милләт була ала икән. Үз төбәгеннән аерылган «былбыл балалары» читтә каргага бик тиз әйләнәләр. Менә шушы идея ята минем ул әсәрнең нигезендә. Шуны матур итеп, үтемле итеп әйтеп булырмы, юкмы?!

Сезгә саулык, иминлек теләп, сагынып, Аяз.

ӘХСӘН БАЯНОВКА

1966 ел, 16 март, Кисловодск.

Әхсән!

Ни хәлләрдә? Киткәнгә өченче атна китте, Казаннан ник бер кеше хат язсын. Элек, сугыштан соңгы елларда, мин Җир шарында үземә туктар урын тапмый йөргәндә: эшсез, өйсез – кинодан чыкканда, бер тойгы кичерә идем. Менә кешеләр савылып чыгалар, һәркем өенә, туганнары, әти-әнисе янына ашыга. Ә минем беркая да барыр җирем юк... Өем дә, туганнарым да ерак – беркемем дә юк төсле, мин – дөньяга чытык йөз белән караучы сукбай!

Һәрвакыт шушы хис, шушы тойгы була иде. Менә шундый халәт кичерәм мин. Минем өем дә, якыннарым да, туганнарым да юк төсле. Җир шарын туктатып, кайсыдыр тукталышта төшеп каласы килә.

Миңа авиа белән хат җибәр әле: повесть ни хәлдә? Төшереп җибәрдегезме? Кайсы урында бүлдегез?

Шәүкәткә ике хат яздым, аннан да ләм-мим. Шулай ук мин һаман япа-ялгыз сукбаймыни?

Ә көннәр матур, һава коры. Тауларга менәм.

Әнә Эльбрус... Әнә Биштау, Машук... Телевизор баганасы куелган таудан барысы да күренә икән...

Ниләр бар?

Сәлам белән, сине сагынып, Аяз.

НӘКЫЯ ГЫЙЛӘҖЕВАГА

1966 ел, 16 март, Кисловодск.

Нәкыя!

Нәрсә ул милләт, халык, туган җир, туган тел?

Аларның барысының да конкрет чагылышлары бар ләбаса! Туган җир ул минем өчен Зәй, Сарман яклары, Минзәлә елгасы, Баграж елгалары. Милләт минем өчен иң элек син, улларым, ата-анам, дусларым, үзем сөйгән җырлар...

Сагынып, Аяз.

***

1966 ел, 12 август, Тубыл, Хуҗайлан.

Әнисе, матурым, исәнме!

...Көннәр баштарак бик җиңел һәм тиз узганнар иде, хәзер бераз ялыктырды. Гел өйдә генә утырабыз. Якуб агай мәктәпкә китә, аның да ремонт эшләре башланды. Рәшидә ханым да эштә. Балалар белән өйдә мин генә калам. Аларга бер кунак малае да килде. Кыскасы, өйдә кым-кырыч. Тик балалар мин утырган бүлмәгә кереп йөрмиләр. Китаплар укыйм. Тагын бер кат «Анна Каренина»ны караштырып чыктым. «Батый»ны укыдым. Моннан элек укыганда, ул якларына игътибар итмәгәнмен икән. В. Ян әшәке рәвештә, тенденциоз һәм ялган китап язган кебек күренде. Монгол татарларында гел ыргыйлык, усаллык һәм наданлык булса, русларның иң бетәшкән түбән кешеләре дә югары фәлсәфи категорияләр белән генә фикер йөртәләр. Алар гуманистлар, патриотлар, йомшак күңеллеләр. Шулкадәр өстән-өстән генә тузан очырып язылган китап икән ул. Юкка гына Сталин бүләге тоттырмаганнар икән аңа! Кайчагында китапларны кайта-кайта укып чыгу да зыян булмый икән!

Инде Тубылдан әйләнеп кайтмыйча хат яза алмам. Бу хатны да шуннан салырмын инде.

Барыгызны да сагынып, Аяз.

***

1966 ел, 23 август, Салехард.

Әнисе, кадерлем минем!

Менә минем Себер буйлап сәяхәтем тәмамланып килә...

Әле, киткән чакта, минем юлларым да, уйларым да томанлырак иде. Кайда тукталырмын да кая таба карармын? Шундый уйлар белән, ләкин ниндидер бер эчке дулкынлану белән чыккан идем. Ни дисәң дә, шундый ерак җирләргә, язучы буларак, минем беренче сәфәрем. Йөри һәм күрә белү осталыгына да без әллә ни өйрәнмәгән. Хәтта юлда язарга да күнекмәгән икән.

Якуб агай, Рәшидә ханым һәм мин, колхозның бик таланган, бик иске машинасына утырып, 17 августта, иртәнге чәйне эчкәннән соң, Тоболга киттек.

16сында, иртәнге дүрттә үк торып, инде соңгы мәртәбә бер ау ләззәтен дә татып карыйк, дип, күлгә үрдәк атарга барган идек. Үләннәргә томан сарган бик матур иртә иде. Билдән чык ярып, шарт-шорт ата-ата йөрсәк тә, берни дә кыра алмадык. Соңра урманга кереп китеп, Якуб агай белән колхоз парторгы – Тукай дигән кеше – дүрт үрдәк атып чыктылар. Шуларны күтәреп, билләргә бик шәпләп патроннар тезеп, мин дә бик шәпләп карточкага төштем. Болай күңелле генә булды. Кайткач, Тукайлар кичке ашка да чакырган иделәр, тик иртән дә йокламаган, көн буе аяк өстендә уздырган, билләр дә язылмый, тиз генә әвен базына китеп бардык...

Иртән үрдәкләр бик шәп кызган иде, минем әле Тоболга соңгы барганда алып кайткан бер «Кабинет» бар иде. Якуб агай үзенең баллы настойкаларын эчә, мин «Кабинет» чүмерәм, шәпләп ашап-эчеп алдык. Машина иске булса да, борынга, бөркелеп, тузан, бензин исләре атылып торса да, юл озак та, ялыктыргыч та кебек күренмәде. РОНО инспекторы Әнвәр Саитов дигән егет теплоходка билет та алып куйган булырга тиеш иде. Хуҗайланнан килгәндә, шәһәргә якынлашканда, бер борылыштан Тобол бик матур, бик зур шәһәр булып күренеп китә. Иртеш борылып-борылып ага. Шәһәрне монда «тора»



Аяз һәм Нәкыя. 1988 ел

Аяз Гыйләҗев каләмдәше Якуб Зәнкиев һәм аның хатыны Рәшидә ханым белән. Казан. 1978 ел

диләр. Иртешне монда берәү дә Иртыш дип катылап сөйләшми, иркәләп, яратып, үз итеп, Иртеш, диләр. Суын бик яратып эчәләр. Якуб агайлар мәктәпкә казыткан скваженадан эчәләр, күрше-тирәләре дә шуннан ташый. Әмма картлар, Атыш акәләр, Дәүләтша акәләр Иртеш, суын, махсус кайтартып, чәйгә тоталар икән. Агым су – Иртеш суы, китәр көнгә кадәр иртә дә, кич тә коенырга йөрдем. Агым су – Иртеш суы, уң як ярын һаман ашап-җимереп бара. Хуҗайланның борынгыдан килгән зыяратын «ашый» башлаган. Якуб агай зыяратны күчерә алмыйча ике ел йөргән. Янәсе, зыяратка кем беренче булып күмелә – шуның нәселе бер-бер артлы җепкә тезгәндәй вафат булачак, дип әйтеп куйганнар. Шуннан инде онытылып беткән, картайган бер нәселсез бабайны күмәргә дип сүз куешканнар. Үзе дә: «Шунда, яңа урынга – тау ягына күмәрсез», – дип әйткән булган. Әмма Якуб агай кайдадыр, шәһәрдә вакытта, карт үлеп киткән. Онытылган-ташланган картның әллә кайдан кардәш-кабиләләре кайтып төшеп, теге сүзне кабатлап, картны тагын иске зыяратка җирләгәннәр. Ниһаять, ялгыз карт белән карчык: «Без бер-бер артлы үлсәк, бик хәерле булыр», – дип, картны яңа урынга куйганнар һәм аның карчыгы, бик таушалган, борчылган ятим карчык ике ел инде үлә алмыйча газаплана икән...

Иртеш ага да ага. Ярны җимереп, ком астыннан йөзәрләгән мамонтларның сөякләрен чыгара тора. Якуб агайның йорты Иртештән әллә ни ерак түгел. Ул, көлеп, болай ди: «Мин йортны шундый исәп белән салдым, мин картаям, йөрү авырлаша, миңа йөрергә уңайрак булсын өчен, Иртеш ел да миңа якынлаша. Кырык елда ул безнең йорт янына килеп җитәргә тиеш. Мин тәрәзәдән генә кармак салып утырачакмын», – ди...

Көлке көлә килә, Иртеш ярларны җимерә дә җимерә. Инде борынгы Күчем ханның башкаласы Искер дә су астында калган. Судан ачылып калган сул як ярга тизлек белән куе, тыгыз булып тал үсеп китә. Бу таллыкларга кеше аяк басарлык түгел. Иртеш үзенең юлын да үзгәртеп куя икән. Дугай ясап ага да, мә сиңа, кинәт кенә, дугайны ташлап, туп-турыдан бәрә. Үләртеш дигән урын шуннан калган. «Үле Иртеш»не торабара Үләртеш дип атаганнар.

Менә шушы авылларга, күп җирле, мул сулы халыклар арасына патшага зур җинаятьләр ясаган һәм аның эзәрлекләвеннән качкан Ермак дигән бандит килә. Татарлар аны күргәннәр. Атыш акә болай дип сөйләде: «Көбәк авылына Ермак килеп

чыккач, атарлар үзара сөйләшәләр икән, карачы, бу урыс нишләп йөри соң бу? Шундук үзләрен-үзләре юатканнар: әй, йөрсен гуй, монда җир җитәрлек!» Ә Ермак тик кенә йөрмәгән, ул барын караган, барын чамалаган. Шуннан, үз гаебен йолар өчен, патшага кайтып, аягына егылган: «Телисеңме, падишаһым, мин сиңа яланкул белән оҗмах кошын тотып бирәм?!»

Мин үзем сөйләшкән барлык кешеләрдән дә: «Ничек булган соң инде бу? Ни өчен читтән килгән бер бандит бер дәүләтне, бер ханлыкны бик тиз генә буйсындырган? Татарлар сугышта бик йомшак булганнармы?» – дип сорап карадым. Арада берсе генә – Айматулла акә күңелгә хуш килерлек җавап бирде: «Татарлар, аның ханнары да гаҗәп ярлы булганнар. Дин белән ташкан татарлар, «пәйгамбәрләребез фәкыйрь булган әле», дип, байлыкка, илнең ныклыгына игътибар да бирмәгәннәр. Аннары татарның үзен-үзе ашау гадәте дә бар бит аның», – дип куйды. Бу – тәбәнәк буйлы карт булса да, үзенең элекке солдат, элек җор егет икәнлеген онытмаган матур кеше миндә әйбәт истәлекләр калдырды. Хуҗайланга беренче булып будёновка киеп кайткан, колхоз оештырган, аның беренче председателе булган Айматулла акә татарча да – казанча әдәби итеп сөйли белә...

Менә Себер... Менә Иртеш...

«Себер» сүзе татар сүзе икән. Сип-йир, ягъни «җир сип» дигән сүздән алынган. «Иртеш» – шулай ук татар сүзе, «йирне тишүче, каты агымлы» дигән мәгънәне аңлата.

Мин менә шушы Себердә, менә шушы Иртештә «Генерал Карбышев» пароходында агып барам. Сәгатенә 22 километр барабыз, Төмәндә эшләнгән 800 ат көчле, 350 кеше утырырлык бу теплоход татар халкының улы – герой генерал-лейтенант Карбышев исеме белән аталган. Бу Омск урысы үзенең тумасы белән татар икән. Аны миңа Вагайда чакта Нурислам агай әйткән иде. Гомумән, Нурислам агай белән тагын бер очрашып сөйләшәсе иде. Татар исеменең каян килеп чыгуын да ул әйтте. Академик Ключевскийның китабында бу хакта шулай язылган, ди. Монголларның сугышчан отрядлары арасында «атта-атарлар» дигән частьлары булган икән. «Атта-атарлар» иң алдан бара торган булганнар. Шуннан, кыскара-кыскара, татар дигән исем кереп калган, имеш. Моның дөрес булу ихтималы бик бар. Тик нигә безнең матбугатта бу хакта берни дә язылмаган икән? Ключевскийны безнең галимнәр дә укыйлар бит? Әллә мин үзем генә абайламый калдырдыммы?

Сагынып, Аяз.

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ

1966 ел, 12 август, Тубыл, Хуҗайлан.

Шәүкәт, исәнме!

Китәр алдыннан тәки күрешә алмадык. Эшем ияләре булып киттек, әй! Мин күрешергә барырга торганда, әниең, урамда очрап: «Алар моннан бер сәгать элек кенә әллә кемнәргә киттеләр», – диде. Фараз кыла торгач, син, мөгаен, Юнысларга сәфәр тоткансыңдыр, дип уйладым...

Менә мин, кыш көне урап киткән йомгакны сүтеп, яңадан Иртеш буйларында йөрим. Төп урыным Хуҗайланда. Вагайга да барып кайттым. Кыш көне күрми киткән гаҗәп кызык бер кеше белән очраштык. Күпне күргән, күп укыган кеше. Укытучылар арасында беренче мәртәбә шулкадәр белемле, эрудированный кеше күрәм. Тарих укытучысы булган, хәзер операциядән соң авырып ята. Теге кыш булып узган кедр урманында булдым. Чикләвек тә җыйдык. Кышын туңа-ката үтеп киткән Иртештә иртә-кич су коенам. Якуб агай бик кунакчыл, киң күңелле кеше икән. Аның белән һич сүзебез бетми. Иртәгә Тобольскига китәм. Анда кунармынмы-юкмы, белмим. Баруым:

Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Ринат Мөхәммәдиев, Марат Әхмәтов, Аяз Гыйләҗев, Ренат Харис һәм Гарифҗан Мөхәммәтшин. 1994 ел

китү турында пароход белешергә. 20 августларда мин Иртеш буйлап төньякка – Обька чыгып, Салехардка сәфәргә чыгып китмәкче булып торам. Салехардта беркадәр торырга да исәп бар, әгәр инде гостиницаларында урын булса. Моңарчы һавалар бик әйбәт торды, менә ай урталарында көннәр бозылырга тиеш, дип язалар.

Мин һаман, әлеге дә баягы, шәйтан бабай таягы, дигәндәй, Казанда башлаган һәм һич тә бетерә алмаган пьесам белән утырам. Менә бүген икенче пәрдәне очлый яздым. Иртәгә иртүк аны тәмамлап куярга исәп. Өченче пәрдә кыска, киткәнче анысының да кәмәлен китереп куйсам, шәп булыр иде, ничек барып чыгар тагын.

Себер кызык икән ул, малай. Төрле уйлар, төрле борчулар тудырды. Татар халкының борынгы бер төбәге генә түгел, Татарстан татарларының эмиграция урыны да шул икән. Сөрген урыны да шул. Монда күп язмышлар чәбәләнгән, күп тарихлар кисешкән. Белмим, язып, аңлатып һәм кайберәүләр белән аңлашып булырмы...

Син инде хат язып тора алмассың. Кайчан бара әле бу хат, кайчан син аны килеп аласың, кайчан җавап язасың – ул арада мин тупырдап кайтып та җитәрмен әле. Салехардка пароход өч көн бара икән. Юлларның бик тыгыз чагында йөрергә туры килә инде. Тиздән студентлар кузгалалар. Алар – әрсез халык, күчәр башларың орынмасын, кыйнап та китәрләр...

Гаилә эчеңә, дусларга сәлам! Сиңа саулык-сәламәтлек теләп калам. Яңа китабыңны монда алып килдем.

Аяз.

РӘДИФ ГАТАШКА

1967 ел, 3 декабрь, Казан.

Рәдиф, картлач!

Хатларыңның барын да алдым...

Йөрәк сызлый...

Менә унбиш көн инде көн вә төн, йөрәк авыртуына түзә алмыйча, ишекле-түрле

йөрим. Күк – ямьсез, уйлар һаман шул: үз-үзеңне күмәсең... Матур башланган кыш та куандырмый. Нигәдер җан-тән арыган, сызлана да сызлана!..

«Казан утлары»на «Җиргә тапшырылган серләр»не биргән идем, басмадылар. Рафаэль: «Редакция членнарының барысы да басарга каршы булдылар», – ди. Хәй Вахиттан сорыйм: «Юк, – ди, – мин басу ягында!» Нил Юзиев үзе очрап әйтте: «Минем килешмәгән нәрсәләрем бар, әмма пьесаны басарга кирәк», – ди. Минем алда шулай сөйләшәләр, редактор янына кереп кара – гайбәт тараталар. Ибраһим Гази да: «Пьесаны басып булмый, Хәй Вахит та минем күз алдында редакторга шулай дип торды», – дип раслады. Ә редактор үзе кайда? Ул пьесаны укымады да... Секретарьлары Ләбибә дә шулай ук... Журнал редакциясенә «вотум недоверия» белдереп, каргап, пьесаны алып чыгып киттем...

Бу юлы мин Ибраһим Газиның намусына да ышанмадым... Пьеса басылырлык, аның әдәби кыйммәте мине шикләндерми, димәк, монда ниндидер башка көчләр басым ясаганнар!..

Әйдә, журналдан башка да яшәп карарбыз!

Урын, чин бездә кешеләрне ничек тиз боза!..

Гомумән, татар әдипләре соң дәрәҗәдә кабахәт кешеләр булганнар!.. 1937 елларны гына хәтерлә. Ничек бер-берсен чәйнәгәннәр, ашаганнар алар! Минем кулга «Фәтхи Бурнаш – сарайлар, морзалар, ханнар шагыйре» дигән бер китап килеп эләкте. Ул Фатих Сәйфи-Казанлылар, башкалар, шул ук Кутуй... ничек кенә кимермиләр Фәтхи Бурнашны!.. Хәзер дә шул ук гадәтләр яшәп килә! У-у, әгәр Шамовларга, Бәшировларга, Минскийларга хәзер 1937 елны кайтарсаң...

Димәк, пьесаны басмаганнар...

«Дружба народов» «Зәй энҗеләре»н кире какты...

Ярый, начар повесть... Тәрҗемәче генә кызганыч. Аннары «Дружба народов» начар журнал, минем анда басыласым да килми...

Журналның 11 нче санында «Ә син үзең кем, укучы?» дигән мәкалә бастырган идем, югары йортта өермә күтәрелгән. Цензорга һәм редакторга бик нык эләккән, пыр тузып, бөтенесе шуны күтәреп йөриләр, ди.

Ни өчен?

Ах, шулай бөтенесен кузгатырлык, йокыларын качырырлык әйбер язасы иде, юк, бер генә сүз әйтәсе иде, булмый шул! Куркаклар без, өркәкләр без!

Хат яз, сине сагынып, Аяз.

ТӘУФЫЙК САБИТОВКА

1972 ел, 17 ноябрь, Иске Руза.

Кадерле Тәуфыйк ага!

Мин 12 ноябрьдә Казаннан чыгып ычкындым әле, менә монда, Мәскәүдән 100 чакрымнар чамасында, урман арасында, тау башында, елга ярында эшләп яткан булам. Урын шәп, иптәшләр дә яхшы, тамак ягын да кайгырталар. Бүлмәм зур, җылы. Тышта гына күңелсез көз. Иртән – салкын, кич – җылы. Иртән кар, кич яңгыр, аяк асты пычрак, күк иске юрган кебек алама, аңа карамастан, эшлибез. Монда драматурглар семинары. Бер-беребезнең пьесаларын укыйбыз, яңалыклар белән танышабыз, үзебезчә мәш киләбез.

Казаннан сезгә хат салган идем, шәт, иншалла, алгансыздыр. Китәр алдыннан гына Оренбургтан фотоларны җибәрделәр, аңа бик куандым. Күз күргән кешеләрнең фотолары бар. Сагынганда карарга, дип, сезнең фотоны да салдылар. Тик карточкаларны

Безнең мирас №2 февраль 2018

Утырганнар (сулдан уңга): Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Рашат Низамиев, Хатыйп Миңнегулов, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баян, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин.
Басканнар: Харрас Әюпов, Ркаил Зәйдулла, Шәүкәт Галиев, Миркасыйм Госманов, Зиннур Хөснияр, Тәлгат Галиуллин. Казан

эшләп җибәргән кешегә генә хат язарга өлгермәдем, мәшәкать, ыгы-зыгы белән адресын да алмаганмын! Очрата калсагыз, бик зурлап рәхмәт тапшырыгыз үзенә! Инде исән-аман сәфәр йөреп кайткач, үзем дә язып җибәрермен.

Фотолар, бер яктан, шатландырды, икенче яктан, уйландырды.

Оренбургта йөргәндә күңелгә килеп-килеп тә, тышка бәреп чыгарга ирек бирмичәрәк йөргән уй-фикерләремне кабат уйлап алдым. Яшьләр юк сезнең арада, яшьләр! Ә яшьләрсез булмый, алардан башка ярамый. Яшьләрнең булмавы, аларның читләшүе, үз телләрен санга сукмаулары бик куркынычлы хәл! Кинәт кенә теге китапханәче ханымның: «Балаларымны татарча өйрәтә алмыйм», – дигән сүзләре искә килеп төште... Шундый зур, шундый иркен китапханәнең буп-буш салкынча заллары күз алдыннан узды... Һәм без, өлкәннәр, җыелдык та барын кайгыртабыз, барысы өчен борчылабыз... Кемгә тапшырырбыз без бу борчуларыбызны?!

Бер бик гыйбрәтле хәлгә игътибар итик... Әйтик, татар әдәбиятын Такташтан, Муса Җәлилдән, Шәриф Камалдан, Тинчуриннардан, Кутуйлардан һәм башка бик күпләрдән башка гына күз алдына китереп карыйк... Нинди ярлы, нинди мескен һәм нинди кечкенә булыр идек без! Ә менә ничә еллар инде безнең әдәбиятка, сәнгатькә чит өлкәләр бер кешене дә бирми. Инде Оренбургтан кусалар, Сыркыдыдан Такташлар берчакта да килмәячәк. Әгәр инде «алар руслаштылар, югарырак культура вәкилләренә күчтеләр», дип юаныр идең, руслар арасына да берәүнең дә өстәлгәне юк. Бөгелмәдән Магаданга китеп, Альберт Мифтахетдинов язучы булды да, Ренат Суфиев, чукынып, Роман Солнцевка әйләнде. Башкача ни татарга, ни руска талантлы кешеләрнең килеп керә алганы юк. Бу безне бик борчый. Татарстанда халкыбызның азчылыгы яши. Әле ярый Башкортстан безгә һаман-һаман талантларны өстәп тора. Ә бик күп өлкәләр сүнде, югалды.

Аяз. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

Туган телнең хәстәрчесе

Рифкать Әхмәтҗанов

Узган гасырның илленче-алтмышынчы елларында әдәбиятка куәтле дулкын булып кергән һәм җитмешенче-сиксәненче елларда гөрләп алган «яшь татарлар» арасында Хәсән Сарьян үзенчәлекле урын алып тора. Ул – язучы гына түгел, әдип татар мәдәниятенең төрле мәсьәләләренә кагылды, бигрәк тә татар әдәби теленең кайнар хәстәрчесе буларак танылды. Әле бүген дә, Сарьянның вафатына шактый еллар узгач та, аның исемендәге татар теле җәмгыяте оештыру турында сүзләр йөри...

Аның хакында язылган мәкаләләрнең кайбер исемнәрен генә карагыз: «Уелып калды уйлары» (И.Низамов, 1993), «Зур әдип әзер хакыйкать белән генә яши алмый» (В.Макарова, 2001), «Хөрмәтле Хәсән ядкәре» (М.Әхмәтҗанов, 2007)... Үзе вафат булганнан соң шактый сулар аккач та шундый җылы сүзләр илә искә алынган татар әдипләре бездә күп түгел.

Сарьян кебек затлар, тиешле шартлар булганда гына, безнең тормыш төпкеленнән калкып чыга. Хәзерге рәсми Башкортстанның күпчелек халкын тәшкил иткән Бакалы, Бөре, Бүздәк, Дәүләкән, Дүртөйле, Илеш, Кушнарен, Туймазы, Чакмагыш һ.б. төньяк-көнбатыш районнарында туып үскән шәхесләребез гаять күп. Ана телендә, ягъни татарча сөйләшүчеләр компакт төркем тәшкил иткән иң зур төбәк-регион да шул төньяк-көнбатыш Башкортстан һәм Сөн буе инде (Татарстандагы «Казан арты» исә икенче урында тора).

Хәсән Сарьян Башкортстанның Илеш районында, Татарстан чигенә якын гына аккан Минеште дигән кечкенә елга буендагы Иске Аю авылында туып үскән. 1945-1951 елларда (җиденчене бетергәч) Бөре педучилищесында укый һәм унбиш яшеннән алып шул якларда еш кына оеша торган күчмә концерт-театр труппалары эшендә катнаша башлый. 1951-1955 елларда Уфа педагогия институтында укып, Уфадагы татар матбугатында актив катнаша, «Кызыл Таң», «Совет Башкортстаны» гәзитләрендә, «Сәнәк» («Һәнәк)» журналында языша. Ул гадәти корреспондент-язучы булып кына калмый, бигрәк тә 1957 елда ачылган Башкорт дәүләт университетында укытырга чакырылгач, әдәби тел мәсьәләләре белән кызыксынып китә. Язучы буларак, ул баштарак юмор-сатира жанрында эшли. (Яшь артист чакларыннан калган бу хасият аның соңгы әсәрләренә кадәр сизелде). Аннары аның тематик нигезе тирәнәя бара. Ул лингвист галим буларак та камилләшә.

Язучының аерым китаплары чагыштырмача соң нәшер ителә, «Хикәяләр» (1962), «Классташлар» (1965), «Әткәм һөнәре» (1966), «Нокталы өтер» (1966) дигән кечерәк китапларыннан соң ул зур әсәрләр язуга күчә: аның «Бер ананың биш улы» (1976),

Хәсән Сарьян. 1970 нче еллар. (Фоторәсем М.Галиев архивыннан алынды)

«Егет язмышы» (1978) бәяннары – шундыйлардан. Тел гыйлеме бабында әдипнең «Уеңны уйдырып сал» (1977) китабы һ.б. публикацияләре (мәкаләләре) бар. Үзе 1978 елда (әле иллесе дә тулмаганда) вафат булгач та, аның әсәрләре татар һәм рус телләрендә нәшер ителеп килә.

Хәсән Сарьянга замандаш язучылар һәм әле алардан бераз яшьрәкләр дә сугыш хәлләре, сугыш һәм хезмәт батырлары турында язып, күренеклеләр рәтенә керде. Бу темаларга язганнарга сүз әйтеп булмый, аларны мактадылар, хупладылар, изге мәүзугълары, дип әйттеләр. Әмма артка карамыйча алга барып булмаган кебек, гел артка карап та алга барылмый һәм язучыларның алдынгы бер төркеме ваемлы замандашларның һәрберсен борчыган: «Ничек яшибез һәм ничек яшәрбез?» – дигән сорауга җавап эзләргә алынды.

Һәм менә яшь татар язучыларыннан беренчеләрдән булып, бу кирәкле, катлаулы һәм җаваплы, хәтта тайгак («бу социалистик реализм түгел», дип әйтүчеләр күп табылыр иде) темага, минемчә, беренчеләрдән булып Хәсән Сарьян алынды.

Аңа кадәр «көндәлек» темаларга Әмирхан Еники, Фатих Хөсни кебек өлкән язучылар, Габдрахман Әпсәләмов һәм аңардан яшьрәк Гариф Ахунов һ.б. зур-зур әсәрләр иҗат итте. Тик аларның язган әсәрләре, кайсылары киләчәгебез мәсьәләләренә кагылса да, «производство романы» кысаларында язылдылар. Хәсән Сарьянның әсәре сугыштан

соңгы чорда беренче «гаилә романы» иде. Һәм бу җәһәттән Галимҗан Ибраһимовның атаклы «Яшь йөрәкләр» романын хәтерләтте. Асылда, һәр ике романда да «Якын киләчәктәге үзгәрешләр каршында татар халкы нишләргә тиеш?» мәсьәләсе куелган иде кебек. Ул әсәрләрдә шәхси фаҗигаләр якынлашып килгән иҗтимагый-тарихи давылларның чагылышы булып тора.

Мин аның белән 1957 елда яңа ачылган Башкорт дәүләт университетына кергәч таныштым. Сарьян абый анда татар әдәби телен укыта башлаган иде. Ул чагында аның кечкенә генә бер юмористик хикәяләр китабы чыккан һәм ул чагыштырмача яшь иде әле. Уфадагы өенә – фатирына барып, җыйган китаплары белән танышып йөргәнем хәтеремдә. Гадәттә студентлар мөдәррис (укытучы) өенә барып йөрми. Ләкин миңа рөхсәт иттеләр. Җәмәгате Тәкмилә ханым да каршы булмады.

Укыткан чагында, дәрес биргәндә ул студентлар белән эчкерсез-ихлас әңгәмә кора, җанлы вә җылы итеп сөйли, үзе елмая-көлә, студентларның күңеленә керергә тырыша иде. Күрәсең, мондый манераны конферансье «әртист» булып йөргән чакларында, тамашачы белән аралашкан-сөйләшкән елларында үзләштергәндер.

БДУда ике ел укыткач, 1959 елда ул Казанга килеп урнашты. Шуннан соң берара, 4-5 ел дәвамында, мин аны күрмәдем. 1963 елда Казанга килеп, ИЯЛИгә *(хәзерге көндә Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. –* **Ред.***)* эшкә урнашкач, мин тагын (ничек килеп чыкканын хәтерләмим) аның өенә еш кына барып йөри башладым һәм арабыз ул вафат булганчы өзелмәде. Әмма дә утырдашлык-табындашлык дәрәҗәсендәге якынлык та булмады.

Казанда Хәсән абыйга язучы Мирсәй Әмир фатирын биргәннәр иде (аңа исә, фронтовик булгач, яхшырак фатир тәгаенләгәннәр иде бугай). Финанс институты янында (өстәрәк) урнашкан агач өйнең икенче катын биләп тора иде ул.

1972 елда җәен Хәсән абый бөтен гаиләсе белән ялга киткәндә өендә хатыным белән миңа торып торырга тәкъдим итте. Шунда бер ярты айлап тордык бугай. Ул елларда Хәсән Сарьянның, Фатих Хөсни әйтмешли, «гөрләгән чагы» иде. Хәсән абыйга төрле кардәш-туганнары да килгәли иде, шулай да өендә безне яшәргә калдырды.

Ләкин бераздан Хәсән абыйның матди хәле мөшкелләнеп китте булса кирәк. Бермәлне ул миңа шәхси китапханәсендәге кайбер китапларын сатып алырга тәкъдим итте...

Берара ул себер татарлары турында нәрсәдер язмакчы булып, берничә ай Себердә торып кайтты. Яздымы-юкмы, эшләгәнен белмим, миңа күрсәтмәде.

Хәсән ага Сарьян тәкәллефсез, иркен зат иде. Ул өенә килгән кеше белән ачык вә кунакчыл сөйләшә, аның янында якташлары, фикердәшләре еш күренә иде. Якташы, шагыйрь Зыя Мансур, мәсәлән, анда үзен өендәге кебек хис итә – идәндә утырып, Хәсәннең кечкенә малайлары белән туп тәгәрәтеп уйнаганын күргәнем бар.

Шунысы үтә кызганыч – бер гаиләви афәт турында язган язучы кайчакта үзе дә шул ук афәткә дучар булучан. Эчкечелек фәләкате турында язган Хәсән Сарьян белән дә шулай булды бугай. Атаклы америкал язучысы Джек Лондон кебек... Ул да, «Мартин Иден» дигән романында дөньясын каһәрләп, океан уртасында корабтан суга сикергән кеше турында язгач, озакламый үзе дә мордарлык юлы белән дөньядан киткән.

Бу хәлләрдән соң шактый еллар узды. Мин кайбер нәрсәләрне онытып та бетергәнмендер, тик аның нурлы вә сагышлы йөзе, бигрәк тә җанлы вә мәгънәле итеп сөйләшүләре һәрвакыт күз алдыма килә. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Нурсөя һәм Фәнис. 1974

Татар теле

Фәнис Яруллин
(1938-2011)

Дәүшурада бара зур җыелыш,
Шурачылар сөйли кызып-кызып.
Президиумның озын өстәленә
Татар телен кемдер салган сузып.

Хирурглар, ягъни шурачылар,
Зур өстәлгә таба игән башын.
Кайсы чеметә телне, кайсы тешли,
Хәл итмәкче алар Тел язмышын.

Сүзен башлый берсе: менә бу Тел,
татар теле була, господалар.
Үстермәскә... Тьфү, үтермәскә
Берәр чара кирәк булыр аңар.

Икенчесе, Телгә караш ташлап,
Микрофонга мондый аваз сала:
– Бу тел үлгән инде, әфәнделәр,
Иң яхшысы: ясин чыгыйк аңа.

Залдан кычкыралар: браво, браво.
Ясин чыгыйк тизрәк. Тергезмик.
Татар халкы тыйнак, сабыр халык,
Бик килешә аңа телсезлек.

Телле халык азып-тузып йөри,
Яман сүзләр әйтә, сүгенә.
Телсезләрне теге дөньяда да
Утырталар оҗмах түренә...

Шул чагында өстәлдәге зур Тел
Чәбәләнеп куйды, сикерде.
Ә аннары, тыгыз залга карап,
Лачт иттереп берне төкерде.

Зал бермәлгә тынып калды кинәт,
Гаҗәпләнү чыкты йөзләргә,
Тел үлмәгән! Димәк, монда инде
Башка хәйлә кирәк эзләргә.

Эзли торгач, бәхәсләшә торгач,
Бер чарасын уйлап таптылар:
Өстәлдәге Телне алдылар да
Авыз эченә кертеп яптылар.

...Тел өстеннән һаман хөкем бара,
Кисеп ташларга да чыкмый җай.
Бикле авызда Телебез бәргәләнә
Амнистия көткән тоткындай.

Шигырьне басмага Р.Акъегет әзерләде. ■

ҮТКӘННӘН ҮТЕНЕЧ

Бер төркем әдипләр Шәйхи Маннурның туган авылы Тулбайда. Рәсемдә (сулдан уңга): Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники. 1965 ел

1969 елның башларында Мөслим районында әдәбият атналыгы үткәрелә. Татарстанның халык шагыйре Рәдиф абый Гаташ әйтүенчә (ул каләмдәшебез, әлеге чарада катнашучыларны күргән һәм алар белән аралашкан Наис Гамбәр истәлеген укып хәбәрдар икән), әдәбият атналыгында Казаннан Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, Абдулла Сәләхетдинов, Касыйм Фәсәхов кебек язучылар (барлыгы унлап каләм әһеле) катнаша. Тантаналы бер очрашу вакытында берничә язучыга «Мөслим районының Почетлы гражданины» дигән мактаулы исем бирелә. Атаклы «Йөзек кашы» авторы Фатих Хөснинең Татарстан Язучылар Берлеге идарәсенә язган үтенечендә әлеге мактаулы исем турында сүз бара.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенә
Союз члены, язучы
Фатих Хөснидән

ҮТЕНЕЧ

Әле теге вакытта ук, без Мөслим районында әдәбият атналыгы уздырган вакытта, мөслимлеләр безне – берничә кешене – шул җөмләдән мине дә, «Мөслим районының Почетлы гражданины» дигән мактаулы исем белән бүләкләгән иделәр. Моны аклап, бәләкәй бер хикәя бастырудан бүтән, рәтле-башлы бер эш тә күрсәтә алганым юк. Бу турыда күптән уйланып, борчылып, туры килгәндә сорашкалап йөрим.

Сораша торгач, тирәсеннән биеп китәргә ул якларда бер «мич» тә табылырга тора. Миңа Мөслим районындагы алдынгы һәм үткән (тормыш. – **Л.Л.***) юлы бик тә*

Фатих Хөсни эш бүлмәсендә

Безнең мирас №2 февраль 2018

гыйбрәтле бер председатель турында сөйләделәр. Казына белеп казынганда, ул тирәдән башка «асылташлар» да табылырга тора, имеш.

Аллага тапшырып, мин тәвәккәлләргә булдым. Әлбәттә, газета очеркы гына түгел, урынга барып, бераз чокчынырга-өйрәнергә туры киләчәк. Шул максат белән миңа аз дигәндә бер айлык иҗат командировкасы бирсәгез икән. Соңгы ун ел төшендә (эчендә, дип укырга кирәктер. Диалект сүзе, күрәсең. – **Л.Л.***) Союздан һәм Литфондтан хәтта шырпы да сораганым юклыкны истә тотып һәм, аннары, фәкыйрегезнең дары базында әлеге дарының бөтенләй үк бетмәгәнлеген дә истә тотып (моны шушы бер бит кәгазь үзе үк күрсәтеп тора!), бу үтенечемне кире какмассыз, дигән өмет белән: Фатих Хөсни. 11.VIII. 1969 ел.*



Татарстан Язучылары Союзы идарәсенә

1 айга иҗат команд. 12/VIII – 69

Союз члены, язучы Фатих Хөсническә

Үтенеч

Әле тегеЛ вакытта ук, без Мөслим районында әдәбият айналыгы уздырган вакытта, мөслимлеләр безне – берничә кешене –, шул җөмләдән мине дә, «Мөслим районының Почетлы гражданины» дигән мактаулы исем белән бүләкләгән иделәр. Моны аклап, бәләкәй бер хикәя бастырудан бүтән, рәтле-башлы бер эш тә күрсәтә алганым юк. Бу турыда күптән уйланып, борчылып, туры килгәндә сорашкалап йөрим.

Сораша торгач, тирәсеннән бией кирәгә ул якларда бер «мич» тә табылырга тора. Миңа Мөслим районындагы алдынгы һәм үткән елы бик гыйбрәтле бер председатель турында сөйләделәр. Казына белеп казынганда, ул тирәдән башка «асылташлар» да табылырга тора, имеш.

Аллага тапшырып, мин тәвәккәлләргә булдым. Әлбәттә, газета очеркы гына түгел, урынга барып, бераз чокчынырга-өйрәнергә туры киләчәк. Шул максат белән миңа аз дигәндә бер айлык иҗат командировкасы бирсәгез икән. Соңгы ун ел төшендә Союздан һәм Литфондтан хәтта шырпы да сораганым юклыкны истә тотып һәм, аннары, фәкыйрегезнең дары базында әлеге дарының бөтенләй үк бетмәгәнлеген дә истә тотып (моны шушы бер бит кәгазь үзе үк күрсәтеп тора!), бу үтенечемне кире какмассыз дигән өмет белән:

Фатих Хөсни
11.VIII.1969 ел

Әдипнең бу үтенече игътибарсыз калмаган: кемдер кәгазьнең өске сул як өлешенә зәңгәр кара белән «1 айга иҗат команд. 12/VIII – 69» дип язып куйган.

Мәшһүребез Фатих Хөсни бу иҗат командировкасына баргандыр, язарына чынлап та «азык» алып кайткандыр, дип ышанам. Кем белә, бәлки берәр галим моңа киләчәктә ачыклык кертер.

Үтенечне ***Ләбиб Лерон*** *укыды.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

«Күңел дәфтәре»ндәниләр бар?

Лирон Хәмидуллин



2011 елның ахырында Татарстан китап нәшрияты Гомәр ага Бәшировның көндәлек язмаларын аерым китап итеп бастырып чыгарган иде. «Күңел дәфтәре» дип исемләнгән ул китапны олуг әдибебезнең улы Зөфәр Бәширов нәшриятка әзерләп биргән. Бу җыентыкка әдипнең биш калын дәфтәргә төрле елларда теркәп барган истәлек язмалары кергән. Беренче дәфтәрдәге беренче язма 1937 елның 13 февраленә карый. Бишенче дәфтәрдәге соңгы өч җөмләле язма 1999 елның май башында теркәлгән. Ә китапның соңгы битендәге соңгы җөмлә, Зөфәр кулы белән язылганы: «Әдип Гомәр Бәширов 1999 елның 7 май таңында вафат булды», – дигән сүзләр белән тәмамлана. Нәкъ шул көнне Гомәр агага 98 яшь тә 4 ай тулган була.

Бу җыентык белән таныштыру өлешендә Зөфәр Бәширов: «Көндәлекләр берникадәр кыскартылып бирелә», – дип белдерә. Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре, олуг әдип белән кырык ел чамасы аралашып яшәгән Равил Фәйзуллин язган.

Безнең өлкән язучыларыбыз арасында көндәлек вакыйгалардан истә калырга тиешлерәкләрен «куен дәфтәренә» теркәп бару тәртибе яшәп килде. Шундый истәлек дәфтәрләренең Афзал Шамов, Госман Бакиров, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах варислары кулында сакланганын беләм. Мәсәлән, бер очрашу вакытында Афзал ага андый истәлек язмаларын 1919 елдан яза башлаганын, Госман ага исә шул эшкә 1923 елда, Ятим балалар йортында тәрбияче вазыйфасын үтәгәндә керешкәнлеген сөйләгән иде. Өлкән буын әдипләреннән Шәриф Камалның да көндәлек дәфтәрләре булган. Ләкин, «буржуй Рәмиевләр белән якын мөнәсәбәттә торганлыгын чагылдырган урыннар теркәлгәнлектән, кызы Зәйнәпнең аны яшереп тотуын» әйткәләүчеләр булды.

Гариф Ахуновның җитди генә җыелышлар барышында да, куен дәфтәрен алга куеп, нидер язып утыруларын хәтерләүчеләр бардыр. Мондый эшкә һәвәслек аңарда илленче елларда ук туа. Туксанынчы елларда, кайбер чордашларының, мәсәлән, Мирсәй ага Әмирнең шундый язмалары матбугатта күренгәли башлаганда, мин аңа берничә мәртәбә:

— Синең көндәлекләрне дә укыр көннәр җитте бугай. Нишләп аларны «Казан утлары»на күрсәтмисең? – дип әйткәләгән идем.

– Вакыты җитмәгән әле, – дип җавап кайтара иде ул.

Ә бер мәртәбәсендә:

– «Совет әдәбияты» редакциясендә һәм Әлмәттә эшләгән елларымда хәзерге классикларыбызның кайберләренә карата байтак кына тәнкыйди фикерләр дә язган булганмын. Аларны әлегә чыгарасым килми, – дип әйтте.

***

Без мәктәптә укыган кырыгынчы елларда, Тукай, Такташтан кала, әдәбият аксакаллары исемлегендә тагын 5-6 кеше генә бар иде шикелле. Шәриф Камалның «Матур туганда»сыннан өзекләр, Гомәр Бәшировның «Сиваш» повестен, Афзал Шамовның «Госпитальдә» хикәясен, Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен, Ибраһим Газиның «Катя Сорокина»ларын укып үстек. Әлбәттә инде, китапханәдән дә иң әүвәл шул авторларның китапларын алып укый идек.

1948 елда «Совет әдәбияты» журналының берничә санында Гомәр ага Бәшировның «Намус» романы басылып чыкты. Ул вакытта Казан каласыннан мең чакрымдагы безнең Иске Актауда журналны мәктәп китапханәсе дә, авыл советы карамагындагысы да алдырта иде. Авыл халкының әлеге әсәрне чират торып укыганлыгы хәтеремдә. Ә безнең өйдә аны кыш дәвамында 5-6лап хатын-кыз – авылыбызның Нәфисәләре – бергә җыелып укыды. Кул эшләрен тотып килерләр дә, шул эшләрен онытып, күз яшьләрен сөртә-сөртә, Гомәр ага язганнарны тыңлап, әсәрләнеп кайтып китәрләр иде... Әнинең апасы ул елларда кырчылык бригадасы бригадирыныың кул астында исәп-

хисап эшләрен башкаручы – учетчик иде. Бригадир бабай кырда сирәк булганлыктан, барлык эш диярлек аның җитәкчелегендә алып барылды.

1960 нчы елларда, бер очрашу вакытында, мин бу вакыйганы Гомәр агага да сөйләп бирдем.

– И-и, ул елларда миңа төрле-төрле яклардан шундый хатлар бик-бик күп килде. «Намус» бит ул вакытта журналның өч санында басылды (№1-3). Кайберәүләр, киләсе санның килеп җитүен көтмичә, фәлән-фәлән хәлләр ничек төгәлләнә, дип түземсезләнеп сорап та язалар иде. Ә менә үзебезнең кайберәүләргә ул әсәр ошап бетмәде, «Кызыл Татарстан» газетасында аны тәнкыйтьләп язып чыктылар. Миңа аны яңадан төзәткәләргә, яңадан эшләргә туры килде, – дип сөйләгән иде әдип, урман аша Аккош күле дачасына таба икәүләп барган бер кичтә...

Шул вакыттагы сөйләшүне дә искә төшереп, кызыксынып, әдипнең «Намус» романын иҗат иткән, басмада чыгарган еллардагы көндәлек язмаларын укыйм. Әйе, бу романны язу уе Гомәр агада 1943 елның җәендә, Балык Бистәсе районындагы бер авылда ике атна чамасы яшәп алганнан соң туган икән. Әдип шул авылга автомобиль авариясеннән соң, хастаханәдә ятып бераз терелә төшкәч, табигать шартларында сихәтләнергә дип барган булган. Сырхау Гомәр аганың Кама буендагы авылга әлеге сәяхәте нәкъ урак өсте көннәренә туры килгән. Булачак роман әүвәл аның күңелендә авыл тормышына багышланган бер хикәя рәвешендәрәк бөреләнә башлаган. Шуннан соңгы өч-дүрт ел дәвамында инде ул әсәр әлеге роман кысаларына кергән.

Бервакыт Гази ага Кашшаф белән бер атналык сәяхәттә бергә йөреп кайткан идек. Литфонд оешмасының ике елга бер уздырыла торган исәп-хисап корылтаена барып, бер бүлмәдә яшәп, байтак хәлләр турында гәп кордык. Шул сәяхәт вакытында ул миңа Гомәр ага белән кайчандыр бик якын мөнәсәбәттә булганлыгын, «Намус» романы кулъязмасының һәр битен кат-кат укып, авторына бик күп киңәшләр биргәнлеген дә сөйләде. «Радиокомитетта эшләгәндә Гомәр ага төрле-төрле районнарга командировкаларга да йөри, колхозчылар тормышын яхшы белә иде», – дигән иде ул.

Инде янә Гомәр аганың көндәлегенә күз төшерик. Менә 1947 елның 30 ноябрендә теркәлгән язма. «Биш елдан бирле түземсезләнеп, зарыгып көткән куанычлы көннәр килеп җитте. «Намус»ны тәмам итеп, ниһаять, соңгы өлешен 24 ноябрьдә «Совет әдәбияты»на тапшырдым. Аны укыйлар. Әле берәүнең дә кире фикер әйткәне юк».

Роман журналда басылып чыга. Күпсанлы укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. «Гомүмән, яхшы фикердән башканы ишеткән юк иде», – дип яза автор көндәлегенә. Кулъязма инде китап нәшриятына тапшырылган көннәрдә, көтмәгәндә генә, «Кызыл Татарстан» газетасының 1948 елгы 13 октябрь санында «Намус» романының кимчелекләрен бәян иткән мәкалә басылып чыга. Партиянең өлкә комитеты карамагындагы газетада эшләүче өч авторның – Фатих Хөсни, Фәтхи Балыкчы һәм Фатих Мөсәгыйтьнең уртак хезмәте. «Намус» романының уңышына «кайбер бәндәләрнең ифрат эчләре пошты, кара көйделәр, күтәрә алмадылар, көнчелектән шартлый яздылар», – дип, көндәлегенә язып куя әсәр авторы бу мәкаләне укыгач. Ул мәкаләне табып укымастан, Гомәр ага әйткәннәрне генә искә төшереп язам: әлеге язучылар авторның төп гаепләреннән берсе итеп романда партия тормышының кирәгенчә тасвир ителмәвен күрсәткән булалар. Шушы вакыйгалардан соң Киевтә, Украина язучылары корылтаенда булып кайткач, әдип дәфтәренең 1949 елның 18 февраленә караган битендә тагын түбәндәге җөмләләрне өстәп куйган: «Гомумән, мин бу эшемнән канәгать. Ул әнчекләр тик өрә бирсеннәр! Аннан миңа ни зарар?»

Автор шулай дип үз-үзен тынычландырырга тырышса да, күңел тынычсызлыгы тиз генә басылмый, әлбәттә. «Нәшриятка хәзер шик төшә. Ә Мәскәүдә тәрҗемәне тукта-

тырлар. Менә сиңа нәтиҗә!» – дип, соңрак язып куя автор. Нәшрият директоры Закир Тинчурин белән киңәшергә була. «Акыллы, тәҗрибәле, кешене аңлый торган кеше» белән киңәшүдән соң: «Партия райкомы идея җитәкчесе булырга тиеш», – дигәнрәк фикергә киләләр.

«Үз заманының каһарманы» дип аталган кереш сүз авторы Р.Фәйзуллин да, шушы вакыйгаларны да истә тотып булса кирәк, мондый сүзләрне яза: «Хәзерге яшьләрнең ул чор Совет әдәбияты үрнәкләренә үз карашлары бар – тәнкыйди караш, – ди. – Әмма үзләре шул заманда яшәп иҗат итсәләр, нишләгән булырлар иде икән? Кемнәргәдер «Намус» романындагы Нәфисә образы ясалма булып тоелырга мөмкин. Онытмыйк, Нәфисәләр берничә буынны тәрбияләде. Начарга тәрбияләмәделәр бит. Шунысы мөһим».

Бик-бик хак сүзләр. Нәфисәләрдәй уңган, калку образлар тудырган олуг әдипнең хезмәте – «Намус»ы тел-логать һәм әдәби сурәтләү җәһәтеннән дә онытылырга тиеш булмаган әсәрдер дип уйлыйм мин. Кайберәүләргә ул әсәрнең Сталин премиясенә лаек булганлыгы да ошап бетми шикелле. Роман начар булганга түгел, «начар кеше» – Сталин исеменә бәйле булганга күрә генә аны «танырга» теләмәүчеләр дә бар. Ләкин ул премия дә бит бу әсәргә җиңел генә бирелмәгән. Көндәлек язмаларыннан күренгәнчә, Татарстан җәмәгатьчелеге аны өч мәртәбә тәкъдим иткән. Өченче мәртәбәсендә, әсәрнең русча тәрҗемәсе «бөек, даһи җитәкчебез» кулына эләккәч кенә «Намус» романы икенче дәрәҗә бүләккә лаек дип табыла.

Элекке семинарист Иосиф Сталинның әдәбият, сәнгать кешеләре белән турыдан-туры элемтә тотуы, әдәби әсәрләрне шәхсән үзе укыганлыгы турында күп мәртәбәләр яздылар. Аның «Намус» романын йөгертеп кенә күздән кичергән булуы да зур дәрәҗә. Шундый дәрәҗәгә ирешкән Гомәр агабыз өчен без бүген дә куанырга тиештербез, шәт. Янә авторның үзенә сүз бирик. 1950 елның 23 декабре: «Бу арада «Намус»ның корректурасын укыдым. Гаҗәп. Ничәнче тапкыр басыла инде. Татарчасының гына да 3 нче мәртәбә басылуы. Ә һаман да төзәлә, яхшыра бара. Сыек яисә кабатланган, бик үк уңышлы әйтелмәгән урыннары һаман да очрый әле». Бу җөмләләрдән авторның үз-үзенә, иҗатына карата ни дәрәҗәдә таләпчән булганлыгы чамалана. Ә бит бер язылган кулъязмага кабат кул тыкмаучылар, шул хакта башкаларга мактанып сөйләп йөрүчеләр дә бар.

Соңгы сүз итеп Г.Бәширов көндәлегендәге тагын бер язмага тукталып үтик. 1966 елның июленә караган язма ул. Икенче бер олуг әдип, күренекле сүз остасы Әмирхан Еникинең әдәбиятка багышланган бер кичәдә әйткән сүзләрен искә төшереп, көндәлек авторы болай дип язган: «Ә.Еникинең минем «Намус» турында фикерен элек ишеткәнем юк иде. Ул мондый фикер әйтте: «Докладчы «Намус» романыннан бик отышлы үрнәкләр китерде. Роман аңа лаек. «Намус» романының кыйммәте халыкның сугыш вакытындагы патриотик хисләрен, фидакяр эшләрен югары художество чаралары ярдәмендә күрсәтүдә генә түгел. Ул үзенең әдәби кыйммәте белән, бик отышлы табылган детальләре белән дә кадерле».

Көндәлек авторы башка әсәрләренең язылу тарихларын да искә ала, әлбәттә. Ләкин ул алар турында бик алай җәелеп язмый. Китапта әдипнең чордашларына, якын күргән каләмдәш дусларына багышланган, аларның әсәрләренә бәя биреп киткән аерым битләр дә бар. Үзенең фикердәшләренең фикере белән килешеп бетмәгән очракларны теркәп куюны да кирәк тапкан әдип.

Гомәр ага Бәшировның «Күңел дәфәре» китабын мин яхшы бер роман, авторның үзенә багышланган роман кебек, йотлыгып укып чыктым. Әдәбият сөючеләргә дә аны алып укырга тәкъдим итәм. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

Үзем һәм юбилеем турында

(Көндәлектән)

Гомәр Бәширов

Бүген миңа 90 яшь тулды. Гаҗәп бит. 90 бик күп бит ул, көтелмәгән хәл. Минем авыруларым бик күп. Мин аларның кайсын майлап, кайсын җайлап дигәндәй юатып киләм. Шулкадәр авыруларым була торып, һич тә 90 га җитәрмен дип көтмәгән идем. Бик тә гаҗәпләндерде бу хәл.

Бүген иртәдән бирле телефон янында китә алмадым. Бик күп кешеләр чын күңелдән тәбрик иттеләр. Телеграммалар, открыткалар бик күп килде. Арадан чамадан тыш күперенке мактау сүзләре әйтүчеләр дә бик күп иде. Әйдә, ярар инде, 90 еллык үзенә күрә бәйрәм бит инде ул, бәйрәмдә исә иркен күңелле булырга, кешеләргә каты бәрелмәскә кирәк.

Балалар белән тыйнак кына мәҗлес уздырдык. Мин балаларга һәм оныкларыма безне борчымаулары, әдәпле һәм акыллы булып үсүләре өчен рәхмәт әйттем. Чыннан да, Кәримә белән шушындый өлкән яшькә җитә алуыбызга алар да ярдәм итте бит, безне борчымадылар, тыныч булдылар.

1991, 7 гыйнвар

Тәбрикләр әле һаман да дәвам итә, телеграммалар килеп тора.

Соңгы елларда мин күп кеше белән аралашмыйча, күп эшләргә катнашмыйча, йомыграк тормыш белән яши башлаган идем. Шул сәбәпле мине күп кеше белми, акрынлап оныта башладылар дип күңелсезләнеп тә куйгалый идем. Минем соңгы елларда язган публицистик парчаларым кемнең генә күңелен кузгатсын, ул бит, ни әйтсәң дә, туйдырып бетергән сәясәт кенә. Аны кем генә аңлый?..

Юк, алай гына түгел икән, тыңлыйлар, укыйлар, кадәри хәл һәммә чыгышларга үзләренчә бәя биреп баралар икән.

Моңа мине байтак кешеләр әйткән фикерләр ышандырды.

Башкалар арасында һич көтмәгәндә Шәриф абзый Камал кызы Зәйнәп ханым тәбриге ишетелде. Радиодан чыгышымда Шәриф абзый хакында берничә җылы сүз әйткән идем. Шуның өчен Зәйнәп ханым бик дулкынланып рәхмәтләр әйтте.

Ул да түгел, элек радио дикторы булып эшләгән Рәисә Волкова тәбрик итте. Элекке артистлар, мәдәният әһелләре хакында язганнарым бик ошаган икән, сезнең шикелле олы кешеләрнең истәлеге бик кадерле, диде. Юк, гомер юкка узмаган, нindiдер эз кала икән әле.

1991, 9 гыйнвар

Үзең хакында язуы кыен. Ләкин 90 еллык бәйрәм хакында бер дә әйтмичә калу да дөрес булмас иде.

Үзем дә гаҗәпләнәм. Ничек мин 90га җиттем икән? Атам – 63тә, анам – 57дә, абыем 74 яшендә вафат. Бәлки, бабалар, әбиләремнән кемдер озак гомерле булгандыр, бәлки, шу ларның тазалыгы, буыннан-буынга килә торгач, миңа насыйп булгандыр?

Гомумән, без үзебезнең нинди нәселдән килгән кешеләр булуыбызга тиешенчә игътибар итмибез. Болай бит, гаделлек юлыннан барганда без үзебездәге бик күп яхшы сыйфатлар өчен ата-аналарыбызга, нәселебезгә бурычлы.

Безнең әти безнең нәселне Симәкәйме, Сәмәкәйме нәселе дип атый иде. Ихтимал, ул бик борынгы, бик сәләтле нәсел булгандыр. Ләкин аның тарихы бер урында да язылып калмаган лыктан, без ул нәсел хакында берни дә белмибез. Әмма шунысы бар: хәзер шул нәселдән килгән берәүне талантлы дип мактыйлар икән, ул кешенең мин фәлән, мин төгән дип масаерга хакы юк. Әгәр дә ул талант акыллы кешегә бирелгән булса, ул иң әүвәл үзенең борынгы нәселенә бурычлы булуын истә тотарга тиеш. Күрәсең, шул Сәмәкәй нәселеннән бер ир затында яки хатын-кызда ул талант ничектер балкып та алгандыр. Әйтик, моннан берәр мең ел элек яки аннан да элегрәк, кайдадыр Монголия якларындагы бер тау мәгарәсеннән чыгуына тулган айга күзе төшеп әллә нишләп китә. Ай шундый якты, аннан күзләр чагыла. Ә һава тын. Якын тирәдәге куе үләннәр арасында чикерткәләр гөрелди, кайдадыр, ерак та түгел, ниндидер дала хайваннары чыелдый, бик еракта, тауның борылышынданиләрдер елтырый, төрле төсләр уйный. Шуларга карап минем әбием, әллә йөзенче, әллә йөз илленче булачак әбием, күңеле рәхәтләнүгә түзә алмыйча, айга карап, башын чайкый-чайкый җырлап җибәрә. Аның күзләре ярым йомылган, озын кара чәче иңнәренә җәелеп биленә кадәр асылынып төшкән, аның күңелендә ниндидер бер сәер тойгы туа, аның менә шул рәхәтләндерә, үзеннән-үзе җыр булып яңгырап чыгарга ашкынган тойгыны башкаларга да ишеттерәсе килә. Минем ул йөз илленче әбиемнең җырының әле исеме дә булмагандыр, ул яшьлекнең табигать матурлыгына сокланудан туган бер күңелле җилкенүе, шул җилкенүнең көй булып, җыр булып тышка бәреп чыгуы булгандыр.

Минем әбиемнең матур тавыш белән моңлы итеп көйләве башкаларның да күңелен кузгаткандыр, мәгарәдән берән-берән чыгып яшьтәшләре, туганнары аның тирәсенә җыелганнардыр, моңаеп тыңлаганнан соң, аның иңбашына кулларын салып, ул вакыттагы телдә аңа рәхмәтләр әйткәннәрдер.

Бәлки, ул әбиемдәге талант чаткысы аның нәселеннән

килгән берәүдә сөлгеләр чигү осталыгы яисә хәттат* маһирлеге булып балкып алгандыр, һәрхәлдә, миндәге яки бүтәндәге талант яки сәләт бүген генә тумаган, аның җеп очы бик борынгы әби һәм бабаларыбызга барып тоташа, чишмәнең башы бик ерак гасырларда ук тибеп чыккан булса кирәк.

Шул сәбәпле, димәк, миндәге яки бүтәндәге талант ул минеке яки синеке генә түгел, ул нәселдән килә. Ул ниндидер формада, моң рәвешендәме, төскә гашыйклык, чичәнлек булыпмы безнең бабаларыбыз белән монгол далаларын да, Урта Азия чүлләрен дә узган. Болгар илендә дә, Казан ханлыгында да балкып алган, үзенә бик күп чор һәм заманнарның тәэсирен саклап хәзерге заманга килеп җиткән. Бу – нәселдән килә торган, берни белән дә чагыштырмаслык рухи байлык. Аның кадерен белеп, күз карасыдай сакларга, тагын да үстереп, киләчәк буыннарга тагын да баетып калдырырга кирәк. Көчең, сәләтең мөмкинлек биргән кадәр, билгеле.

1991, 14 февраль ■

*Хәттат – каллиграф.

Йәгез, бер дога!

Утызынчы еллар...

Күпме фаҗига кичергән, күпме күз яше, кан түккән чор...

Дөньякүләм хокук белгечләре иң гуманлы дип таныган Сталин Конституциясе дә вәхшилекләр, ерткычлыклар кылырга киртә булмый. Хәер, «төп канун»ның бу илдә кайчан асыл мәгънәдә Төп Канун булганы бар соң?!

Ул чор корбаннарын санап чыккан арада да чәчең агарырлык...

Һәрберсенең «эше» калын-калын китапларда урын алырга, аерым өйрәнелергә лаек. Шөкер, андый китаплар юк түгел. Алардагы кайбер сәхифәләрне барлыйк.

Йәгез, бер дога!

АФЗАЛ ТАҺИРОВ
(1890-1937)

Язучы, драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Мөхетдин улы Таһиров 1937 елның 11 августында партиядән чыгарыла. (Аңарчы Башкортстан Үзәк Башкарма комитеты (БашЦИК) рәисе булып эшли.)

1937 елның 16 августында, «террорда, милли фетнәчеләр оешмасында катнашуда» гаепләнеп, СССР Югары суды хәрби коллегиясенең карары нигезендә «халык дошманы» дип кулга алына һәм Мәскәүгә озатыла. Анда әдипне каты җәзалап, сорау алалар, «үз гаебен танытып», кул куйдырталар һәм 1937 елның 23 сентябрендә атып үтерәләр.

Җәсәде Мәскәүнең Дон зиратында җирләнә.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан:

Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.422.

ФАТИХ КӘРИМИ
(1870-1937)

1937 елның 4 августында Фатих Кәримине (җитмешкә җитеп килгән картны!) Мәскәүдә кулга алалар. 27 сентябрьдә СССР Югары судының хәрби коллегиясе әдипне үлем җәзасына хөкем итә. Хөкем карары шул ук көнне гамәлгә ашырылган, дип фаразлана.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.706.

ФӘХРЕЛИСЛАМ АГИЕВ
(1887-1938)



Фәхрелислам Агиев – егерменче еллар ахырында ОГПУ тарафыннан фальсификация юлы белән махсус оештырылган һәм «Солтангалиевнең контрреволюцион оешмасы» дип исемләнгән «җинаять эше» буенча кулга алынган татар зыялыларының берсе.

1930 елның 23 июлендә ОГПУ коллегиясе аны атарга хөкем итә.

1931 елның 13 гыйнварында шул ук коллегия, алдагы карарын үзгәртеп, үлемгә хөкем ителгәннәрнең җәзасын унъеллык концлагерь белән алыштыра. Ләкин алда аталган «эш» буенча гаепләнүчеләрнең күпчелеге 1937-1938 еллардагы «зур террор» чорында кабат җавапка тартылып, НКВД «өчлек»ләре карары белән янә атарга хөкем ителә. Шулар исемлегендә Фәхрелислам Агиев та була. Ул 1938 елда Мәскәү төрмәсендә атып үтерелгән, дип фаразлана. Кабере билгесез.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.10.

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН
(1887-1938)

Газиз Гобәйдуллинны (тәхәллүсе – Г.Газиз) 1937 елның 18 мартында Азәрбайҗан Фәннәр академиясенең бертөркем галимнәре белән бергә кулга алалар. Абруйлы галимне «солтангалиевчелек»тә, фән хезмәткәрләре, студентлар

арасында милләтчелек, пантюркизм идеяләре таратуда, совет хакимиятенә каршы яшерен оешмада әгъза булып торуда, Төркия, Алмания, Япония файдасына шпионлык эше алып баруда гаеплиләр. Шул елның сентябренә кадәр өзлексез дәвам иткән сорау алу, тән җәзалары куллану нәтиҗәсендә, баягы «гаепләрне» танырга мәҗбүр итәләр. 1937 елның 7 сентябренә әдип-галимнең «җинаять» эше буенча тикшерү төгәлләнеп, шул ук елның 12 октябрендә СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе Газиз Салих улы Гобәйдуллинны, хосусый милкен конфискацияләп, атарга хөкем итә. 1937 елның 13 октябре таңында Газиз Гобәйдуллинның гомере өзелә. Әдип-галимне физик-бәдәни юк итү белән бергә аның әдәби һәм гыйльми хезмәтләре дә кулланыштан алына, исеменә табу-тыю мөһере салына.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.295.

МАНСУР КРЫЙМОВ
(1898-1938)

Утызынчы елларның икенче яртысында, сәламәтлеге начараю һәм матбугатта шәхесе-иҗатына карата тәнкыйть сүзләре ишәю сәбәпле, Мансур Крыймов күренекле язучы, Башкортстанның Үзәк Башкарма комитеты (БашЦИК) рәисе Афзал Таһировның шәхси чакыруы буенча, Мәскәүдән Уфага күчеп килә.

Таһиров, «террорда, милли фетнәчеләр оешмасында катнашуда» гаепләнеп кулга алынганнан соң, Крыймовка да чират җитә: аны 1938 елның 1 августында Уфа төрмәсендә атып үтерәләр.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.733.

ГАЛИМ МӨХӘМИТШИН
(1911-1938)

Шагыйрьне 1937 елның 26 октябрендә кулга алалар. Ул, бер төркем яшь язучылар Ибраһим Салахов, Сөббух Рәфыйков һ.б. белән берлектә, «халык дошманы» Галимҗан Ибраһимовны илле яше тулу уңаеннан котлап язылган күмәк хатка имза куюда «гаепләнә». Бу факт аны милләтчелектә, советка каршы яшерен оешма төзү, совет һәм партия

җитәкчеләренә террористик һөҗүмнәр әзерләүдә һәм башка «җинаятьләр»дә гаепләргә нигез була.

Шагыйрь СССР Югары судының 1938 елның 10 маендагы карары белән үлем җәзасына хөкем ителә. Карар шул ук төндә гамәлгә ашырыла.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.149.

ГОМӘР ТОЛЫМБАЙ
(1900-1938)

Режим *(һәрвакыттагыча! онытма, кешелек!* – **Р.М.***)* рәсми идеологиягә һәм сәясәткә ихлас бирелеп хезмәт иткән каләм ияләренә дә мәрхәмәт күрсәтми. Рәхимсез дәүләт террорына Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) да килеп эләгә. Ул 1937 елның 8 июнендә кулга алына. 1938 елның май аена кадәр Казанның Плэтән төрмәсендә утыра. Кайбер каләмдәшләре әйтүенчә, әдип бер елга якын дәвам иткән җәза-кыйналулар нәтиҗәсендә акылыннан яза һәм 8 майда ашыгыч хөкем карары нигезендә атып үтерелә.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.438.

ФАЗЫЛ ТУЙКИН
(1887-1938)

Шагыйрь, драматург, фольклорчы, тарихчы, мөгаллим Фазыл Кәрим улы Туйкин 1936 елда НКВД тарафыннан махсус оештырылган һәм тарихка «Һади Атласичылар эше» дигән исем белән кереп калган «милли контрреволюцион хәрәкәттә», «Төркия файдасына шпионлык итүдә» гаепләнеп кулга алына. 1937 елның 23-28 октябрь көннәрендә бу «эш» буенча җавапка тартылган егерме дүрт кешегә Казанның Менжинский исемендәге клуб бинасында ябык суд ясала. Идел буе хәрби округы трибуналы карары белән тугыз кеше, шул исәптән Һади Атласи үзе, Фазыл Туйкин һәм аның абыйсы Кәбир Туйкин үлем җәзасына – атарга хөкем ителә.

Хөкем карары 1938 елның 15 февралендә гамәлгә ашырыла.

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.444.

Язмаларны
Рузәл Мөхәммәтша
әзерләде. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

Тимерче Фатих

Локман Закир

Уникe яшьлек Фатих, бабасының тимерчелегендә чын-чынлап эшли башлаганнан соң, кайчан да булса 80 мең чакрымны тәпиләп узармын, дип башына да китермәгәндер. Әмма Түбән Ушмы зиратына орынып диярлек аккан көмеш челтерәүле инеш буендагы тимерче алачыгында башланган юл шундый булып чыга.

Әүвәл Беренче Бөтендөнья, аннары исә Гражданнар сугышында аның күп җирләрне кыдырып йөрисе бар әле. Менә шулай җиһан гизеп әйләнеп кайтса, этисе көтеп тормаган, гүр иясе булган. Бабасының алачыгы да туздырылган. Инде үз куллары белән ак таш актарып, алачыкны сипләп яңадан торгызам дигәндә генә, төзү-яңарту түгел, юньләп тимер сугарга да бирмиләр, НЭПны бетерүгә, алачыгын тартып алалар. Әмма тимер остасы һөнәри мөһеренә бервакытта да тап төшерми! Аңа баш иеп, гозер белән бөтен Мамадыш өязе килә. Ул, урта хәллеләр исемлегенә кереп, тамак ялгарлык кына тәгам ише аны-моны таба ала иде.

Фатих – Гражданнар сугышы яугире

Ләкин Советлар акылына төкерәсеңмени: рас урта хәлле икәнсең, димәк, син кулакка якын. Фатихның балаларын мәктәпкә алмыйлар. Ни өченме? Күп кенә өйләрнең салам түбәләрендә ишеләм-ишеләм дип сыңар морҗа тырпаеп торганда, нигә соң әле аның шыгырдап торган гәрәбә бүрәнәләрдән салынган алтыпочмаклы йорт түбәсендә ике тимер торба ялтырап утыра?! Шуннан Фатихка, «ярлы» булып күренер һәм дә балаларын мәктәптә укыттырыр өчен, бүтәннәрнеке сыман бер генә морҗа калдырырга туры килә. Дөресендә, ике мичнең дә төтен юлын берләштереп, бөтен авылныкы кебек, түбәгә бер генә морҗа чыгара ул. Силсәвит бу хәйләне сизенсә дә, Фатихның ярлылар сафына «омтылуына» каршы килми. Шул рәвешле, тимерче балалары, мәктәп бусагасын атлап кереп, белем эсти башлый.

Авыл башлыклары барыбер кырын карагач, Фатих тимерче булып агробазага, «Мамадыш» совхозына эшкә күчә. Өлкән буын кешеләре хәтерлидер әле: ул елларда МТСлар – машина-трактор станцияләре барлыкка килгән, алар авыл хуҗалыгына шактый гына ярдәм күрсәтә иде. Фатих райком кушуы буенча шунда күчерелә, шулай кендегеге ахыргача МТСка бәйле булып кала. Еллар уза, яңа директорлар килеп китә тора, МТСлардагы политбүлекләр юкка чыгарыла, ә тимерче эше көн дә кирәк, аның алачыгы рәшәдәй күгелҗем төтенне һәрдаим төтәтә бирә.

Кырыгынчы еллар башында Фатих кылны кырыкка ярырлык шундый камил белгечкә әверелә ки, аны хәтта фронтка да җибәрмиләр. Сугыш чорында безнең якларда туплар гөрселдәмәсә дә, тәрәзәләре маскировка япмалары белән томаланган тимерчелектә тимер сукканнары тәүлекләр буена еракка ук ишетелеп тора. Фатих кайвакыт атналар дәвамында өйгә кайтмый, сандалы янында гына черем итеп ала, бәрәңгесен дә мичкә тәгәрәтә, кишер чәен дә шунда пешерә. Сугыш елларында ир-ат җитмәгәнлектән, тимерне аңа Клава исемле 17 яшьлек бер кыз чүкешә.

Фатих үзенең гомер юлын, Җир шарын ике мәртәбә чорнап алырлык чакрымнарын санап тормас та иде, бәлки. Вәләкин аның бер хасияте бар: үзләренең тимерчеләр нәселендә иң озак яшәүче – ул. Аның этисе һәм берничә буын бабасы, тын юлларына тимерчелекнең авыр, зыянлы тузаны утырып, хәтта 50 яшькә дә җитмичә вафат булган. Хикмәт шунда: бабаларының алачыклары өйләреннән берничә адымда гына (бер караганда әйбәт инде югыйсә). Алар, үпкәләре көне буе тимер тузаны йотканнан соң, ач карыннарын аннан-моннан канәгатьләндереп, арып-талып шундук түшәккә ава торган булган.

Фатихка исә гомерен озынайту өчен нәкъ менә өенең ерак булуы ярдәм иткән дә инде. Ул МТСка 8 чакрымнан килеп йөри. Эштән соң, ирексездән, аңа аулак юлдан тәпиләргә, үпкәләрен саф һава белән җилләтергә туры килә. Еш кына ул карга бата-чума атлый, юл өзегендә пычрак ера. Ярый әле адашмас өчен телеграф баганалары бар. Шулай да, ара-тирә буранда юлны югалткалый, шул ук вакытта адашкан мосафирларга да таяныч була. Бүреләргә каршы торырга да туры килгәли аңа. Кыскасы, өстенә яңгыр-кар түгел, таш яуса да, бербөтен ипи кыстырып, газиз балалары, хатыны янына кайтып җитәргә кирәк. Алар капка төбенә чыгып дүрт күзләп көтеп торганда, ничек инде кайтмыйсың ди?!

«Тимерчене зиярәт кылырга килүчеләр ташта сурәтләнгән чүкечне, аның да гадиен генә түгел, сандал өстендә чаткылар чәчтереп торган чүкечне, дулкынланып, күздән кичерәдер...»

***

...Әле кайчан гына «Сельхозтехника» берләшмәсенең Мамадыш районы бүлегендә кем дә булса ташландык иске сарай янында ап-ак сакаллы сәер генә бер картны күрә иде. Карт кайчандыр ак таштан салынган, ләкин кайбер ташлары коелып төшкән бу сарай тирәсендә үз-үзе белән сөйләшеп йөри, аның мүкләнгән диварын калтыраулы куллары белән сы-

Локман ага якташы, каләмдәше вә адашы Марат Закир белән. 2017 ел

пырып куйгалый, шунда йөзе, хәзинә тапкандай, яктырып китә иде. Бүтәннәргә берни дә белдермәгән диварлар, гүяки җанланып, аңа күп нәрсә хакында сөйли: биредә карт тәүге тапкыр МТС ның беренче директоры – «егермебишмеңче» Морозовны күргән, аннары алар икәүләп эре-эре ак таштан шушы алачыкны корганнар иде. Тимерчелеккә еш кына МТСның баш агрономы, бик ачык күңелле Мөгыйнов сугылгалый иде... Тик бахыр, кырда суык тидереп, бик иртә дөнья куйды. Монда ул көн саен алмадай кызыл битле, чукмар башлы кувалда тоткан Клава һәм бүтәннәр ярдәмендә тимерне, йомшак балавыз дәрәҗәсенә җиткереп, әллә ниләр кыландырып бетерә иде...

Хәзер инде хезмәт ветераны, тимерче Фатих җир куенында «йоклый». Гүргә иңсә дә, «Тимерче» кушаматын мәңгегә ташламаска ниятләгән, ахры. Ни кызганыч, Әби патша заманыннан, ягъни сугышлар һәм казалар белән тулы чал дәверләрдән бирле тимер тапап килгән нәселенең иң соңгы буыны булган ул. Шуңа күрә дә, тимер осталары тамгасы мәңге саклансын диптерме, ул аны кабер ташына алдан ук уеп калдырган. Тимерчене зиярәт кылырга килүчеләр ташта сурәтләнгән чүкечне, аның да гадиен генә түгел, сандал өстендә чаткылар чәчтереп торган чүкечне, дулкынланып, күздән кичерәдер...

Редакциядән:

Журналыбызның иң өлкән яшьтәге авторы, язучы һәм публицист Локман ага Закирга (Локман Фатих улы Закировка) 19 февральдә 90 яшь тула. Тынгысыз күңелле вә актив каләмле аксакалыбызны ошбу күркәм вакыйга белән ихластан котлап, аңа сәламәтлек, имин тормыш, тыныч картлык һәм иҗат уңышлары телибез. ■

ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ!

ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА – 85 ЕЛ

Татарстанның халык шагыйре Илдар Гафур улы Юзеев 1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районында Ямады авылында укытучы гаиләсендә туа. 2004 елның 21 декабрендә Казанда вафат була һәм Яңа бистә зиратында җирләнә.

АБЗЫЙ БАТМАС ИДЕ...

Билгеле мәзәк. Русча белмәгән бер абзый, Казанга килгәч, су коеныргa төшкән икән. Бервакыт бу, тирәнгәрәк кереп, бата башлаган.

– Ныряю! – дип кычкыра икән русча яхшы беләм дип уйлаган абзый.

Пляжда кызынып ятучылар:

– Ныряй, ныряй, ныряй! – дип әйтә икән, көлә-көлә.

Абзый, бата-калка, соңгы тапкыр кычкыра:

– Еще раз ныряю!

Тамаша кылып утыручылар һаман көлә, ди.

Абзый иң соңгы тапкыр калкып чыгып:

– Последней раз ныряю! – дигән дә, көлү тавышлары астында, су төбенә киткән...

Фаҗига белән тәмамланган мәзәк. Минемчә, абзый үзе гаепле. Нигә инде аңа рәхәтләнеп үз телендә: «Батам, коткарыгыз! – дип кычкырмаска? Мөгаен, татарча аңлаучы яки үз телен онытырга өлгермәгән берәр адәм табылыр иде!

Туган телнең тылсымлы көченә ышанырга кирәк шул!

Илдар Юзеев

Дуслар-фикердәшләр – Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев, Фасил Әхмәтов һәм Мирсәет Яруллин

Безнең мирас №2 февраль 2018

ГӨЛЧӘЧӘК ГАЛИЕВАНЫҢ ТУУЫНА – 90 ЕЛ

Язучы-прозаик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик язмалар авторы Гөлчәчәк Кәрим кызы Галиева (Яхина) 1928 елның 5 февралендә Татарстанның Арча районындагы Сеҗе авылында туа.

САФ МӘХӘББӘТ ҮРНӘГЕ

«Гөлчәчәк һәм Әхмәт Галиевләр калдырган мирасның бер өлеше – саф мәхәббәт үрнәге. Галиябану белән Хәлилне сәхнәдән тормышка күчереп, мәхәббәтләрен үлгәнче, ягъни 63 ел буена сүндерми яшәтә алган гаҗәеп пар бит бу! Алар 1951 елның 30 апрелендә язылышкан. Яңа гаилә Әхмәт абыйга 20 яшь тулган көнне туган...

Гөлчәчәк апа – 2014 елның 11 маенда, Әхмәт абый исә 2015 елның 24 гыйнварында вафат булды. Каберләре Арча районының Сеҗе авылы зиратында». Рәфикъ Юныс, «Алардан шәп мирас калды». («Безнең мирас», №11, 2016)

ДУСИЛ КАСЫЙМОВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Татарстанның атказанган артисты (2002) Дусил Гаяз улы Касыймов 1943 елның 7 февралендә Мамадыш районының Иске Комазан авылында туа.1974 елда Казан театр училищесын тәмамлый һәм Республика күчмә театрына кабул ителә. 1975 елдан 2003 елга кадәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. 2008 елның 12 июлендә вафат була, Иске Татар бистәсе зиратында җирләнә.

Уйнаган рольләре: Денщик – «Качаклар» (Н.Исәнбәт), Казый – «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт), Андреев – «Зифа» (Н.Исәнбәт), 1 нче кунак – «Кишер басуы» (З.Хәким) һ.б.

ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРЕВНЕҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйрев 1938 елның 15 февралендә Татарстанның Октябрь районы (1997 елдан Нурлат районы) Әхмәт авылында колхозчы гаиләсендә туа. 2009 елның 29 июлендә Ульяновск өлкәсенең Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә вафат була.



СЕЗ МИНЕМ ЙӨРӘГЕМ
(Көндәлектән)

21 ноябрь 1966 ел

«Рәсемнәрем – сез минем күзләрем, шигырьләрем – сез минем йөрәгем. Рәсемнәрем, мин сезне ясаудан туктап сукыр калыйммы? Шигырьләрем, сезне язудан баш тартсам, минем өчен ул йөрәгем тибүдән туктауга караганда да авыррак булыр иде...» ■

Зәмһәрир суык иртә. Г.Сәгыйрев рәсеме

Безнең мирас №2 февраль 2018

САБАКТАШЫМ, ИҖАТТАШЫМ...

(Мактаулар бозмаган, дан-дәрәҗәдән үзгәрмәгән егеткә мәдхия)

– Шундый да кеше буламыни? – диярләр кемнәрдер.

– Бар шул! – дим мин, бәхәскә урын калдырмас ышаныч белән һәм кулыма драматург, төзүче-автор Юныс Сафиуллинның «Ринат Таҗетдинов» дигән саллы китабын алам.

Бу китапта Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Дәүләт премияләре лауреаты, орден-медальләр кавалеры, сәхнәдәге казанышларын хуплап бирелгән «Алтын битлек»кә ия Ринат Таҗетдинов турында әдәбият-сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре белән җәмәгатьчелек тарафыннан танылган абруйлы талант ияләре, һөнәр белгечләре, сәхнәдәшләре һәм артист үзе язган уйланулар, әңгәмәләр, мәдхияләр – һәркайсы фәнни хезмәткә тиң нигезле, тирән эчтәлекле хатирә.

Шул китапның бүләк язуында (автограф), Ринат миңа «сабакташым» дип мөрәҗәгать итә. Әмма мин, барыннан да элек, аның тамашачысы да бит әле!

Бу язмамның исеменә «мәдхия» дип куйсам да, максатым китап каһарманын мактау гына түгел. Кайбер урыннарда «чеметкәләсәм», Ринатның үпкәләмәвенә өметләнүдән. Әйтик, мәсәлән, китапны бүләк иткәндәге язмасында җибәргән вак хаталары өчен: «Талантлы дустыма, исәнлек теләп, теләгән яшеңә җитүеңне теләп...» – ди ул. Бер җөмләдә дүрт хата күбрәк түгелме? «Теләк тели белмәсәң, имгәк», диләр бит. «Талантлы дус» нинди була да, «талантсызы» нинди була? Бу безнең Ринатыбызның кешеләр белән мөнәсәбәттә һәркемне үзенә тиң итеп күрергә теләвеннән киләдер. Шуңа күрә «дус» дигәнгә «талантлы» сүзен дә өсти ул. Ә чын талант ияләренә ул сүзнең кирәге юк.

Без «талантлы артист Райкин», «талантлы актер Ильинский» дип әйтсәк, бу даһи артистларны кимсеткән кебек булабыз. Шулай ук «талантлы режиссер Станиславский», «талантлы Шукшин», «талантлы Ринат Таҗетдинов» дигәндә дә, «талант»сүзе бу исемнәрнең дәрәҗәсен күтәрми. Чөнки бу исемнәр үзләре дәрәҗәдән өстен, күтәрүләргә дә, терәүләргә дә мохтаҗ түгел.

Язмама «мәдхия» дип куйсам да, максатым сабакташымны мактау гына түгел.

Аның, артист һөнәрен «иярләгәннән» башлап, һәр тапшырылган рольнең серен ачуда кулланган универсаль «ачкычының» кайда саклануын беләсем килә. Хәзергечә әйтсәк, компьютерны эшләтеп җибәрү өчен кирәкле паролен, артист буларак һәр рольнең бикле йозагын ачкан ачкычның серен ачарга телим. Бармы ул? Юкмы? Миңа

гына түгел, бу Ринат иҗатына гашыйк һәр тамашачыга кызыклы ачыш булыр иде.

Мәгълүм ки, ул инде күптән мактауларга мохтаҗ булмаган кебек, казанышлары белән мактанулар да аңа ят. Мәдхия сүзләрен дә Ринат, балыкка тоз сипкәндәй күпме сипсәң дә, үзенә кирәк кадәр генә сеңдерә дә, калганына «без внимания».

Өченчедән, мактыйсың икән – ул, йолдыз ачкандай, яңа ачышка тиң булырга тиеш. 60 ел буена ул ачкан йолдызлар саны йөздән арта («Ринат йолдызлыгы» дип атарга була). Шулар җемелдәвеннән яңа йолдызлар әлегә безнең күзгә чалынмыйлар. Ә бит, һәр яктылык – йолдыз балкысын өчен, шарт буларак, караңгылык кирәк.

Октябрь бәйрәме демонстрациясенә чыккач. Мәскәү. 1956 ел

Хәзерге лазерларның күләгәсез нуры хакимлек иткән, караңгылык тансык заманда, күктән яңа йолдыз эзләүне «пүчтәк әкият» дип карасак та, өметсезлеккә бирелмибез – яңа йолдыз кабыначак! Кемдер: «Ринат үзе йолдыз ич инде, яңа йолдыз ачасы юк аңа», – дип пышылдый. Кушылабыз. Әйе, Ринат уйнаган рольләр үзе бер йолдызлыкны тәшкил итәрлек. Бер көн килер һәм астрономиядә «Ринат Таҗетдинов йолдызлыгы» да пәйда булыр.

Мактауларга мохтаҗ түгеллеген белсәм дә, үзем дә сизмәстән, Ринатны мактау тональностенә күчеп барам икән.

Җиткәндер, булгандыр. Ринат кебек, вәгъдәдә торыйк. Уен-көлкеләрне, кинаятөрткеләрне калдырып, 60 ел элек булган-күргәннәргә күчик. Бәлки Ринат иҗатына ачкыч-пароль шундадыр.

Без, сабакташлар гына түгел, бүлмәдәшләр дә идек. Мәскәүнең Трифонов урамы, 58 нче баракның (әсир немецлар төзегән) 1 нче каттагы 17 нче бүлмәсендә. Ринатның ятагы, ишектән кергәч, уң як дивар буенда икенче караватта иде. Беренче караватта Батулла, Ринат белән янәшәдә Рәшит Галиәкбәров, түрдәге ягылмый торган мич артында – Туфан Миңнуллин, сул дивар буенда Мир-Мирич, Дунаев һәм Зарипов караватлары. Аларның барысы бертөрле булса да, пөхтә итеп җыелганлыгы белән, Ринатныкы

бүлмәгә ямь биреп торыр иде. Ятагы гына түгел, кием-салымы да, савыт-сабалары да пөхтәлек, төзеклек ягыннан һәркайсыбызга үрнәк булды. «Үрнәк», дигәннән, аның язу каллиграфиясенең үрнәк булырлык матурлыгы турында билгеләп үтәсем килә. Күп чакта, рәсмирәк язулар кирәк булганда, аннан яздыруыбыз хәтердә.

Мин үзем, хәтта Җәмиләмә өйләнергә рөхсәт сорап, бабайларга хатны да Ринаттан яздырдым. Соңыннан, өйләнешеп яши башлагач, балаларыбыз булгач, гаиләбездә ниндидер аңлашылмас узгынчы «чытыклыклар» килеп чыкканда, бабай мәрхүм ишек кашагасына кыстырылган шул «тарихи» хатны алыр иде дә, кызы Җәмиләгә, ягъни

Үзебез яшәячәк тулай торак төзелешендә. Мәскәү. 1957 елның язы

минем хатынга карап: «Кияүгә чыкканда без ризалык биргәненә чыкмавың галәмәте бу», – дияр иде.

Соңыннан аңлавыбызча, кызларын сорап язган кияү ишек кашагасында сакланган матур язылган хат хуҗасы булган! Көлсәң – көләрлек, еласаң еларлык факт булса да, бу – Ринатка мәдхия!

Без, сабакташлар гына түгел, сердәшләр, табындашлар да идек. Болары турында Батулла белән Туфан язганнарга әллә ни өстәп булмас, «шәкертлек» эпизодларын хәтерләү кызыклырак булыр. Ринат шәкерт чагыннан ук иҗат кешесе булды, дисәм, әле исән курсташларым, «арттырасың», димәс.

Ринатлар гаиләсендә 5 малай, 1 кыз үсә. Һәр балага бүлеп бирелгән үз эше була. Ул эшләр тиешле сыйфатта башкарылу өчен олылары кечеләрен күз уңында тотса, бердәнбер кыз исә малайлар өчен әти-әни каршында җаваплы. «Эшсез кеше – ашсыз» кагыйдәсе аларның һәркайсының канына кечкенәдән сеңдерелгән. Ринат «ялт» иттереп идән юарга да өлгерә, кием-салымын да үтүкләми кими, эш арасында ашарга пешерергә дә җай таба. Ашау мәсьәләсенә килгәндә, мин аның «тәмсез» дип аш сайлаганын хәтерләмим. Гомумән, тамакка талымсыз иде ул.

Дәресләрдән качканын да, сайланып, назланып утыруын да хәтерләмим. Артистлыкка укысак та, безнең һөнәргә ят тоелган дәресләребез дә күп иде. Конспектлар язып баруда ялкаулык көчле булгач, бөтен ышаныч Ринатта булды. Ул яза. Почеркы әйбәт, семинарлар вакытында аның дәфтәрләренә чират торабыз.

Ничәнче курста булгандыр, безне автомашина йөртергә өйрәтә башладылар. Өч дәрес «теория» булса, атнага бер көн практика – рульгә утырабыз. Бу эштә Ринат белән Батулла безнең механикларыбыз: әйтерсең, гомергә машина йөрткәннәр! «Машина» дигәннән, «Мастерство» дәресләрендә беренче курста бездән этюдлар эшләтәләр иде.

Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивалендә 1 нче урынга лаек булган (1978 ел) «Йолдызлар җитә һәркемгә» фильмында (Әхсән Баяновның «Тау ягы» повесте буенча) катнашучылардан бер төркем

Минем әткәй Агыйделдә маякчы булып эшләгәч, этюдымны маякчы эшенә бәйләп, «шаккаттырырга» булдым. Класс бүлмәсендәге урындыкларны көймә итеп, «воображаемый» ишкәкләр белән «ишеп, көймәгә фонарьлар төяп, сүнгән фонарьларны алыштырырга» кереп киттем». Бик тырышып уйнадым. Көймәне маяк станогындагы бавыннан ычкындырып ярга чыккач: «Все», – дидем.

Ә Ринат өстәл һәм урындыклардан «ДТ» тракторы ясап, аны «кабызды» да «җир сөрә башлады». Укытучылар «җитте», «хватит» дигәч кенә, тракторын сүндереп, урынына барып утырды.

Этюдларны сүтү, анализлау башланды.

Яшермим, мактау көттем. «Агымсу», «дулкыннар», «көймәне бәйли алмый газапланулар»... Сәхнәдә күрсәтү өчен кыен күренешләр исәбенә «скидка» ясалыр, дип көткән идем – булмады. Укытучыбыз башта мине «сүкте», ягъни, минем этюдны сүтте. Имеш, агымсу тәэсирен «сизмәгәнмен», ишкәкне гел бертөрле «ишкәнмен», сүнгән лампаны дөрес «кабызмаганмын» һ.б. Ике минутлык этюдны 20 минут «сүтте». Ә менә Ринатның «тракторны» ярты сәгать кабызуына кул чаба-чаба, «гаси свой мотор», дип мактый башлады. Ә мин, озын-озак маташканы өчен, аны да «сүтәр» дип көткән идем, хәлфәбез аны башкаларга үрнәк буларак күрсәтеп, «син тракторның холкын каян шулай яхшы өйрәндең?» – дип, Ринатның тәрҗемәи хәлен сөйләтте. Шунда без Ринатның этисе

Арифҗан абзыйның авылга беренче тракторны алып кайтуын, Шәйморза МТСында баш инженер булып эшләвен, сугыштан «бронь» белән калдырылып, хатын-кыз тракторчылар курсын оештыруын, районны иң алдынгы механизаторлар районы иткәнче эшендә калуын, гаиләләрендәге 6 баланың 5есе ир бала булуын, аларның кечкенәдән эш белән, техника белән тыгыз бәйләнештә үсүен белдек.

Нәтиҗәдә, Ринатка «5»ле куелып, миңа «3»ле булуны хәлфәбез: «Һәр эшне бөтен ваклыклары белән, кабаттан эшләмәслек, төзәтмәслек итеп, җиренә җиткереп эшләргә кирәк. Сәхнәдә һәр ваклык булганыннан эрерәк булып күренүне беркайчан да исегездән чыгармагыз. Эшнең эшләнү ритмы да, аңа булган мөнәсәбәт тә иҗатта мөһим роль уйный. Бер кабынып, бер сүнү сәхнәгә игътибарны сүндерә.

Ә менә Зариповның «маякчысы», болары эшләмичә дә аңлашыла ич инде, дигәндәй, «тисә тиенгә – тимәсә ботакка» булды. Тәҗрибә үрнәге буларак, бу этюд та кирәкле сабак», – дип аңлатты.

Укытучыбыз бу фикерләрне, әлбәттә, рус телендә белдерде. Аның күзгә карап һәркайсыбызга биргән киңәшләре бүген дә хәтердә. Талантына өстәмә һәр эшкә кирәкле шөгыль дип карап, аны ике эшләмәслек, төзәтмәс сыйфатлы итеп башкару – Ринатның фамильный иҗат ысулы, дияргә була. Йөзләгән спектакльдә йөздән артык роль башкарган актер биографиясендә Ринат аркасында «провалга» юлыккан, «харап булган» спектакль юк.

Әлбәттә, ул катнашкан спектакльләрнең озын гомерле булуы да, уңышсызлыкка очравы да бер артист яки режиссер иҗатына гына бәйле түгел. «Провал» яки «уңышсызлык» сүзләренең безнең Академия театры спектакльләренә карата ишетелгәне булмаса да, «Антонио-Клеопатра» спектаклен шул бәхетсез категориягә кертми булмый. Бу, әлбәттә, театр тарихындагы «ЧП» һәм аның өчен төп гаепле кеше Цейтлин – Рус яшьләре театры (ТЮЗ) режиссеры. Хәзер инде сирәгәеп калган сабакташлар белән очрашып әңгәмә корып утырганда, режиссер Цейтлинны гаепләп сөйли башлагач, Ринат аны да яклап чыкты: «Шекспирның «Давыл»ын Рус яшьләр театрында куеп, үзе җитәкләгән театрга «Алтын битлек» алышкан режиссерның безнең театрда спектакль куярга ризалык бирүе, «Европа» үлчәмендәге сыйфатлы спектакль куеп бирәчәкмен», дигән вәгъдәсе, безнең Шекспир трагедиясендә уйныйсы килү хыялларыбыз миражга әверелде дә калды шул. Бу провал искә төшкәндә, әле һаман аркамда салкын тир пәйда була. Иҗаттагы иң караңгы көннәрем – шушы спектакльне әзерләү чорында. «Бу җиңелүгә кем-нәрсә сәбәпче соң?» – дигәндә, иң әүвәл режиссерның татар тамашачысы белән санлашырга теләмәве.

Аннары... Әсәрне дөрес кыскартмавы аркасында эчтәлеге нык зәгыйфьләнде. Цейтлин үз кыскартуларында татар милләтенең уй-теләкләрен, хыял-омтылышларын, тарихтагы язмышын, урынын бөтенләй исәпкә алмады.

Ә бит татар дөньяны, тормыш агышын үзенчә аңлый, үзенчә кире кага, үзенчә ярата. Гомуми кешелек алдында торган проблемалар күп, әмма һәр милли театр аны үз тамашачылары аңлаганча хәл итәргә омтыла. Режиссердан шул милләт проблемаларын калкуырак күрсәтү көтелә. Сюжетны бозу яки юк итү җиңел ул. Аның астына яшерелгәнне табу – иҗаттагы иң мөһим эш.

Бу трагедиянең төп геройлары – җиңүче дәүләт вәкиле Антонио белән Мисыр дәүләте ханбикәсе Клеопатра.

Тел яшерәсе юк безнең милләтебез дә буйсындырылган хәлдә яши бит. Шуңа күрә гасырлар буе азатлык сорый, үзе булып сакланырга тырыша, тигез булып яшик, ди, милләт хокукларын яклауны сорый.

Аптырагач, Цейтлинга: «Без күрергә теләгән умыртка сөяге кайда?» – дип

мөрәҗәгать иткәч, ул безгә: «Әйдә, сәхнә буйлап йөрегез дә, репликаларны әйтегез, ә мин яраганын калдырырмын, артыгын сызармын, тирәнгә кермәгез», – диде.

Нәтиҗәдә, Шекспир әсәренең үзендә булган фәлсәфәсе татар тамашачысына хезмәт итми сызылды. Тамашачы спектакльне ташлап чыгып китә башлады. Җыенысы 3 кенә мәртәбә уйналды... Футболда Пеленең туп тибүдә үзенә генә хас ысулы булган кебек, синең, ягъни Ринатның роль йозакларын ачудагы нинди алымнары актер осталыгы дәреслегенә кертергә лаек? Үзләрен театр белгече дип йөрүче кайберәүләр «Өч аршын җир» һәм «Кол Гали» спектакльләренә карата «болар трагедия түгел – мелодрама гына» – дип язганда, үзебезнең «милли тәнкыйть докторларыбызның» кайсысы, артист Ринатның «товарына» таянып, «бу артист чын трагик роль тудырган», дип яза алды? Хәер, әйтсеннәр дә, ди, язсыннар да, ди. Әмма дәлилләү өчен актерның башкару алымнарын, «ачкычын» – иҗат «паролен» күрсәтеп анализлау сорала бит. Бармы бездә шундый диагноз куярлык «докторлар»? Булса, кайда һәм ничек күрсәттеләр алар «докторлыкларын»?

– Әхтәм, син миңа «кыргаякның алгы дүрт аягы гына атлаганда арттагы сигезе нишли?» дигән кебегрәк «мудреный» сорау бирәсең, ягъни, «мудрствуешь лукаво». Сәнгать мондый тональностьне кабул итми. Җиргә төш һәм минем иҗатымда нәрсә артык, нәрсә җитми – ачык итеп әйт. Безнең тәнкыйть өлкәсендә ихласлык һәм гаделек юк. Уң колакны уң кул белән кашымыйча, сул кулны эшкә җикмәк булабыз. Алай булмый.

Тамашачы «кыргаякның» аякларына карамый – кая таба баруына карый...

– Артистның яратып уйнаган рольләре күп була. Яратмый уйнаганнары гына булмыйдыр. «Сүнгән йолдызлар»ны искә алуыңда, Әхтәм, мин ниндидер ирония шаукымын сиздем. Бөкре мәхдүм Надир – аеруча яратып уйнаган ролем. Уйнаган саен тамашачымның да тетрәнүен күрү миңа яшәү дәрте өсти. Надирның гәүдәсе гарип, ләкин акылы зирәк, йөрәге кайнар, хисләре саф, теләкләре изге. Спектакльдә мәхдүм үзен-үзе үтерә. Ләкин бу үлем дөньядагы гаделсезлеккә чыдый алмыйча үлү булып яңгырый. Трагедия бит бу.

Шундый кешенең язмышын дөнья классикасы трагедияләре югарылыгында күрсәтү безнең театрыбызга мәдхия түгелме?

Бу сөйләшү-әңгәмәдә без – щепкинчы картлар, театрның күп эшләренә тукталып, үз бәһабезне бирдек. Аларны кыскача гына язганда да үзе бер калын китап булыр иде.

Әмма безнең максат элек язылган китапны тикшерү дә, данлыклы театрның спектакльләренә ревизия ясау да түгел.

80 яшен тутырган Ринатның 60 еллык иҗатына бәһане милләт үзе биреп, театрыбыз аның исемен дөнья масштабында яңгыратты. Без – тамашачылар һәм сабакташлары, аның белән бер чорда яшәвебез һәм театр сәнгатенә хезмәт итүебез белән горурланып, аның иҗат серләрен ачкан «пароль»не табуны игълан итәбез. Алар бик күп икән: һәр спектакльнең, һәр рольнең үз «пароле». Шуларны берләштергән гомуми бер «пароле» бар: ул «Ринат» дип атала. Шул аның һәр иҗади эшендә ачкыч-пароль.

Без аның каллиграфиясе, почеркы – язуы матурлыгына соклануыбызны белдердек. Ринатның матур, тигез хәрефләрдән торган почеркы аның иҗат иткән образларында да чагылыш таба. Аны Ринат стиле, Ринат почеркы, диләр. Бу бик зур бәһа.

Тормышта ул һәркемгә миһербанлы, беркемгә дә өстән карамас, тәкәбберлекне белмәс, әмма үзенә сүз тидермәс, шәхесен түбәнәйтмәс тигез холыклы кеше. Язуы гына түгел, яшәүдә дә Ринат кебек яшисе килә дә, әмма һәркем – үз холкының колы...

Сабакташым-дустым турында әйтәсе сүзләремнең иге-чиге булмаса да, алар журнал рамкаларына гына сыймагач, ул фикерләрем Ринат белән бергәләп иҗат ителәчәк

8 серияле «Ташкыннар» фильмын (Рөстәм Нәбиуллин эше) төшерү вакытында алынган фото. 1977 елның сентябре

фильм-спектакльләрдә, иншаллаһ, әйтелер, дип өметләнәм. Өмет безнең яшәү терәге бит!

Бу язмамны күңелемдә яңгыраган шигъри юллар белән тәмамлыйсым килә:

«Бер-берсеннән таулар биек була,
Исемнәре төрле булганлыктан,
Җисемнәре шуңа ишарә.
Кайберсенең түбәсендә Эдельвейс үссә,
Кайберсендә яши бозлы шишарә.
Кайбер тауга менеп мактаналар,
Кайсын күргәч, сокланудан,
«Тауга карап, тау булып булмас», – диләр.

Шулай... Таулар тигез булмагандай, артистлар да (кешеләр дә) тигез түгелләр».

Ринат әфәнде! Күп санлы тамашачыларың шулай тәкрарлыйлар: «Карлы таудай ап-ак булган башың – бәрәкалла!» – диеп. Кемдер әйтер: «Иртә картаюдан, күп уйнаудан», – дияр, сөеп. Без әйтәбез күмәк тавыш белән:

«Һич борчылма, әзи, таулар биек булса гына,
Аның түбәсенә кар ята».

Тамашачыларыңны тыңлап шигырь язарга омтылучы сабакташың
Әхтәм ЗАРИПОВ.
Язылды – 2018 елның 1 гыйнварында. Ринатның туган көнендә.

Фотолар автор архивыннан алынды. ■

КИҢ ТАРМАКЛЫ МИЛЛИ ИҖАТ

Розалина Шаһиева



Хәмит Латыйфның агач уймалары, ягъни агачны уеп ясаган сәнгате – меңьеллыклар буенча безне әйләндереп алган, тибрәтеп йоклаткан, йә кояшлы йорт, йә алтын бишек булып назлаган, йә тәгәрмәчле арба сыйфатында, йә уенчык ат булып дөнья гиздергән; яфраклары, бизәкләре, хуш исләре, сайрар кошларының чыңгылдавы белән йөрәкләрне җилкендергән урман

«Сак-Сок». Панно. 2017 ел

«Яз». Тәлинкә. 2015 ел

«Безнең көй». Тәлинкә. 2005 ел

белән тоташу хикмәте. Бу сәнгать – үзе бер зур тармак! Алтынсу йомшак каен такталарга махсус пычак яисә өтерге ярдәмендә уеп бизәк йөгертү, күңелләреңне биләп торган уйлар ташкынын сынландыру – ата-бабалардан калган, авылларда әле дә очраштыргалый торган хикмәтле һөнәр – хикмәтле мирас! Балачагыннан эшче-корымчылар, йорт салучылар, агач осталары арасында кайнашкан, җәй буе әтисе белән ат җигеп, утын агачы ташыган, бүрәнә ярган Хәмит бик иртә агач тану, агач бизәү стихиясенә кереп киткән. Ләкин биредә дә ул традицияләрне кабатлаучы һөнәр иясе – уемчы булып кына калмаган: күләмле сюжетларга, тематик серияләргә, фәлсәфи уйланулар дәрәҗәсенә күтәрелгән оста, яңа технологияләр тудыручы, үз алымнарын булдыручы рәссам булып формалашкан. Әле 1972 елда, мәшһүр агач уенчыклар төбәге – Мәскәү өлкәсенең Загорск районы Богородское авылында укыган чагында ук, Хәмит, биредә бары тик стандартка кергән темаларны кабатлый торган башкаручылар гына кирәклеген аңлап, укуын ташлаган һәм Уфага, сәнгать училищесына – махсус агач сырлап бизәү бүлегенә укырга кергән (1974-1978) еллар). Агачны нәкышләү һәм аңа чокып-уеп бизәк төшерү ысулларын анда җентекләп өйрәнгән. Инде беренче эшләре үк – «Шүрәле» панносы, Яр Чаллы шәһәрендәге балалар бакчасы, төрле җәмәгать биналары өчен башкарылган декоратив паннолары, ишекләр татар читеген каю техникасын хәтерләткән нечкә сырлы юлларның үзсүзле көйле хәрәкәтеннән гыйбарәт. Аларның максаты – «үрмәкүч оясы»н хәтерләткән сызым һавалы җанлы тирәлек тудыру...

Агач бизәү өлкәсендә барган иҗади эшне Туймазы фарфор заводында эшләү этабы, чын мәгънәсендә милли сәнгать – нәкыш, гүзәл пастель техникасында башкарылган әсәрләргә чыгу чоры (1990 нчы еллар) туктатып тора кебек. Ләкин бу өлкәләрдә эшләү авторның композицион кыюлыгын арттыра; агач бизәү энергиясен абстракт геометрик кабатлаулар, йорт экстерьерын: капка, тәрәзә, өй кирәк-яракларын бизәү стиленнән мөстәкыйль мохит, образ тудыру стихиясенә алып кереп китә. Авторны сынчыга, нәккашкә әйләндерә.

2000-2002 елларда Хәмит Латыйф «Туран» милли-мәдәни фондында эшли. Бу чорда кыска гына вакыт эчендә гаҗәп үзгә, функциональ яктан күптөрле ихтыяҗларга туры килгән күләмле «уйма» серия пәйда була. Бу – агачтан ясалган сурәтле яссы тәлинкәләр, зур-зур декоратив сандыклар, ипи савытлары, интерьер җисемнәре, ярма

«Абый белән». Панно. 1977 ел

«Шүрәле». Агач. 1975 ел

салыр өчен көпшәләр, декоратив паннолар. Аларның йөрәге – тыгыз тутырылган гөлъяфрак, чәчәк орнаменты, аларны «кочып», тирәләп алган кеше сурәте: «Кубыз көе», «Урман көе», «Тукай», «Сакчы кошлар», «Матур кыз», «Гармунчы»... Шәймәрдан чорында* (2002-2003) бу җанлы катлам – кошлар, күбәләкләр, хайванәт – кояш-йолдыз, агар сулар, «тереклек агачы» сыман космогоник образлар белән керешеп китә... Останың агачны чокып, кисеп кенә, бизәкне өске якты яссылык белән астагы батынкы шәүләләрнең берләшүеннән туган тирәлектән гайре, өтергене тибрәтеп, биетеп, фактуралы бай мохит кабызу ысулы туып чыга.

2006 елларда Хәмит Латыйф яңа форма – юнып эшләгән түгәрәк озын вазалар – бал, май, кымыз савытлары, май төшерү гөбеләре сыман оригиналь шәкелләргә мөрәҗәгать итә. Аларны татар әкиятләре, мифологик образлар белән бизи, үзенең балачак хатирәләрен яңарта: самимилек һәм тәвәккәллек белән эшләнгән киң көпшәләр тышында нурлы кошлар, әкәм-төкәм, ак еланнар, юлбарыслар, шүрәлеләр, түбәтәйле батырлар, курайчылар. Урман җыры... Юка гына катлам органик буяу астында – әллә нинди шигъри хикмәт, фантастик манзаралар һәм әйберләрнең көнкүрештәге вазгыятенә тиң әверелешләр, үзгәрешләр могҗизасы. Тикмәгә генә алар бер мизгел эчендә Изге Болгар шәһәренең гөмбәзле төрбәләр панорамасына әверелмиләр! Бу чордагы тәлинкә-панноларда да – монументаль эрелек, саран серле сырлар, йөрәкне чымырдатырлык драматик чалымнар: «Юлбарыс», «Болын кошы», «Колын» һ.б. Мондагы алымнарның ачыклыгы – җәяле ук кадалган кебек тәгаен эзләр, төртке-сызымнар – хис тирәнлеген ача, образларның мәңгелегенә ишарә итә.

Нәкъ бу чорда Хәмит шулай ук яссы сувенир скульптуралар (15-20 см биеклектә)

* Шәймәрдән чоры – рәссамның Саба районының Шәмәрдән бистәсендә эшләгән еллары.

«Килен сандыгы». 2001 ел

«Болгар урманында». Капкачлы агач вазалар

Ике ягы да уелып, уртада пыяла калдырып эшләнгән ишек

һәм Африка битлекләре тәэсирендә туган «Битлекләр» сериясен иҗат итә. Болар агач фактураның мөмкинлекләрен, аның магик-мәҗүси тәэсир көчен ача торган иҗади эксперимент, бу традицион системага да авангард шаукымын кертеп карау, агачның, материя буларак, универсальлеген исбатлау омтылышы булып кабул ителә. Күп кенә сувенирлар – кулай һәм, чын мәгънәсендә, бу җирнең күркәм традицияләрен ачучы истәлек булып кабул ителәләр: «Малай белән Шүрәле», «Бабай», «Кош тоткан кыз», төрек һәйкәлләрендәге кебек ананың йөрәге янында уелган бала – «Бала-ана», «Фәрештә» һ.б.

Хәмитнең иҗат кырлары бер-бере белән табигый берләшә, бер-беренә тәрәккыят дулкыны өсти, рәссамчылыгы «уймачылыгына», ә соңгысы нәкышенә, пастель һәм графикасына тәэсир итә, гомум камилләшүгә этәрә. Агачта тапкан кискен, үзсүзле, кулының энергиясен саклаучы, тормышның һөҗүменә бирешмәүче санаулы сызымнары, шулай ук аның пастель эшләренә дә кереп китә; «киртләч» агачлар, чатнаган куаклар арасында сурәтләнгән «матур авыллар», яшь-җилкенчәк, карт-коры образларына тәгаенлек, хакыйкать хисен өсти, шактый экзотик, яңача «үз тасвирына» ышаныч тудыра...

Мөстәкыйль бер сәнагъ дөнья, иҗади бербөтен этнографик нигездә һәм рәссам дулкынлануы тәэсирендә туган «Агач уймалар» – үзе бер музей, авторның мәҗүси саф рухы, аның табигатьне тоя белүе, ихтыяр көченең күләмлелеге, иҗади сизгерлеге билгесе. Аларда – гүзәл дөнья кору сәләте; материяне буйсындыра белү, каты җисемнәрне үзләштерүнең кискен энергиясе. Алар рәссамның милли гаярьлеге, зирәклеге, татар дөньясының эшлекле вә гайрәтле иҗатчысы, гаҗәеп осталык иясе булуы турында сөйли. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

Җырлар артыннан илләр гизеп

(Фольклорчы көндәлегеннән)

Эльмира Каюмова

Эльмира Каюмова. Фәнни сәяхәткә чыккач. 1990 еллар башы

*Быел фәнни сәяхәтләргә чыга башлаганыма нәкъ **30 ел була**. Узган җәй экспедициясе Татарстан Республикасының Буа районына юнәлтелгән иде. 14 авылда эзләнүләр алып бардым. Биредә кайбер авылларның исемнәре дә үзенчәлекле – төрле район үзәкләре атамаларын йөртә: Әлки, Кайбыч, Норлат. Кайбыч авылында, мәсәлән, танылган композитор һәм җырчы Фирзәр Мортазин яшәп, иҗат итә икән. Бу хәбәрне ишетүгә, шундук хатирәләргә чумдым, чөнки тәүге экспедициям Буа районында узды...*

1988 ел. Миңа 19 яшь, Казан дәүләт консерваториясенең теория һәм композиция факультетында укыйм. Беренче курс ахырында безне, фольклор практикасына, дип, Буа районының Түбән Наратбаш авылына җибәрделәр. Борынгы халык иҗаты үрнәкләре белән бергә заманча җырларны да язып йөрдек. Өлкәннәрдә «Кайдадыр шунда, авыл читендә» бәете «Кирпичики» көе белән таралган. Яшьләр арасында Ф.Мортазин әсәрләре аеруча популяр («Бер генә минутка», «Хуш инде» һ.б.), алар үзләренең якташы белән бик горурланалар иде. Ул чакта Ф.Мортазин танылa гына башлаган иде әле. Шулай ук «Мин сине шундый сагындым» (Л.Батыр-Болгари музыкасы), «Эх, кара каш, кара күз» (шаян җыр) яратылып башкарылганы һаман дә истә.

Әлеге сәяхәт күңелемдә тирән эз калдырып, язмышымда хәлиткеч роль уйнады, киләчәктә профессиональ юнәлешемне сайларга этәргеч бирде. Монда гомумән татар музыка дөньясы белән якыннан танышу, аның тәмен тою булгандыр. Балачактан салынган орлыклар калкып, үсеп чыктылар.

Балачак дигәндә, бераз аңлатма бирергә кирәктер. Миннән: «Ничек инде син шәһәр баласы, авыл белән кызыксынып киттең?» дип еш сорыйлар. Асфальтта чын фольклор барлыкка килми, дигән караш бар. Әле минем туган телебездә әйбәт сөйләшкәнгә гаҗәпләнеп китәләр (безнең чорда минем тиңдәшләр арасында бу – гадәти булмаган күренеш иде). Әйе, мин Казанда туып үстем, әмма тамырларым авылдан. Җәйге каникулларны Казан артында әбиләрем янында үткәреп, туйлар, кичке уеннар, Сабантуйларны күреп, җыр-көйләрен ишетеп, авыл моңнарын сеңдердем. Авылыбыз тирәсендә иске язулы кабер ташларын күзәтеп, хәйран калдым. Бигрәк тә «Изгеләр зираты»нда урнашкан эпиграфик һәйкәлнең алты канатлы йолдыз сурәтенә игътибар итеп, кызыксынып киттем («Безнең мирас» укучыларына бу таш билгеле, авылның исеме дә сер түгел). Каян килгән бу?! Нәрсәне аңлата? Минем бабаларым кем булган? Кем соң без – татарлар? Бу сорауларга җавап табасым килгән иде.

Китап укырга бик ярата идем. Шулай бер көнне Фенимор Куперның индеецлар турындагы әсәрләрен укып утырам. Кояшлы җәйге иртә. Тәрәзәгә карап, уйланам. Әтәч кычкыра, эт өрә... Янәшәдә әбием мичтә төче коймаклар, дучмаклар пешереп мәш килә. Укып утыргач: «Карале, индеецларның холкы, дөньяга карашлары татарларга якын ич», – дигән фикер башыма килә. Бу фикернең нигезле булуын мин соңрак белдем (ике халык арасында уртаклык галимнәр тарафыннан расланды, ә мин аны үсмер чагында күңелем белән генә сиздем).

Өстәп шуны да әйтәсем килә, ирем авыл кешесе – тумышы белән Кайбыч ягыннан. Шуңа күрә дә Тау ягы традицияләре миңа якын-кадерле, аларны күптәннән белеп торам.

Бүрене аяклар ашата диләр. Фольклор җәүһәрләрен җыючының да нәкъ шулай. Гомеребезнең зур өлеше юлда үтә. Берничә дистә ел дәвамында нинди генә почмакларда булырга туры килмәде. Татарстанның районнарын санап китсәң: Арча, Актаныш, Алексеевск, Апас, Балтач, Зәй, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим, Питрәч, Саба, Теләче, Тәтеш, Яшел Үзән һ.б. Бүтән төбәкләрне исәпкә алсаң: Киров, Оренбург, Түбән Новгород, Чиләбе өлкәләре; Башкортстан, Мари Иле, Удмуртия Республикалары. Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, Урал татарлары, нократ татарлары һ.б. – 200 ләп авыл тикшерелде. Ел саен исемлеккә уртача 10 авыл өстәлә.

Меңләгән кеше белән аралашу бәхете тиде. Мисал өчен, бер Нижгар якларына оештырылан экспедиция вакытында гына да 80нән артык кешедән мәгълүмат тупланды. Чынлап та, бүлмәдә, китапханәдә утырып кына халык мәдәниятен аңлап булмый. Халык тормышын эчтән үк белмичә, аның яшәешен, уй-кичерешләрен тоймыйча, һавасын суламыйча, суларын эчмичә, шул төбәктә туган иҗат җимешләренең асылына дә төшенә алмыйсың! Мин моны ялтыравыклы сүз өчен түгел, үз тәҗрибәмнән чыгып

«Изгеләр зираты»нда кабер ташы.
1992 ел

Борынгы кабер ташы.
2011 ел

әйтәм. Нижгар мишәрләре фольклорында «Төймә такмаклары» (яки «Төймә бәетләре») дигән гаять үзенчәлекле үрнәкләр бар. Алданрак мин алар турында күренекле музыка белгечебез Мәхмүт Нигъмәтҗанов хезмәтләрендә укып, бер төрле нәтиҗәгә килдем. Ләкин 2010 елда «Төймә такмаклар»ын үзем язып алгач, чын мәгънәсенә төшенгәч, фикерем үзгәрде. Кәгазьдә ул – бер нәрсә, ә табигый яшәешендә күзәтү – икенче нәрсә. Юкка гына «кыр фольклористикасы» дип аталмый!

Музыкаль мирасны төрле оешмалар тарафыннан оештырылган һәм шәхси экспедицияләр вакытында барларга туры килде. Студент чагымда – Казан консерваториясе, аннары – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (башта ул Тел, әдәбият һәм тарих институты исемен йөртте), соңгы елларны – Татарстанның Мәдәният министрлыгы каршындагы Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең вәкилләре белән бергә чыккан идем. Төркемнәр составында укытучым Наилә Әлмиева, тел галиме Николай Максимов, композитор Мәсһүдә Шәмсетдинова һ.б. мәшһүр шәхесләребез бар иде. Хөкүмәттән финанслау өзелгән чорларда, туганнарга мөрәҗәгать итеп, алар ярдәме белән материалны җыю эшен туктатмадым. Моннан тыш, кайда туры килә (фестивальдә, конференциядә, мәҗлестә) – бөтен җирдә тупларга тырышам. Аерым башкаручылар белән дуслашып китәбез. Телефоннан шалтыратышабыз, кемдер җыр дәфтәрләрен җибәрә.

Нурия Закирова (1934 елгы) һәм Эльмира Каюмова. Татарстан Республикасы, Буа районы, Кайбыч авылы. 2017 ел

Читтән караганда барысы да ал да гөл шикелле. Әгәр дә бу ханым юлларда йөрергә бик ярата дип уйласагыз, нык ялгышасыз. Парадоксальлеге шунда ки, өйдән чыгып китүне, юл газапларын зур авырлык белән кичерәм. Нишлисең бит, һөнәрең озын сәфәрләр, өйрәнелмәгән җирләр белән бәйле булгач, һәрвакыт үз-үзеңне җиңәсең инде! Илләр гизеп, төрле куркыныч (хәвефле) хәлләргә дучар буласың. Яшьлектә берничә кат (Мөслим, Зәй якларында) урлап караганнар – кыз урлау, Кавказда гына түгел, бездә дә таралган булган, әмма бу гадәт борынгы булса да, мине бер дә сөендермәде. Берзаман Урал таулары янына юл алгач, илебездә кискен үзгәреш – ГКЧП барлыкка килде. Киләчәк куркыта, халыкта дулкынлану, ә мин шундый ышанычсыз мизгелдә музыкаль фольклор җыеп йөрим. Экспедицияләргә ялгыз да, кечкенә баланы җитәкләп тә чыгып китүләрем булгалады.

Ни өчен алай азапланырга, дип сорыйсызмы? Нәрсәгә кирәк инде бу җырлар, көйләр? Хәзер әллә ни ачышлар ясап булмыйдыр. Кайберәүләр музыканың вазыйфасы фәкать күңел ачудан гыйбарәт дип белә. Әмма халык музыкасы – тарихның яңгырый торган елъязмасы. Көйләрне тел белән тиңләргә була, тик анда мәгънәләр аһәң, тавыш, ритмнар аша бирелә. Көйләребездә милләтнең үткәне, бүгенгесе, башка халыклар белән булган мәдәни бәйләнешләр чагылыш таба. Әлеге караш уен җырлары, такмакларга да кагыла. Бүгенге көндә эшебезнең максаты сирәк очрый торган, билгесез мисалларны эзләп табу белән генә чикләнми. Әз булса да, тамчылап җыйсаң – якутҗәүһәрләр табыла, фәнни ачышлар да ясала. Ләкин өйрәнү кырыбыз күпкә киңрәк: үз эченә халык төшенчәләре системасын, башкару үзенчәлекләрен, этнографик якларын (көнкүрештә тулы канлы яшәеш күренешләрен) һ.б. аспектларын сыйдыра. Җыеп әйткәндә, этномузыка белгеченең кызыксыну үзәге – халык музыка мәдәниятен тулысынча вә тәфсилләп өйрәнү.

Кызыклы һәм искиткеч кыйммәтле байлык тупланды. Аны тиешле дәрәҗәдә эшкәртер өчен тагын өч кеше гомере кирәктер. Сандыгымда бикләп тотасым килми. Журнал битләрендә үземнең тәэсирләр, табышларым белән уртаклашасым килә. Алга таба язмаларыбызда экспедиция көндәлегеннән өзекләр, фольклор үрнәкләре, онытылмаслык очрашулар турында материаллар тәкъдим итәрбез.

Дәвамы бар

Фотолар Э.Каюмова архивыннан алынды. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ТИМЕРЧЕЛЕК – Тимерче алачыгы – металларны кыздырып чүкү юлы белән эшкәртү өчен билгеләнгән остаханә. Русча – *кузница*. Татар авылларында гадәттә су буенда урнашкан тимерчелек таштан яки саманнан төзелеп, ут чыгу куркынычын киметү өчен, яссы түбәсенә туфрак та җәелгән тәбәнәгрәк кенә бинадан гыйбарәт иде. Тимерчелекнең уртасында җиргә казып утыртылган коршау суккан юан бүкәнгә сандал беркетелгән. Янәшәдә генә тимерче миче һәм учакка һава өрдерү өчен хезмәт итә торган күрүк. Тимерче кораллары – ике куллап тота торган

Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Безнең мирас №2 февраль 2018

Тимерчелектә эш кызу

зур, авыр чүкеч (*балда* яки *дөлдә*, русча – *молот*, *кувалда*), вак чүкечләр, кыпсуырлар (келәшчәләр), үрдәкборыннар, каргаборыннар, кискечләр, тишкечләр, боргычлар, игәү-рашпильләр, эреле-ваклы гайка ачкычлары, винт сыры ясу кораллары, кадак станнары һ.б.лар шулай ук кул астында гына. Зур кыскыч яки эскәнҗә-тиски кечкенә тәрәзә буендарак. Тимер пычкысы шунда имән чөйдә эленеп тора. Кулдан әйләндерелә торган бораулау станы – монысы инде «катлаулы техника»... Бер почмакта капчык-капчык агач күмере, кызган эшләнмәләрне суыту яки сугару-чыныктыру өчен су салынган кисмәк әче-төче исләр чыгарып тора. Менә бу әрҗәдә ниндидер каралҗым ком, аны кып-кызыл булып кызган коршау очларын бер-берсенә ябыштыру өчен сибәләр. Квадрат тәрәзә төбендә шешәсе белән усал кислота, банкасы белән зәһәр нашатырь кебек «химия». Шөрепләрне чистарту-юу һәм майлау өчен керосин, автол-солидол кебек нәрсәләр дә үз урыннарын тапкан...

Тимерчелек алдында юан баганалардан һәм аркылы борыслардан торган ат дагалау станы яки станнары булмыйча калмый. Гадәттә стан буш тора, бала-чага гына аның түшлек каешын атынгыч итеп файдалана. Тәгәрмәч коршаулау җайланмасы да шунда гына. Бер читтәрәк тимер-томыр яныклары, шлак өеме.

Тимерчелектә *чар, кайрак ташы, наждак* булмыйча калмый.

Тимерчеләр гадәттә икәү – баш оста һәм аның кулдашы (молотобоец) була иде. Ялгыз гына эшләгән тимерчене руслар, мәсәлән, *кулсыз тимерче* дип атаганнар («безрукий»). Бер ярдәмчесе булган тимерчене – *сыңар куллы* («однорукий»), ә ике кулдашы булганын *ике куллы* («двурукий») дигәннәр. Тимерче, тәҗрибәсенә таянып, кайсы урынга, нинди юнәлештә һәм ничә тапкыр кувалда белән сугарга икәнен үзенең кечкенәрәк чүкече белән суккалап күрсәтмә биргән.

Эрегән самавыр яки тишек комганын йә казанын күтәреп яисә башка вак-төяк йомышлары белән килгән кешеләр күрүк басып ярдәм итәләр, бу эшне малай-шалай да бик теләп башкара. Серле эш ул – тимер эше, гыйлем ул, шуңадыр, балаларга «ут эше» балта эшеннән кызыклырак тоела.

Элегрәк Рәсәйдә татар авылларында астыртын гына корал-мазар ясап ятмасыннар өчен тимерчелек эше тыелган булганга, татарлардан сәнәгати эшләнмәләр ясый белүче осталар юк чамасында иде. Ләкин ат дагалау осталарына кытлык булмады. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

Бу күркәм йортны, бер стильгә китереп, архитектор Карл Людвигович Мюфке 1906 елда төзетеп бетерә. Ул үзе 1868 елда Воронежда провизор (аптекада дарулар сатучы) гаиләсендә туып үсә. Петербург сәнгать академиясендә укып чыгып, архитектор-рәссам дәрәҗәсен ала. Австрия, Италия, Франция кебек илләргә иҗади сәфәргә чыгып, классик архитектура үрнәкләрен өйрәнә. Чит илдән кайткач, ул Казан сәнгать мәктәбенең директоры була һәм архитектура бүлеген җитәкли. Бер үк вакытта ул 1901-1909 елларда Казан университеты архитекторы вазыйфаларын да башкара.

Милли китапханә бинасы ике катлы, кушылып бетмәгән каре формасында, Казанның үзәгендә әкияти бер затлы сарай кебек әллә каян күренеп, үзенә җәлеп итеп тора. Ераклардан килгән сәяхәтчеләр, кунаклар бу бина янынннан битараф кына үтеп китә алмыйлар. Туктыйлар, карыйлар, сокланалар, рәсемгә төшерәләр, сорашалар. Ташка

*Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

күңел нуры, җан өреп ясалган бизәкле диварлары, түгәрәк эркер белән тәмамланган «почмагы» челтәр балконлы, югарыга, күккә омтылган көмешсу гөмбәзле, бөтен рәвеше җиңеллек бөркеп торган бинаның рамнар белән бүлгәләнмәгән зур-зур тәрәзәләре эчкә, моңарчы күрелмәгән дөньяга дәшеп тора.

Йортның эчке бизәлеше дә шулай ук бай һәм үзенчәлекле, монда төрле архитектура стильләре чагылыш тапкан. Иң баштан, саллы ишекне ачып кергәч, без серле шәрык хәятенә эләгәбез. «Шинуазри» рухында ясалган тантаналы баскыч сине кояш чыгышы илләренең шанлы хакиме хозурына алып керер шикелле: диварларда, ишекләрдә, түшәмдә, баскыч култыксасын тотып торган челтәрләрдә коеп, уеп эшләнгән, сөрмәле алтын йөгертелгән лирик аждаһа силуэтлары поскан. Диварларда кыйммәтле ефәккә чигелгән рәвештә борынгы Кытай, япон нәкыш сәнгатенең үрнәкләре бамбукка охшатылган рамнар белән каймаланган. Диварда, идәндә аң-зиһенне уяту догасы кебек иероглифлар шәйләнә.

Тантаналы баскычка чыгучы төрле формадагы ишек тоткалары – чын сәнгать әсәрләре: бронзадан ясалган кечкенә аждаһа фигураларын күз алдына китерә. Тәрәзәләре төсле француз пыяласыннан витраж итеп эшләнгән, анда җәннәт үсемлекләре, үрмә гөлләр, асыл кошлар сурәте көн нуры аша чагыла. Өлгеләрдәге «Ш.Шампиньоль, Париж» дигән француз телендәге язулар бүгенге көнгәчә сакланган. Төп баскычның мәрмәр идәненә алтын җепләр батырып, японнарның сакурасы (чәчәк аткан чия куаклары) ясалган.

Тантаналар залы (хәзерге көндә уку залы) ампир стилендә, аерата хушлык биреп, хәрби атрибутлар кулланып бизәлгән. Түшәмдә катырып эшләнгән орнаментлар калкан, кылыч, байрак, канатлы арыслан һәм ат, очарга җыенган бөркет сурәтләре белән аралаштырып бирелгән. Латин вензеле N куелу йорт хуҗасының Наполеонга мөнәсәбәте

Безнең мирас №2 февраль 2018

хакында искәртеп тора. Бу залның биек саллы ишек башларына куелган скульптуралар, чын сәнгать әсәрләре, кабарынкы итеп эшләнгән бөркет, Горгона дип аталучы медуза сыннары беркетелгән.

Затлы йортта иң хикмәтле урын – табигый тау куышына охшаган сталактитлы бүлмә, монда бар да чын мәгарәне искә төшерә. Стеналары чын кабырчыклардан катырып эшләнгән, эре, тигезсез итеп стенага ябыштырылган уентыкларга бүлгәләнгән, ул плитәләр арасындагы ярыклардан үрмә гөлләр тишелеп чыгып чәчәк аткан, түшәменнән баш түбәсендә сталактитлар асылынып торган бу мәгарәнең аквариумы, ташлары, сәер балык авызыннан су сиптерүче фонтаны хәзергәчә исән сакланган. Мәгарәнең урам ягы зур-зур тәрәзәләрдән гыйбарәт, алар аша яктылык агылып керә.

Мавритан стилендә эшләнгән бүлмәнең эркерында түгәрәк мәчет манарасына охшаган урыны да бар. (Мавритан стиле XI-XV гасырларда Төньяк Африка һәм Көньяк Испаниядә киң таралган төзелеш сәнгатендәге шартлы исем.) Гадәттә, манараның эче очлаеп тәмамлана, ат дагасына охшаган ярымтүгәрәк өлеше телеп-телеп киселеп эшләнә. Мондый стильгә аркалар, агачка уелган бизәкләр, үсемлек үремнәре, геометрик фигуралар һәм хәрефләрдән чигеп ясалган орнаментлар хас. Мавритан залының үзенчәлеге шунда: мәһабәт ишекләргә алтынланган гарәп хәрефләре белән, искиткеч матур төгәллектә үреп, шамаилгә охшатып, исламның төп нигезен тәшкил иткән изге сүзләр язылган: «Аллаһтан башка Иляһ юк...» Ушковлар дәверендә мавритан рухы аңкып торган стеналарына кылычтыр, хәнҗәрдер, ятагандыр тезеп эленгән бу зал тәмәке тарту урыны булган. Бүген монда күргәзмәләр, мәдәни чаралар үткәрелә.

Әүвәл ашханә булган зал урта гасырларның алман замокларындагы кебек, эңгер караңгылыгы саркытып торган готика стилендә, диварлары морилка сеңдерелгән кара имән белән тышланган. Элек монда фарфор-фаянс коллекциясе куелган булган. Түшәме кессоннарга бүленгән, зур булмаган оркестр өчен балконы да бар.

Кунак кабул итә торган кечкенә алсу бүлмә исә гаҗәеп купшы зиннәтләнгән: нәфис бизәкләр төшерелгән ачык төстәге ишекләр, виньеткалар, кечкенә амур фигуралары, чәчәкле медальоннар ясалган түшәм һ.б. Яшел төстәге кунак кабул итү бүлмәсендә яшел мәрмәрдән ампир стилендә ясалган, җиз бизәкләр беркетелгән каминнар һәм Венециядән китертелгән көзгеләр сакланып калган. Шундый ук каминның икенче бер төрен (өске өлешсез) хуҗа кабинетында күрергә мөмкин. Аның өстенә бронзадан эшләнелгән борынгы канделябрлар һәм элеккеге хуҗалардан калган, сәнгатьле итеп коелган «Зубр» статуэткасы куелган. Алар хәзергәчә шул ук урында торалар. Бина-

дагы каминнар – җәмгысы җидәү. Кабинет түшәмен бизәүдә дә латинча N вензеле кулланылган.

Йортны бизәүчеләрнең осталыгына хәйран калырлык. Һәр зал, һәр бүлмәнең үз йөзе бар. Сурәтләр, төсләр, стена-түшәм бизәкләре бер дә кабатланмый. Хәтта ике залны тоташтырган ишекләр дә бу яктан кергәндә бер төсле, икенче яктан – шул залга тәңгәл стильдә бөтенләй үзгә бизәкле.

Идән җыелма паркетлар тезеп, беренче катта исә керамик плиткалардан эшләнгән (алар йорт хуҗасының үз заводында коелган). Ишектән кергәндә кайбер плиткага хуҗаның исеме язылган (реклама), ә инде һәр плитканың арт ягына Ушковлар тамгасы куелган.

Хуҗалары алышына-алышына тулы бер дәвер кичергән бу затлы бина, миллионнарча китапларны куенына сыендырып, яңа гасырга кереп бара. Белемле, иҗтиһадлы китапханәчеләр, галимнәр тарафыннан эшчәнлеге фәнни һәм заманча нигездә оештырылган Милли китапханә – бүгенге көндә төп Үзәк, татар китабының Мәккәсе... ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

Байкиев М.Х. Шиһабетдин Мәрҗани. 1926 ел

МИЛЛИ МУЗЕЙДА ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ МИРАСЫ

Ш.Мәрҗанинең урындыклары, бюро-секретеры һәм стена сәгате



Ш.Мәрҗанинең хезмәтләре

Ш.Мәрҗанинең шәхси мөһере. 1865 ел

ТР Милли музее фондында дин галиме, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанинең шәхси әйберләре саклана. Алар, ТР Милли архивы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, КФУның Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсеннән алынган материаллар белән бергә, галимнең тууына 200 ел тулу уңаеннан оештырылган «Милли музейда Шиһабетдин Мәрҗани мирасы» исемле күргәзмәдә тәкъдим ителде.

Фотолар ТР Милли музееннан алынды. ■

Ш.Мәрҗанинең юл сандыгы

КУКМАРА МИРАСЫ

Татарның асыл улы

Ләбиб Лерон

Без алдан сөйләшмәгән идек. Кукмарага баргач кына шылтыраттым. Төштән соң сәгать өчләр тирәсендә аның эш бүлмәсендә очрашырга килештек. Нәкъ шул вакытка килдем. Бүләк итеп бирермен, дип керешли машинамнан берничә данә «Безнең мирас» журналын алдым.

Бүлмәсенә кергәндә кем беләндер телефоннан сөйләшкән чагы иде. Күрештек. Кыяфәте – элек ничек иде, хәзер дә шул килеш – тамчы да үзгәрмәгән. Шамил Михәйдәр улын үзгәреш заманыннан бирле ишетеп белсәм дә, аның белән танышуым 2011 елның көзендә булды. Каләмдәшем Рәдиф Сәгъди белән икәү, Мамадыштан Казанга кайтышлый кереп, аның эш бүлмәсендә шактый вакыт сөйләшеп утырдык. Биш елдан соң, ягъни 2016 елның 10 октябрендә Тинчурин театрында кабат очраштык. Ул «Безнең мирас» журналының 25 еллык юбилеена кунак булып килде.

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин 1954 елның 18 апрелендә Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылында туа. Казан авиация институтында электрон прибор төзүче белгечлеге ала. Кукмара киез итек фабрикасында (хәзер Кукмара киез итек-киез комбинаты) башта – инженер (1981), аннары баш механик булып эшли.1988 елда фабрика коллективы 33 яшьлек Шамил Михәйдәр улын директор итеп сайлый.
2017 елның 3 июлендә вафат була.

Инде менә янә күрештек... Бусы соңгы күрешүебез булыр, дип кем уйлаган. Бик җылы сөйләштек Шамил Михәйдәр улы белән. Дөресрәге, күбесенчә ул сөйләде. Мин ара-тирә сорау гына биргәләдем. Комбинатның үткәне, бүгенге хәл-торышы белән таныштырып алды.

Комбинатның хәзерге хәле турында сөйләгәндә, мин Шамилдән:

– Чималны Казахстаннан кайтартабыз, дидең... Ә бит төрле хәлләр булырга мөмкин, мәсәлән, нииндидер сәбәп аркасында чималны кайтарта алмавыгыз ихтимал. Андый вакытта комбинат эшләвеннән туктап торамы? – дип сорадым.

– Юк, туктамый, – дип җавап кайтарды ул. – Шундый хәлгә калмас өчен, махсус бинада мең тонна (хәтерем ялгышмаса, нәкъ шулай диде) запас чимал тотабыз...

Шамил Агиев,
Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе:

«Кешелекле, акыллы, ышанычлы кеше иде Шамил. Оештыру сәләте көчле иде. Бөтен җиргә өлгерергә, катнашырга, яңалыклар белән танышып барырга тырышты. Казандагы киез итек фабрикасы ябылды, ә Шамил үзләрендәге комбинатны саклап калды. Көнбатышка чыгарга омтылды. Германия, Финляндиягә Кукмара итекләрен кертергә теләде. Канадага хәтле барып җитте».

Бераздан ул өстәлгә Кукмара һәм «Кукмара киез итек-киез комбинаты» тарихын яктырткан өч китапны (аларны яздыртучы, җыентык итеп туплаучы һәм китап итеп бастырып чыгаручы да Шамил Михәйдәр улы булуын мин соңыннан белдем, әлбәттә) янәшә куеп, әле берсен, әле икенчесен, әле өченчесен ачып күрсәтә-күрсәтә, хыял-ниятләре хакында сөйләп алды. Комбинатта музей ачарга исәбе барлыгын әйтте: әзер бина бар, аны рәткә-тәртипкә китерәсе генә калды, диде.

Без гәпләшеп утырган мәлдә бүлмәгә бер яшь кыз керде. Ул аңа карап елмайды да:

– Кызым, барысы да тәртиптәме? – диде. Шулвакыт мин әлеге кызга күз кырые белән генә карап, аның әтисенә охшаганын искәреп алдым һәм, кызы да үзе белән бергә эшли икән, дип уйлап куйдым.

Шуннан соң сүз сөрешебез «Безнең мирас»ка күчте. Үз чиратымда мин дә Шамил Михәйдәр улына бер теләкниятем барлыгын җиткердем:

– Сезнең белән киңәш-табыш итешеп, журналда комбинатка, аның тарихы-

на, гомумән, Кукмарага, шушы төбәккә нисбәтле сәхифә ачарга исәп бар. Сезнең киңәш, фикер-тәкъдимнәр ярдәмендә без бу күркәм эшне шушы елның июль аеннан башлап җибәрер идек, – дидем.

Шамил туган, шатланып, берсүзсез риза булды.

Саубуллашыр алдыннан шкафка урнаштырылган төрле үлчәмдәге матур киез итекләргә күзем төште дә, шуларны кулыма тотып фотога төшәсем килеп китте. Шамил Михәйдәр улы фотограф ролен башкарып алды да:

– Бу бизәк төшерелгән ак киез итекне күргәч, бер кызык хәл исемә төште әле, – диде. – Татарстаннан Парижга ике кеше турист булып барган. Шуннан бик матур киез итек сатып алып кайтканнар. Беркөнне шул киез итекне миңа күрсәтергә алып килде болар. Менә, диләр, чит илдә нинди затлы киез итекләр эшлиләр! Ак итек, шәп итек, чынлап та затлы, матур итек. Итек табанындагы келәймәне караган идек, безнең комбинат итеге булып чыкты.

Рәхәтләнеп көлештек тә, җәйгә таба күрешербез, дип саубуллаштык.

Шушы очрашудан соң күп тә үтмәде, «Безнең мирас»ның июнь санында Кукмараның атаклы байлары – бертуган Комаровлар, Вавиловлар, Родигиннар, Войдиновларга

Мөхәммәт Гатиятуллин,
Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты профессоры, 1990-1999 елларда Кукмара район хакимияте башлыгы:

«Шамил Михәйдәр улы тумыштан инженерлык сыйфатларына ия иде. Без аны демократия дип йөртелгән чорда фабрика директоры итеп сайлап куйдык. Әлбәттә, җиңел вакыт түгел иде. Җитәкче булып эшли башлауга, фабриканы (хәзер комбинат) газ белән эшләү системасына күчерде. Беренчедән, бу Кукмара өчен файдалы булса, икенчедән, итек басу эшен бик җиңеләйтте. Аңа кадәр фабрика ташкүмер ягып эшли һәм Кукмара бистәсе өстенә 600 кг корым чыгара иде.

Үзгәртеп кору заманында Шамил Михәйдәр улы бөтен Россия буйлап йөреп, яңа эш алымнары эзләп табып, комбинатына бик күп үзгәреш кертте, итек басуның авырлыгын күпкә җиңеләйтте».

Н.В. Комаров

һәм аталы-уллы Лебедевларга нисбәтле этрафлы язма басылып чыкты. Шул язма чыккан журналыбызны тиз генә күрсәтеп кайтырмын, дип уйлап, әүвәл Шамил Михәйдәр улына шылтыраткан идем, ул сәфәрдә – Башкортстанда булып чыкты. Сырхаулап торган килеш юлга чыктым әле менә, диде. Атна-ун көннән соң янә шылтыратмакчы идем, өлгермәдем, Кукмарадан кайгылы хәбәр килеп иреште. Бу 2017 елның 4 июль иртәсе иде. Шамил Михәйдәр улын соңгы юлга озату мәрәсименә кайткач, берничә данә журналны Шамилнең кызы Ләләгә тапшырдым...

Узган ел, ягъни 2017 елның декабрь ахырларында Кукмарага махсус барып, Шамил Михәйдәр улының кызы – хәзер инде «Кукмара киез итек-киез комбинаты»ның генераль директоры Ләлә Шамил кызы Шәрипова белән аның эш бүлмәсендә очрашып сөйләшергә туры килде. Әлбәттә, сүзебез, әңгәмәбез күбрәк аның әтисе Шамил әфәнде һәм аның исемен мәңгеләштерүгә кагылышлы мәсьәләләр турында барды. Үзе утыз ел җитәкләгән комбинат бүген Шамил Әхмәтшин исемен йөртергә лаек, дидем мин. Комбинатка нигез салучы бертуган Комаровлар бар бит әле, диде Ләлә Шамил кызы, кыенсынып кына. Комбинат туксанынчы елларда юкка чыгарга да мөмкин иде, Шамил Михәйдәр улы аны саклап калды, яшәтте, Кукмараны бүгенге дөньяга танытуга биниһая өлеш кертте, ул моңа чын мәгънәсендә лаек, дип тәкрарладым мин. Кукмараның бер урамына (әйтик, вафатына тиклем үзе яшәгән урамга) Шамил Әхмәтшин исемен

Рауил Рәхмәтуллин,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты, 2006-2014 елларда Кукмара район хакимияте башлыгы:

«Авыр елларда да авыл җирлегендә Россиягә танылырлык бренд булдыра алуы Шамил Әхмәтшиннең үҗәт булуыннан, куелган бурычны үтәр өчен көчен, сәламәтлеген, вакытын кызганмаудан киләдер. Ул бик абруйлы җитәкче, яхшы, миһербанлы кеше иде.

«Кукмара киез итек-киез комбинаты» җитештергән продукция читилләр өчен дә үрнәк булырлык. Авыр елларда да Шамил аны япмады, чимал табу буенча эшләде, халык белән аралашты. Хәзер Татарстанда сарыгы да калмады бит аның. Чыгымлы булса да, фабрика директоры йонны Казахстаннан, Урта Азиядән кайтарта иде. Районны төзекләндерүгә дә зур өлеш кертте ул. Ятимнәргә, авыр хәлдә калучыларга даими булышуы — аның миһербанлы кеше булуын күрсәтә».

бирү дә бик мәгъкуль эш булыр иде, дип ассызыклап әйттем. Комбинатның үз музеен булдыруны (Шамилнең зур хыялы-теләге!) да сузмаска кирәктер, дидем. Кулдан килгәнчә тырышабыз инде, бу мәсьәләне тиз арада хәл итәрбез, дип ышандырды Ләлә. Сүз уңаеннан мин аңа «Безнең мирас»та Кукмара төбәгенә, комбинатка мөнәсәбәтле сәхифә ачарга җыенуыбыз хакында җиткердем. Әтисе шикелле, ул да безнең бу изге гамәлебезне шундук хуплады.

Кыскасы, хөрмәтле укучым, Аллага тапшырып, синең игътибарга яңа сәхифә – «Кукмара мирасы»н тәкъдим итәбез. ■

Безнең мирас №2 февраль 2018

ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 5 гыйнварда Татарстан Язучылар берлегендә бер төркем каләм әһелләре, аерым алганда, Татарстанның халык язучылары Рабит Батулла, Марсель Галиев, шагыйрь-язучылар Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Ләбиб Лерон, Марат Закир, Фирдәвес Зариф психогенетик Фәнис Нәбиуллин белән очрашты.

● 15 гыйнварда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә атаклы җырчыбыз Әлфия Авзалованың тууына 85 ел тулуга багышланган зур концерт булды.

● Мәскәү Ислам институтында мәшһүребез Шиһабетдин Мәрҗанинең 200 еллыгына нисбәтле чара үтте. Әлеге чарада институтның уку-укыту эшләре буенча проректоры Рәис Измайлов Ш.Мәрҗанинең тормышы һәм эшчәнлеге турында этрафлы чыгыш ясады.

● 16 гыйнварда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә мәшһүр җырчыбыз Әлфия Афзалованың 85 еллыгы уңаеннан Актаныш якташлар җәмгыяте Актаныш районы хакимияте белән берлектә оештырган зур чара узды.

● Мөслим районының Олы Чакмак авылы китапханәсендә татар әдәбияты классигы Фәтхи Бурнашның (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев, 01.01.1898–01.08.1942) тууына 120 ел тулу уңаеннан әдәби кичә узды.

● Әтнә районының Олы Әтнә мәктәбендә күренекле балалар шагыйре Хәкимҗан Халиковның (16.01.1933–12.02.2002) тууына 85 ел тулу уңаеннан «Сабый күңелле шагыйрь» дигән әдәби-музыкаль кичә узды.

Китапханәче Розалия Хәсәнова оештырган әлеге чарада әдипнең энесе Мөхәммәтҗан Халиков һәм аның ике улы катнашты.

● 17 гыйнварда Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Беларусь Республикасы илчелегенең Россиядә һәм Казандагы бүлеге җитәкчесе Олег Исаев белән очрашты. Быел

апрель аенда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән Беларусь Мәдәният министрлыгы Беларусьта Татарстан мәдәнияте көннәре үткәрергә ниятли. Фәрит Мөхәммәтшин бу чара ике яклы мөнәсәбәтләргә эшлекле этәргеч бирер, дигән фикердә.

● 17 гыйнварда татар зыялылары әдәбиятыбыз классигы Аяз Гыйләҗевнең каберен зиярәт кылды.

● 11-17 гыйнварда Казан федераль университетының төбәкара предмет олимпиадалары булып узды. Татар теленә кагылышлы олимпиадада – 130, геологиягә нисбәтлесендә исә 70кә якын укучы катнашты.

● 18 гыйнварда «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Курган өлкәсе татар конгрессы рәисе Марат Юнысов белән әңгәмә үткәрде (әлеге әңгәмне алдагы саннарның берсеннән укый аласыз).

● 19 гыйнварда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры фойесында «Әкияткә чакырабыз» дигән китап бизәлеше күргәзмәсе ачылды. Әлеге күргәзмәдә рәссамнар Фәридә Хасьянова, Алсу Тимергалина, Светлана Ибраһимова һәм Диләрә Нәүрүзованың («Безнең мирас» журналының дизайнеры) эшләре урын алган.

● 20 гыйнварда Чувашиянең Батыр районы Кыр Бикшиге авылында татар халкының мәшһүр классигы, язучы-драматург Фәтхи Бурнашның 120 еллыгына багышлап үткәрелгән зур тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Дамир Гыйсметдинов, тәрҗемәче Фатих Кутлу, «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты. ■

Мирасворд



Җәләлетдин ... (фарсы шагыйре)

«Зәңгәр шәл» драмасында Булатның сөйгәне

Ау кошының башына кидерелә торган калфак (бор.)

«Мөхәммәдия», «Хөсәения»

... Сараи

Шарт теркәгече

Ике көпчәкле арбага җигелеп пассажирлар, йөк ташучы

... Дәүләтшина (башкорт әдибәсе)

Шәйхи Маннур туган авыл

Чирмешән районындагы авыл

Көнчыгыш халыкларында киң таралган ризык

Пуэрто - ...

Үлән сүле

Яхин, Кутуй

Драматург Сәет ...

Гаяз Исхакый пьесасы

Гарәп артикле

Вак итеп туралган салам

Зурайткыч пыяла аша рәсемнәр күеп күрсәтә торган тартма

Шаять

Шамил Маннаповның тәхәллүсе

Кораб спидометры

Дипломатик мөрәҗәгать

АКШтагы штат

Борынгы Идел

Пан ... Мун

Самат Шакир туган авыл

Урта һәм Түбән Идел буенда яшәгән төрки телле кабилә

10^6

Ркаил Зәйдулла пьесасы

Туган ил

Скандинавия халыкларында батырлар турында хикәят

... Хари

Аз санлы төрки халык



XVII-XIX йөзләрдә башкорт җирләренә күчеп утырган татар

Чад каласы

Ерак басуда эшләүчеләрнең күчмә өе

Борынгы әрмән каласы

... сакчысы

Рәис Габдулла төзеде.

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Хәлил, бичура, Ош, бүре, угыз, Актук, Вәли, ләм, Один, талкан, Вафа, майор, Даян, Илу, «Әнисә», әл, Мансур, Нәвои, Әмир, сүрә, ре, Гек, Риан, Дим.
Өстән аска: «Адәмнәр», якут, әмер, Ясәви, Хәбибуллин, Лорка, Үкәк, чор, Мамин, Ибушев, Лим, Муса, Шакулова, Әнәс, гидай, үги, Софи, Рем, зинар, өрпәк.

Сәгъди мавзолее. 1952 елда төзелә. Шираз шәһәре. Иран

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
ЕЛЪЯЗМАСЫ / ФЕВРАЛЬ

• 760 ел элек (1258)

Сәгъди (Әбү Мөхәммәд Мөсләһетдин ибне Габдуллаһ Сәгъди Ширази (1213-1291)) атаклы «Гөлестан» әсәрен иҗат итә.

• 580 ел элек (1438)

Казан ханлыгы барлыкка килә.

• 300 ел элек (1718)

Казан Адмиралтействосы төзелә.

• 160 ел элек (1858)

27 февральдә педагог, кульъязма һәм басма китап остасы, Петербург сәнгать академиясендә белем алган беренче һөнәрмәнд татар рәссамы Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров (Шакирҗан Таһири (1858-1918)) дөньяга килә.

• 100 ел элек (1918)

Бөтенроссия мөселман укытучылар берлегенең Үзәк бюросы органы булган гыйльми, әдәби һәм иҗтимагый «Укытучы» журналының беренче саны дөнья күрә.

90 ел элек (1928)

22 февральдә беренче татар нәфис кинофильмы «Булат батыр» җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә.

• 85 ел элек (1933)

«Совет әдәбияты» журналында Шамил Усмановның «Легион юлы» исемле күләмле әсәре басыла башлый.

• 80 ел элек (1938)

26 февральдә Татар дәүләт академия театрында Мөхәммәт Әблиевнең «Шәмсекамәр» пьесасы беренче мәртәбә сәхнәгә куела. Режиссеры – Ширияздан Сарымсаков.

• 50 ел элек (1968)

15 февральдә Берлиндагы махсус матбугат конференциясендә немец әдәбияты белгече Лион Небенцаль Муса Җәлилгә мөнәсәбәтле яңа табылган мәгълүматлар белән таныштыра.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Февраль 2018

Историческое наследие: «Татарская деревня: прошлое и настоящее»; «Мои ответы по поводу Ш.Марджани». Б.Шараф; «Нурсултан». О.Иванова; «Газета «Аль-Ислах»; «Сафакуль»; «Ядач и ядачийцы». Р.Фахрутдинов.

Татарский мир: «Тангре, Дингир и Умай...» А.Галимзянов; Любимый поэт балкарцев.

Тюркский мир: «На страже нашего наследия».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Письма Аяза Гилязева»; «Защитник родного языка». Р.Ахматзянов; «Татарский язык». Ф.Яруллин; «Просьба из прошлого»; «Что скрывается в «дневнике души»?» Л.Хамидуллин; «О себе и о своём юбилее». Г.Баширов.

В глубине памяти: «Кузнец Фатих». Л.Закир; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Мой сокурсник, соавтор...» Ахтам Зарипов; «Разностороннее национальное творчество». Р.Шагиева; «За песнями странствуя...» Э.Каюмова.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Наследие Шигабутдина Марджани в национальном музее»; «Истинный сын татарского народа». Л.Лерон.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

February 2018

Historic heritage: «Tatar village: the past and the present»; «My replies towards Sh.Mardgani» by B.Sharaf; «Nursultan» by O.Ivanova; «Al-islakh» newspaper»; «Safakul»; «Yadach and its citizens» by R.Fakhrutdinov.

Tatar world: «Tenre, Dingir and Umay...» by A.Galimzyanov; Lovely poet of the Balkarians».

Turkic world: «On the guard of our heritage».

Religious heritage: «The Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

Literary heritage: «The letters of Ayaz Gilyazev»; «The truly defender of mother tongue» by R.Akhmatzyanov; «Tatar language» by F.Yarullin; «The request from the past»; «What is hidden in «diary of soul»? by L.Khamidullin; «About myself and my anniversary» by G.Bashirov.

From the deepest storage of memory: «Fatikh blacksmith» by L.Zakir; «Keeping the memory, still keeping!»

Creative heritage: «My classmate, my coauthor...» by Akhtam Zaripov; «Versatile national creativity» by R. Shagieva; «Wandering for songs...» by E.Kayumova.

Word is a language's decoration: «Dictionary of national terms» by A.Timergalin.

On the guard of the memory: «National library of the Republic of Tatarstan»; «The heritage of Shigabutdin Mardgani in the National museum»; «The genuine son of the Tatars».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

Сергей Виктор улы Широков 1957 елда Ташкент шәһәрендә туган. Керәшен татарлары гаиләсеннән. Ул Ташкенттагы П.Беньков исемендәге сәнгать училищесын тәмамлаган.

1985 елдан алып рәссамның барча әсәрләре дә Рауль Мир-Хәйдәров тупланмасында саклана, Россиядәге һәм чит илләрдәге күргәзмәләргә куела.

Сергей Широков Мәскәү һәм Монреаль шәһәрләрендә яши.

Сергей Широков

«Кошлар сатучы». 1989 ел. Киндер, катнаш техника

«Хуҗа». 1991 ел. Киндер, катнаш техника

«Бәйрәм». 1993 ел. Киндер, катнаш техника

Гөлгамбәр ханым ире Исмәгыйль Усмановны Беренче бөтендөнья сугышына озатканда төшкән фото

«Татар хатыныниләр күрми».
Илфар Габдрахманов

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Казан ханлыгы язмышы. **Булат Хәмидуллин**
Сәнәкчеләр фаҗигасе. **Гасыймә Мостафина-Рәфыйкова**
Хөсни хат (Матур язу). **Мөхәммәт Галләм**
Татар хатыны ниләр күрми? **Илфар Габдрахманов**
Асылыңда ни, Русия? **Риваль Хафизов**
Кала юлы. **Хәлим Җәләй**
Кем ул Васил Әхмәтҗанов? **Мөҗәһит Әхмәтҗанов**
Каюм Насыйри һәм Мәхмүт Хәсәнов хатлары
Бер бәйләм беркетмә

ИНДЕКС:

ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

*«**БЕЗНЕҢ МИРАС**» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*